ТКН ТКИ

# Шаукат Галиёв

# ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

В пяти томах

1
ТОМ

ЛИРИКА

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2002

# Шәүкәт Галиев

# САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

Биш томда

1
ТОМ

ЛИРИКА

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2002

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
Г 18

Редколлегия:

*З.Р.Вәлиева, Р.М.Миңнуллин, Ф.Г.Галимуллин,
И.Г.Юзеев, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

**Галиев Шәүкәт**

Г 18 Сайланма әсәрләр. 5 томда, 1 том.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.— 480 б.

ISBN 5-298-01194-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2002



## КАДЕРЕН БЕЛГӘННӘРГӘ...

Олуг шагыйребез Шәүкәт Галиевнең әлеге 5 томлык сайланмаларына кереш сүзне зур әдәбият белгечләре, дәрәҗәле тәнкыйтьчеләр, докторлар, академиклар язарга тиеш иде югыйсә. Бармак белән генә санарлык халык шагыйрьләребезнең берсе бит ул. Иң затлы премияләр лауреаты. Шул исәптән, Г. Тукай исемендәге Дәүләт, Х.-К.Андерсен исемендәге халыкара әдәби премияләр иясе дә. Хөрмәтле аксакал! Татар халкының дан казанган олы шәхесе! Ә мин исә аның бик күпкә яшь шәкерте, каләмдәше. Аның шикелле үк әдип, татарның бер балалар шагыйре. Шуңа күрә дә Остаз турындагы сүзем бик үк объектив та булып бетмәскә мөмкин. Әмма шагыйрьнең иҗаты миңа яхшы таныш, үзен якыннан беләм. Иҗатын яратам, үзен хөрмәт итәм.Ниләр уйлыйм, шуларны язармын...

Ә бит бүгенге әдәбиятыбызны әле һаман Ш. Галиевләр буыны тотып тора. Аларның һәммәсе дә диярлек әдәбиятка шагыйрьләр булып килде. Нинди генә шагыйрьләр әле! Асыл шагыйрьләр, затлы шагыйрьләр! Гамил Афзал, Илдар Юзеев, Әхсән Баян, Хисам Камал, Роберт Әхмәтҗан... Ничә дистә еллар буена татар шигыренең иксез-чиксез басу-кырларын алар сөреп барды. Ул басулар мул итеп шигъри уңышлар бирә торды. Ә инде алтмышынчы елларда татар шигыренә яңа шагыйрьләр килгәннән соң, аларның иҗаты тагын да киңәеп, тирәнәеп, иркенәеп киткәндәй булды. Әлеге буынның буыны нык булып чыкты. Шигърияттән тыш та һәрберсе үз җаен, үз жанрын тапты. Ә. Баян прозага тартылды, И. Юзеев — драматургиягә, Х. Камалов романнарга күчте. Ш. Галиев балалар шигъриятен басып алды. Бер Роберт Әхмәтҗан гына саф лирик булып калды...

Әле менә уйлап куям. Ул чакта Шәүкәт Галиев килмәгән булса, безнең татар балалар шигърияте нинди юлдан китәр иде дә, бүген ул нindирәк хәлдә булыр иде икән? Һәркемнең үз фикередер. Һәркем үзен хаклы саный, үзен зур шагыйрьгә исәпли. Заманында бер төркем талантсызлар шагыйрьнең канын шактый эчте. Нишлисең, талантсызларның агрессив булуы һәркемгә билгеле. Әмма ни генә булмасын, Ш. Галиевнең балалар әдәбиятына килүе нәниләр шигъриятен бер баскычка югарырак күтәрде. Балалар әдәбияты кискен

сыйфат сикереше ясады, аның союз күләмендә абруе артты. Шагыйрь үзенең таланты белән, үзенең бай иҗаты белән дистә еллар дәвамында җәмәгатьчелекнең дә, әдәбият белгечләренең дә, өлкән әдипләрнең дә балалар әдәбиятына булган битараф мөнәсәбәтен уңай якка үзгәртте. Балалар язучылары белән санлаша башладылар.

Шәүкәт Галиев балалар әдәбиятына Яңа Шигърият алып килде, дистәләгән шәкертләр тәрбияләде, үз тирәсенә талантлы каләмдәшләрен, яшь сәләтләрне туплый алды, үзенең шигъри мәктәбен тудырды. Үзенең иҗаты белән генә түгел, ә иҗтимагый эшчәнлеге белән дә безгә һәрчак үрнәк булды. Ул балалар әдәбиятын иң актив пропагандалаучыларның берсе. Мәктәпләрдә, балалар бакчаларында, мөгаллимнәр мохитендә ул иң көтеп алынган, яратып кабул ителгән шагыйрь. Алтмышынчы елларда телсез калган татар балаларының телен ачкан шагыйрь ул. Кистереп әйтә алам: Шәүкәт Галиев дөнья балалар әдәбиятының күренекле вәкиле. Бернинди ташламаларсыз әйтәм! Һәм аның исемен А. Барто, С. Михалков, Морес Карем, О. Вациетис, К. Тәңрекулиев, Мостай Кәрим, Э. Успенский кебек дәрәҗәле әдипләр белән беррәттән куям. Шәүкәт аганың иҗаты аларныкыннан һич кенә дә ким түгел. Киресенчә, кайберләреннән күпкә югарырак та әле. Ә менә үзебезнең татар әдәбиятында аны фәкать Тукай, Алиш, Исәнбәт исемнәре белән генә янәшә куеп була. Балалар әдәбиятының дүрт алтын баганасы! Дүрт Алып Батыры!

Балалар әдәбиятына килгәнче, Шәүкәт Галиев үзенең үткен телле, үткен фикерле юморист һәм сатирик икәнлеген күрсәтеп өлгергән иде инде. Халык арасындагы популярлыкны да ул иң элек әнә шул шаян шигырьләре белән яулап алды. Сәхнәләрдән ул елларда берничә генә шагыйрьне яттан сөйлиләр иде. Аларның берсе — Гамил Афзал, икенчесе — Шәүкәт Галиев, өченчесе — Башкортстанда яшәүче Тимер Арслан. Телләренә шайтан төкергән шагыйрьләр, халыкның күңел кылларында ифрат та оста уйный белүчеләр, йомшак җәеп катыга утыртучылар... Халыкчан булу өчен халык кайгысы белән кайгырып, халык шатлыгы белән шатланып яшәргә дә кирәк шул. Халыкның үзе булырга кирәк. Ш. Галиев нәкъ шундый шагыйрьләребезнең берсе. Халыктагы җорлык та, чәчәнлек тә, тапкырлык та, сүз уйнату да җитәрлек аның шаян шигырьләрендә. Сатира-юмордагы әнә шул үзенчәлекләрне балалар шигыренә дә алып килде шагыйрь. Һәм һич кенә дә ялгышмады...

Шәүкәт Галиев үзенең олы иҗатын лирик шагыйрь бу-

лып башлады. Әдәбиятның нинди генә өлкәсендә эшләмәсен, ул барыбер үзенең лирикасын онытмады. Шул лирика дөньясына әйләнде дә кайтты, әйләнде дә кайтты, һәм гомере буе лирик шагыйрь булып калды. Анысы үзе бер шигъри дөнья. Әхмәт Фәйзиләр фатиха биргән ихлас шигърият әле дә дәвам итә, шагыйрь күңелендә балкып-балкып ала. Ул барыбер күңеле белән лирик шагыйрь булып кала...

Бу 5 томлыкка шагыйрь иҗатының бер өлеше генә сыйды. Әгәр дә бөтен иҗатын тулаем чыгарыйм дисәң, тагын шулкадәр томлыклар кирәк булыр иде. Зур аның иҗаты. Ул бит коеп куйган шагыйрь генә түгел... «Илһамым — мәхәббәтем» һәм «Әз-мәз мәзәк» кебек афоризмнар китаплары чыгарып безне бер тапкыр сокландырган иде инде. Шагыйрь анда үзенең, чын мәгънәсендә фикер иясе, акыл иясе булуын, бертуктаусыз иҗат итүен, эзләнүен, образлы фикер йөртүче, философ-әдип булуын күрсәтте. Ул безнең әдәбиятка тагын бер яңалык —яңа жанр алып килде. Афоризмнар, канатлы сүзләр, үткен әйтемнәр, йомры фикерләр, «җүләр» җөмләләр жанры. Сүз эчендә хикмәт бар, ди шагыйрь. Сүз тәмен, сүз эченә яшеренгән хикмәтләрнең серен, тылсымын аннан да ныграк тоемлаучы тагын берәр шагыйрь бар микән бездә? Аның һәр афоризмы — шигырь. Анда шагыйрьнең үз эстетикасы, фәлсәфәсе, дөньяга карашлары, шигырь кысаларына сыймаган тыгыз фикерләре. Ул фикерләрне матур итеп, үтемле итеп, укучының күңеленә, аңына, рухына үтеп керерлек итеп әйтә дә белергә кирәк бит әле... Дөрес, башка зур әдәбиятларда афоризмнар күптән бар инде. Бездә исә аны беренче булып Ш. Галиев аерым бер жанр дәрәҗәсенә күтәрде.

Ә инде «Минем беренче гомерем» — мемуарлар китабы, балачак китабы, истәлекләр китабы. Башка бер язучыныкына да охшамаган, беркемнекен дә кабатламаган, аерым-аерым эссе-уйланулардан торган автобиографик повесть. Язучыларыбызның үз тормыш юллары турындагы язмалар да бар ул бездә, бар. Шактый кызыклы, шактый уңышлы язылган әсәрләребез дә байтак. Шулай да Шәүкәт Галиевнең үз дөньясы, үз бала чагы, үз күзаллавы, үз хәтере, үз истәлекләре...

Шагыйрьнең башка истәлекләре, Х. Туфан, С. Хәким, З.Хәбибуллин, И. Шакиров кебек бөекләребезгә багышланган язмалары шулай ук әдәби кыйммәткә ия. Алар күп, алар үзе бер зур китаплык. Аларга төрле елларда язылган башка мәкаләләрне, рецензияләрне, әдәбият гыйлеменә караган, балалар әдәбияты проблемаларын яктырткан чыгыш-докладларны да

өстәсәң, әдип иҗатының олылыгын, тирәнлеген күрербез. Аларның һәммәсе дә, балаларыбызның, халкыбызның, әдәбиятыбызның киләчәген уйлап, халык язмышы өчен борчылып, янып язылган әсәрләр. Күрәсең, чын әдип шундый булырга тиештер. Фәкать шулай тир түгеп кенә, шулай армый-талмый үз халкыңа хезмәт итеп кенә, бар гомереңне, талантыңны олуг әдәбиятыбызга багышлап кына Шәүкәт Галиев кебек Хөрмәтле Халык Шагыйре була аласыңдыр.

Шәүкәт Галиев әдәбиятта үз сүзен күптән әйтте инде. Берәгәйле итеп әйтте. Әле дә әйтә тора! Әмма аның иҗаты турындагы, үзе турындагы иң олы, иң кирәкле, иң саллы сүз әлегә әйтелмәгән. Аның хакындагы монографияләр, диссертацияләр, китаплар да әлегә язылмаган. Киләчәк буын әдәбият галимнәренә күпме эш! Шагыйрьнең үзенчәрәк әйтсәк, кадерен белгәннәргә күпме байлык, күпме хәзинә!..

Үземнең остазым турында, аның олылыгы турында, аның иҗатының башка матур яклары турында мин тагын да үтемлерәк сүзләр тапкан булыр идем, тагын да саллырак дәлилләр китерә алган булыр идем. Әмма кереш сүзнең үз кысалары бар. Килешмәс дип тә уйладым. Ул мине үзе шулай өйрәтте.

*Роберт Миңнуллин,*
Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт,
Х.-К.Андерсен исемендәге халыкара
әдәби премияләр лауреаты

14 май, 2002 ел

# ЛИРИКА

(1945 — 2002)

# 50 нче еллар

## *Тимерлектә*

Гөрли-гөрли янып тора
Тимерлекнең учагы,
Урак өсте кебек монда —
Эшнең иң кызу чагы.

Уйнатып авыр чүкечен
Көчле, нык кулларында,
Эндәшә тимерче Рафикъ
Иптәше Мулланурга:

— Кич җитә, тик безнең генә
Эшләр очланмый һаман,
Күрәмсең, остасын көтә,
— Тизме? — дип соңгы сабан.

Мулланур җавап урынына
Чүкечен ешрак йөртә,
«Аңладым, дускай», дигәндәй,
Елмаеп башын селкә...

...Сөйлиләр алар турында:
— Болар лачын кебекләр,
Тимерне кызу чагында
Суга торган егетләр.

*1950*

## *Ут кабынгач*

Шәһәрдән бер монтер килгән,
Ут балкыткан өйләрдә;
Үзенә дә, үзенә дә
Ут кабынган, диләр лә...

Ток тимәсә дә, ут тигән —
Мәхәббәт уты тигән,
Ярасы, диләр, ярасы,
Ярасы, диләр, тирән...

Уйламаган чакта шулай
Тагын бер ут кабынды;
Монтерга да, монтерга да
Ут кертүче табылды.

*1952*

## *Соңгы хәбәр*

*Алсуга*

Иртәнге алты.
Мин роддомнан кайтып киләм.
Радио. Гимн яңгырый. Горур. Көчле.
Һәм Левитан соңгы хәбәр итеп илгә:
«Кызы туды Шәүкәтнең!» —
дип әйтер төсле.

*Март, 1956*

## Минем карлыгачым

Зур төзелешләрдә эшли
Ләйлә — минем сөйгәнем;
Кыю верхолаз булганга,
«Карлыгачым» дигәнем.

Утыз катлы йорт салалар;
Шундый югары менә —
«Карлыгачым» күренеп тора
Карлыгач кебек кенә.

Карыйм да, борчылып куям,
Көчле җил өрмәсен, дим,
Бигрәк тә инде биектә,
Егыла күрмәсен, дим.

«Сак бул!» дисәң, көлә генә,
Сикертеп кыйгач кашын:
— Егылуым да ихтимал
Син әйләндерсәң башым...

... Эшләре тыгыз. Бу йортны
Өлгертик, диләр, көзгә.
Шунда «оялабыз», дибез
«Карлыгач» белән без дә.

*1953*

## *Аерылган чак та була...**

(Җыр)

Тормыш булгач, сагынган да,
Моңайган чак та була.
Гел бергә генә торылмый,
Аерылган чак та була.

Якыныңның күзләреннән
Күзең аласың килми;
Минутка да аерыласы,
Ялгыз каласы килми.

Биш көн, биш төн сөйләшсәң дә,
Күңелең булмас иде...
Әле ярый аерылу бар,
Югыйсә шундый шатлыклы
Очрашу булмас иде!

*1953*

## *Яшьлекнең бер минуты*

Бәрле буе. Таллар. Май иртәсе,
Чәчләреңдәй йомшак яз җиле...
Мин кояшны күрмим. Минем өчен
Син балкыйсың. Сиңа — унҗиде...

*Сентябрь, 1957*

* Хөснул Вәлиуллин музыкасы.

## *Атам исеме, балам исеме белән...*

*Җәмилгә*

Эштән кайткач,
Сагынып көткән улым
«Әткәй» диеп күзгә караса,
Үткәннәрем шулчак искә төшеп,
Әрнеп куя йөрәк ярасы.

Күптәнмәле, шулай әтиемне
Каршы ала идем үзем дә.
Инде мәңге ишеталмам аның
«Улым минем» дигән сүзен дә.

Беренчегә мине озатканда
Ул инженер булуым теләде.
Ләкин фашист июнь иртәсендә
Хыялыма мылтык төбәде.

Июнь иртәседәй сабый чагым
Күзләреннән койды чыкларын.
Хәтеремдә,
Әтиемне озатып,
Кулына ябышып авыл чыкканым.

Беренче һәм соңгы тапкыр күрдем
Яшь бөртеген керфек очында.
Кул җылысы шулчак әтиемнең
Йөрәгемә күчте учыннан.

...Ә беркөнне,
Зарыгып хат көткәндә,
Почта авыр хәбәр китерде,
Кош теледәй кәгазь —
Әнкәйне тол,
Безне кинәт ятим иттерде.

Хыялны һәм сөйгән китапларны
Вакытлыча читкә куйдым мин,
Яшь җилкәмдә сугыш авырлыгын,
Йөрәгемдә сагыш тойдым мин.

Еллар үтте.
«Әткәй» диеп, улым
Күзләремә тутырып караса,
Төш сөйләсә әнкәй «атаң...» диеп,
Сызлый башлый йөрәк ярасы.

Онытылыйм диеп, газет алсам,
Борчу гына өстәп җибәрә;
Әтиемә төбәп атучыга
Бүген анда атом бирәләр.

Шатланам да,
Борчылам да карап,
Балам сөенеп уйнап йөргәнне,
Ятимлекне, сугыш газапларын —
Күрмәсеннәр, дим, без күргәнне.

Атам исеме,
Балам исеме белән,
Таләп итәм, моңа хакым бар:
— Үлем түгел, яшәү көче булып,
Хезмәт итсен җирдә атомнар!

*1955*

## Аңа

*

Йолдыз сүнсә дә яктысы еллар буе
Килә, диләр, әле шуны уйлап яттым;
Яшь чагымда сүнгән мәхәббәт йолдызым!
Килеп тора миңа һаман синең яктың!..

*

Төшкә кереп газаплыйсың нигә мине,
Йөрәгемне һаман шулай теләсең ник?
Син яшьлегем белән бергә калдың инде —
Аның кире кайталмасын беләсең бит...

*Октябрь, 1956*

* * *

Каерылып үскән үләннәрдән
Иртәнге чык кибеп бетмәгән.
Салмак кына чалгы селтәп әле
Печәнчеләр моннан үтмәгән.

Ялгыз чалгы өйнең кыегыннан
Сузып тышка кәкре борынын,
Ничә елдан бирле, мине көтеп,
Күзләп тора таныш болынын...

*Февраль, 1957*

## *Сабый чагым, дисәм*

...Ярты тәрәзәгә кадәр — кибәк,
Чыпта белән ишек тышланган.
Күрмәгәндә сөлгеләрне чәйнәп,
Бозавы да шунда кышлаган.

Чалгы пәке белән сырлый-сырлый,
Әрәмәдән кискән таякны,
Мич башында кайнар арышка мин
Азмы утырдым күмеп аякны...

Ишеткәнгә әллә шул вакытта
Тәүге тапкыр Тукай исемен,
Сабый чагым, дисәм, сагындырып,
Кышкы кичләр төшә исемә.

Кулларына тышсыз китап алып,
Сыендырып мине куенына,
Моңлы итеп әткәм сәке өстендә
Көйли иде төннәр буена.

Кышкы кичләр Тукай моңы булып,
Йөрәгемә тирән сызылган.
Кем белә, шәт, шигырь юлларымның
Очы шуннан башлап сузылган...

*Январь, 1957*

## Буразнаны буразнага ялгап...

...Көзге диптер, ахры, карый кояш
Якты төрәненә сабанның,
Йомшак түшен җирнең рәхәтләнеп
Үбеп йөри аяк табаным.

Бер атлап та, бер сикереп арттан
Ияреп килә карга көтүе.
Рәхәт тә соң җиләс иртәләрдә
Җир җылысын тоеп үтүе...

Буразнаны буразнага ялгап,
Әйләнмәгән булсам ул чакны,
Туган кырларымның якынлыгын
Белер идеммени бу чаклы!

*Февраль, 1957*

## Бер карасаң...

Читләрендә юлның — дегетле үлән,
Юл сапканнар арыш таптатып.
Тузан алдан бара
Ашыкмыйча,
Кайтып киләм атым атлатып.

Бер карасаң, күзең тукталырлык,
Нәрсә генә бар бу кырларда?
Ә ул миңа, авыл малаена,
Гомер буе җитәр җырларга!

*Февраль, 1957*

## *Кашкаларым*

Нужа йөген бергә тарткангадыр,
Җил-яңгырны бергә кичкәнгә,—
Җигеп йөргән атлар якын икән,
Озак чыкмый икән истән дә.

Улагыннан шулай башын алып,
Ник ятсынып карый бу кашка?
Читтә минем шактый гомер үткән,
Өс-башым да хәзер шул башка...

Чишмәләрдән су эчәргә кыстап,
Бүтән егет инде сызгыра,
Йөгәненә чукны бүтән тага,
Җилдә ялын бүтән туздыра...

Ә мин хәзер шигырь сукалыйм шул,
Хисләр йөгәнләргә тырышам.
«Атландырмыйм!»—
диеп уйнап чапкан
Пегас* ялларына ябышам...

Кашкаларым, бәлки, ятсыныр да,
Яшәмәсләр һаман юксынып;
Җырларыма ләкин авылдашлар
Карамасын иде ятсынып!

*Июнь, 1957*

* Пегас — грек мифологиясендәге канатлы аргамак. Поэтик илһам символы.

## Алмалар күзлим мин

Бакчада йөрим мин,
Алмалар күзлим мин.
«Авыз ит», дисәң дә,
Берсен дә өзмим мин.
Алмалар күзлим мин...

Ак күлмәк килешә,
Билләрең ай нечкә,
Күземне йөзеңнән
Алалмыйм мин һич тә.
Билләрең ай нечкә...

Чәчәкләр өзәсең,
Үзәгем өзәсең...
Син яшел бакчада
Аккоштай йөзәсең.
Үзәгем өзәсең...

Йөрдем дә йөрдем мин,
Вакыт шул китәргә.
Ике бит алмаңны
Их, авыз итәргә!
Вакыт шул китәргә...

*Июнь, 1957*

## *Мин эзләдем аны...*

Мин текәлеп карыйм һәрбер кызга:
«Бәхет гөлем шушы түгелме?»
Ул Уфада, Мәскәүдәдер кебек,
Ерак җирләр тарта күңелне...

Мин эзләдем аны еллар буе,
Йөрәгемне аңа сакладым.
Мин эзләдем аны бик күп җирдән,
Күпме эзләсәм дә тапмадым.

Яшьлек хыяллары тезгенсез шул,
Диңгез артларыннан эзләгән.
Мәхәббәтем исә, һәр адымым,
Күрше йорттан гына күзләгән!..

*Сентябрь, 1957*

## *Ирнем тибрәтсәм дә...*

Чык агарткан болын буйлап киләм,
Яшел эзләр кала артымда.
Ерак түгел — урман зәңгәрлеге,
Иген дулкыннары каршымда.

Чәчәкләргә карап елмаям мин,
Кояш нурларында коенам.
Ирнем тибрәтсәм дә, шул нурлардай
Җыр агылыр кебек тоела...

*Ноябрь, 1957*

# Әткәйгә хат

(П о э м а)

*Бөек Ватан сугышында һәлак булган этием Галиулла Һидиятуллин истәлегенә*

*

Кояш төшкән Кайбыч урманнарын
Күз йомгач ук төштә күргәндә,
Сабый чактан таныш басуларны,
Чәчәкләрне сагынып йөргәндә,

Чит кырларда, әткәй, егылып калдың,
Чит туфрак ла булды бит юрган...
Чит чәчәкләр үсә яннарыңда,
Баш очыңда шаулый чит урман...

Кайда, әткәй, безнең өчен сине
Соңгы тапкыр күргән ул кырлар?
Адымнарың кинәт өзелеп калган,
Бөтен сагынуларың күмелеп калган
Кабереңә җитсен бу җырлар.

Син сагынган кырлар, игеннәрнең,
Чәчәкләрнең исе бар анда.
Юксынып гел сине төштә күргән
Имәннәрнең моңы бар анда...

## «Мин унике яшьлек малай идем»

«Сугыш!» дигән шомлы аваз иртән
Бәгырьләрне телеп үткәндә,
Мин унике яшьлек малай идем,
Син фронтка чыгып киткәндә...

«Бәбкәм»,— диеп нидер әйтмәк булдың,
Үзең никтер читкә карадың.

Дерелдәгән бармакларың белән,
Чәчләремне генә тарадың.

Ахры, әткәй: «Син сабый шул әле,
Аңламассың...» — диеп тилмердең.
Мин, ваемсыз, капчыгыңнан алып,
Җылы сохарилар кимердем...

Сүзсез генә гел тәмәке тарттың,
Җыерылды бары кашларың.
Кинәт торып, ничә еллар яткан
Зур төпләрне ярып ташладың...

*

Былтыр төпләп кайткан каеныңның
Минем кадәр генә буе да,—
Тамырлары әле ныгымаган.
...Каен түгел, әткәй, уеңда.

Җил-яңгырда шулай улың кала.
Сындырмасмы сугыш давылы?
Әлек син күтәргән бөтен йөкнең
Аңа төшәр хәзер авыры...

Тал биленә кулың салып тордың,
Кайнар битең җилне җылытты.
Тау битләрен күз яшедәй чиста
Чишмә чулпылары чылатты...

Бу сукмаклар, арба эзле юллар,
Каеннарың бар да каласы...
Тал төбендә, сары авызын ачып,
Азык көтә карга баласы...

*

Соңгы тапкыр урам әйләндегез,
Соңгы тапкыр җырлап уздыгыз.
Гармун уфылдады, өзгәләнде...
Саубуллашып җыр-кул суздыгыз.

«Китәм инде, дуслар, китәм инде,
Китәм генә инде, озатыгыз.
Кала җәйгән җылы урыннарым,
Сагынсагыз мине, ятыгыз...»

Җиттек инде басу капкасына,
Капчыкларны вакыт кияргә.
Сеңелемне шулчак иелеп алдың
Соңгы тапкыр кысып сөяргә.

Ябышты ул синең муеныңа,
Алалмас күк беркем аерып.
«Әткәй, китмә!» — диеп елап калды,
Сугыш алды,
алды каерып...

*

Үксез калган таллар башын игән,
Чишмәләр дә моңлы чылтырый.
Өй дә җылый...
Тәрәз күзләрендә
Бөрчек-бөрчек тамчы елтырый.

Ишегалды шып-шыр булып калган...
Өйгә керсәм, бушрак тагын да.
Синең, әткәй, кая киткәнеңне
Төшендем мин тик шул чагында.

«Әткәй!» — диеп үксеп чыгып чаптым.
Көпчәк эзе — басу юлында...
Киткән чакта юансын дип биргән
Пәкең генә калды кулымда.

Башта сугыш минем күңелдә шул
Кинодагы кебек чагылган:
Безнекеләр җырлап алга барган,
Гел дошманнар гына егылган...

*

Ботинкасы, әткәй, ялт-йолт килә,
Күзем алалмадым Назардан;
Чиккән кәләпүше белән бергә
Әтисе алып кайткан базардан.

Кәләпүше миңа таман икән,
Сорагач бер киеп каратты.
...Минем чәчнең төсен кояш алды,
Аякларны «чеби» канатты...

Ә кыш җиткәч, төннәр утырып мин
Олтан салып кидем итегең.
Буран көнне сары туныңның да
Бөкләп бирде әнкәй итәген.

Менә шулай иртә олыгайдым,
Тормыш дилбегәсен тоттым мин.
Синең адым белән юлны башлап,
Зур сәфәргә яшьләй чыктым мин...

## «Җылы урыным кала печәндә»

Хат ташучы үтеп киткән саен,
Тәрәзәгә барып ябыштык,
Өч ай буе көттек өметләнеп,
Өч ай буе, әткәй, ялгыштык.

Күңелләрнең чите китек иде,
Өчпочмаклы хатың ялгады.
«Безнекеннән хәбәр бар!» — дип, әнкәй
Кем узса да әйтми калмады.

Туганнарга сөенеп укып йөрдем,
Күпме шатланмадым, көлмәдем!
Әткәй, әткәй, синең кулдан чыккан
Соңгы хатың икән, белмәдем...

Ул хатыңны алып укыдык без
Кырык өченче ел июньдә.
Кем уйлаган шатлык булып шулай
Кайгы керер диеп өеңә...

*

Ул төнне мин изелеп йоклаганмын,
Хатка каршы хат та язалмый.
Баш очымда басып торган әнкәй
Уятырга мине базалмый.

Сабанчының йокысы тәмле була,
Таңда тагын торып китәргә.
Дилбегәдән кулның бушаганын
Кичкә хәтле кирәк көтәргә.

Ә кич киттек төнге сменага,
Ундүрт яшьтәш — Мәсгуть, Якуплар.
Хәтерләтеп еллар ниндилеген
Каенсарда калды окоплар...

Таңда кайткач эреп киткәнмен мин,
Сиңа тагын җавап язалмый.
Баш очымда басып торган әнкәй
Уятырга мине базалмый...

*

Алгебрадан калган ак битләрне
Йорт хәлләре белән тутырып,
Өч көннән соң учак яктысында
Хат яздым мин, әткәй, утырып.

«Бәрәңгеләр инде чәчәк атты,
Бер бәбкәне тилгән алды бит.
Син кайтканчы, көзгә, зур үсәрләр,
Әле тагын унау калды»,— дип.

Алъяпкычы белән күзен сөртеп
Тыңлый әнкәй. Өсти соңыннан:
«Керен чыгарып оек бәйләп куйдым
Сиңа әйбәт бәрән йонынnan...»

Ябыштырдык. Ачып тагын яздык.
Күпме өстәсә дә булмәдем.
Өзгәләнеп язган бу хатымны
Укый алмасыңны белмәдем...

*

Тастымалга төргән өч бәрәңге
Басып тора бишмәт кесәсен.
Кытыклап ник һаман тамагымны
Минут саен искә төшәсең...

Көзге юллар буйлап, фронт өчен,
Ядрә кебек бодай ташыйбыз;
Тыгыз капчыкларга утырып, үзебез
Бәрәңгене мактап ашыйбыз.

«Стансадан тизрәк җитәр»,— диеп,
Зәңгәр ящиккә мин хатымны
Төшерәм дә тагын килер өчен
Кайтыр юлга борам атымны...

Икмәгем, дим, сезнең окопларга
Хатым белән бергә килмәсме,
Дусларына әткәм: «Бу тәмле ипи —
Улым күчтәнәче»,— димәсме...

...Сөенәм дә бүген тормышымның
Артканлыгын күреп гел яме,
Уйлап куям: «Онытмадыммы соң
Арыш икмәгенең чын тәмен?»

*

Җиденчене бетереп чыккан елым,
Китапларым тора шүрлектә.
Эшләр, әткәй, тыгызланып китте,
Карый алмыйм анда үрелеп тә...

Мин укыйсы китапны шул фашист
Сугыш ялкынында көйрәтте.
Буразнада, арбаларда тормыш
Нужа әлифбасын өйрәтте.

Китапларым кебек, хыялым да
Күңел шүрлегендә калырмы?
Еллар тынычланса, килер көзгә
Бәлки әле укый алырмын...

Звонок тавышы әнә...
Күңел тулып
Күздән ташымасын дип көчкә
Тыелып торам.
Бригадирым килде:
— Кеше кирәк, энем, бар эшкә...

*

Башым әле төрттем генә кебек,
Әнкәй инде селкеп уята:
— Тор, улым, тор,
ат көтүе кайтты.
Соңга кала күрмә, таң ата!

Күзне тырнап ачып җиргә төшәм,
Җылы урыным кала печәндә.
Яңа гына сауган җылы сөтне
Чүлмәгеннән тотып эчәм дә

Йөгәнемне алып эшкә китәм.
Сәгатем юк.
Чамам — таң минем.
Төш җиткәнен беләм — күләгәдән,
Будильнигым уртак — чаң минем.

Кино-фәлән әзрәк эләкте шул,
Гел таң күрдем мин ул заманда.
...Киноларның күбесе онытылган,
Ә таңнарым истә һаман да!

**«Сәнәк каерылса да билләр түзде»**

Нинди генә эшләр күрмәделәр
Ныгымаган безнең яшь куллар.
Йөгереп калды арба асларында
Куна барып үткән күп юллар.

Сәнәк каерылса да билләр түзде,
Салам өйдек, кибән куйдык без.
Билдән карга батып урман кистек,
Ызбаларга чатлык уйдык без.

Атлар егылганда, сыер җиктек,
Көрәк белән кырны актардык,
Көтә идем: эткәй кайтыр менә,
Шушы кырлар буйлап атлар дип.

Нинди генә эшләр күрмәделәр
Ныгымаган безнең яшь куллар!
Йөгереп калды арба асларында
Куна барып үткән күп юллар...

*

Кырык дүртнең язы авыр булды,
Сыгылдырып басты иңнәргә.
Без дә, эткәй, моннан фронт тоттык,—
Солдатларга була тиңләргә.

...Кар киткәнче азык бетеп китте,
Бер сәнәк тә салам калмады.
Чәчкечләргә тиздән җигәр атның
Улагына ул көн салмадык...

Каралтының иштек түбәләрен...
Җилләр белән калдык төренеп,
Арык атлар кабыргасы кебек,
Сайгаклары торды күренеп.

Яткан атлар тора алмый иде...
Күп хәлләргә ул чак күнелде.
Син колхозга авызлыклап төшкән
Туры айгыр шул яз күмелде.

*

...Чәчүлек тә юк иде шул безнең,
Стансадан булды ташыйсы.
Атлар анда йөксез җитә алмас...
Гаҗиз булып җилкә кашыйсың.

Кайбер күңелләрне: «Җирләр шулай
Буш калырмы?» — дигән шик телдә.
Җиргә төшми калган орлык бит ул
Тими калган ядрә шикелле...

Кечкенә арба тартып юлга чыктык,
Капчык салып кайттык иңнәргә.
Без дә шулай моннан фронт тоттык,—
Солдатларга була тиңләргә.

Учлап бодай сипкәч, тубалыннан,
Яшь аралаш бабай ник көлде?
Вакытында төшкән орлык бит ул —
Чәчрәп тигән ядрә шикелле!

*

Әткәй, әткәй, мин соңгарак калып
Сөйлим бугай сиңа бу хакта.
Әрнемәсен, дидек, йөрәкләрең,
Язмадык шул сиңа ул чакта.

Басуларда — урман кебек әрем,
Тамырлары киткән тирәнгә.
Әрем ачыларын,—
бар ачыны
Мин дәшмичә йотып өйрәнгән.

Бер «колесный» йөрде буразнада,
Иснәргә дә җитми төтене.
Безнең генә майламаган сабан
Җир кимерә шыңшып көн-төне.

Арып кайткач, читән буйларыннан
Ярь-яшь кычыткannap өзәм мин.
Витаминнар анда күп ди бугай...
Күп булса да, нишлим, түзәм мин.

## «Ятимлекнең беләм ни икәнен»

Очар кошлар кире кайткан кебек,
Булып синең йөргән якларда,
Окопларны күреп кире кайтты,
Сагынып язган безнең хатлар да.

Элгәреге сугышлардан калган
«Кара пичәт» сүзе телләрдә.
Көтмәгәндә капкаларны шакып,
Кермәде ул инде кемнәргә...

Һаман әле кайта безнең хатлар...
Кача, әткәй, ул төн йокыбыз —
Аптырагач,
                    үзебез сиңа язган
Шул хатларны җыелып укыйбыз...

Хат ташучы яхшы хәбәрләрне
Торган саен күбрәк ташыды.
... Теге көзне сиңа дип үстергән
Казларны, әткәй, бүре ашады...

*

Кырык дүртнең кышы узып китте...
Без белмәдек күңел тынгысы.
Сөенешеп укыган теге хатың
Кайгылысы булды, соңгысы...

...Ә беркөнне
                    зарыгып хат көткәндә,
Почта авыр хәбәр китерде;
Кош теледәй кәгазь —
                                        әнкәйне тол,
Безне кинәт ятим иттерде...

*

Календарьлар күпме яфрак койды,
Саргайдылар инде хатларың...
Сагынган ла саен укый торгач,
Мин күңелдән инде ятладым.

«Яраландым Матвей курганында,
Госпитальдә булдым»,— дигәнсең.
Соңгы рәсмең килде шушы хатта,
Соңгы шинелеңне кигәнсең...

Ничә еллар инде, керфек какмый,
Алмыйсың гел миннән күзеңне;
Менә-менә әйтеп бирерсең күк
Әйталмыйча калган сүзеңне...

Яңа сүзләр килеп чыкмасмы дип,
Хатың укып күзем талдырдым...
Бер-ике сүз нигә өстәмәдең,
Кайткач сөйләргә дип калдырдың?

*

Мин унҗиде яшьлек егет инде,
Синең күлмәкләр дә бик таман.
Тәннәреңнең җылысын саклый алар
Сине хәтерләтеп гел-һаман.

Бүрегең тора чөйдә, туның тора.
Син аларны инде кимәссең:
«Әйдә, улым, бер аппетит өчен
Утын кисеп керик!» — димәссең.

Тырнавычлы чалгың ята әнә,
Тоеп синең кулның эзләрен.
Салам башлы шушы өйгә, әткәй,
Сеңеп калган күпме сүзләрең...

Шахтер лампың тотып, бусагада
Син ничәмә тапкыр күрендең;
Җир астында йөреп исән кайттың,
Җир өстендә йөреп күмелдең.

*

Күзләремә ничек моң сеңмәсен
Сабыйлыкның тыеп шуклыгын,—

«Әткәй» диеп кеше дәшкән саен,
Әрнеттереп сизелә юклыгың.

Сыңар канат —
сыңар канат инде,
Талпынса да ерак киталмый...
Бәхет кошы чая оча бит ул,
Сыңар канат куып җиталмый.

Ятимлекнең беләм ни икәнен...
Китаплардан нигә укырга.
Йөрәккә ул эчтән генә йоткан
Кайгы яше булып утырган.

Кайталмасын синең белсәм дә мин,
Торган саен күбрәк сагынам.
Үзән буйлап поезд тавышы килә
Ерак станция ягыннан...

**«Син күрмәдең, әткәй, бу көннәрне»**

Тарих тынды, әткәй, синең өчен
Кырык өченең июнь аенда,
Сиңа сөйләр хәлләр шактый әле,
Син күрмәдең Җиңү маен да.

Син күрмәдең, әткәй, бу көннәрне...
Рәшәткәгә әнкәй сөялеп:
«Исән кеше кайтыр, безнең генә
Кайтмас...» — диде яшькә төелеп.

Авыз тутырып «әткәй» диялмыйча,
Яшьтән ятим калган балалар:
— Күп әтиләр кайтты, нигә кайтмый
Минем эти? — диеп калалар.

...Бу ятимнәр — соңгылары булсын.
Кеше каны бүтән акмасын.
Безнең әткәйләргә төшкән бомба
Музейларда гына саклансын.

*

Көннәр үтте...
Солдат ярасыннан
Ак марлялар инде алынды.
Илнең ярасына ак марлядай
Ап-ак йортлар, юллар салынды.

Пушка тарткан НАТИ табаннары
Таныш җирне кабат тойдылар.
Тупчылар да кайтып, артып калган
Снарядтан сабан койдылар.

Иртәләрен инде морҗалардан
Чыккалады коймак исләре.
Капка төпләрендә махра уты
Озак җемелдәде кичләрен.

Авылдашың сөйли ничек итеп
Әле генә Берлин алганын,
Кара тәре төшкән «юлбарыс»ның
Муены астына килеп калганын.

*

Әллә инде җиңү шатлыгыннан,
Әллә яшьли күпне күргәнгә,
Тел очыма, әткәй, шигырь килә
Иген арасында йөргәндә.

Аз булдымы каты сугышларда
Ярты сүздә җыры бүленгән?
Биш почмаклы йолдыз асларына
Күпме матур шигырь күмелгән...

Әзер килеш йөрәкләрдә киткән
Көйне, бәлки, озак эзләрмен.
Җиткералсам иде яшь солдатның
Туган җиргә дигән сүзләрен.

Кавышалмый калган сөйгәненә
Моңы булып аның җитсәче,
Сабанчысын көткән игеннәрне
Кулы булып сыйпап үтсәче...

**«Мөлдерәмә тулы күзем белән»**

Яланаяк төшкән рәсемемне
Куенында саклап йөргәнсең,
Күңелеңнән мине һаман да син
Унике яшь итеп күргәнсең.

Ә мин үстем, ярышып каен белән
(Бик юксынсам, чыгам бакчага).
Телогрейка алып кидем инде
Үзем эшләп тапкан акчага.

Чамаласаң шуннан чамаларсың
Син югында үткән араны —
Синең теге «безопасный» пәкең
Улыңа да бу ел ярады.

Синең яшьлек йөргән сукмаклардан
Җырлап үтәм чыклы таңнарда.
Кабатлыйм мин синең гомереңне,
Тырышам мин сине аңларга.

*

Бакырчының урамнары, әткәй,
Син кайткан дип, ялгыш сөенгән.
Тавышым да, ахры, синекедәй,
Охшаш, ахры, җырым-көем дә.

Чиремшәннең суы, син дип белеп,
Кочып алды йомшак куенына.
Бадамшадан искән җылы җилләр
Шарф булып ятты муеныма.

Бики тауда синең чыганак та —
Көзге итеп баккач үзенә,—
Син исән-сау кайткан икән диеп,
Куанып карап торды йөземә.

Каенын да син дип иркәләнә...
Авылдашлар сиңа охшата.
«Атаң төсле итеп карыйм»,— диеп,
Кайгыларын әнкәй бушата...

*

Башлы-күзле булып куйдым инде —
Килен төште синең йортыңа;
«Тигез гомер итегез»,— дип әнкәй
Каршылады китереп шартына.

Кул бастырды онга: «Ашлы-сулы
Булып үтсен тормыш көнегез!»
Май каптырды: «Шушы май шикелле,
Йомшак булсын безгә телегез!»

«Синең кыз бар, минем ул үсә»,— дип
Сөйләшкәнсез икән үзегез —
Дустың Сөнгать сиңа кода булды,
Туры килде әйткән сүзегез.

...Кунакларым күптән җыелып бетте,
Ә мин күзлим һаман урамны;
Сөенеп син дә килеп керерсең кук,
Бүрегеңнән кагып буранны...

...«Кайткач күтәрербез» дигән рюмкаң
Мөлдерәмә итеп тутырдым.
Мөлдерәмә тулы күзем белән
Буш урыныңа карап утырдым...

*

Абайлап та өлгермисең, гомер
Күзге кояш кебек авыша;
Исән булсаң хәзер, ишетер идең
Оныгыңның инде тавышын.

«Сөенче!» — дип, врач чыгып әйткәч,
Сабый төсле көлдем, сикердем;

Яше бер көн булган малаема
Уенчыклар алып китердем...

Бөтерелдем бишек тирәсендә,—
Мөмкин түгел әле сөяргә;
Кыймылдата төсле иреннәрен
Миңа карап «әткәй» дияргә.

«Җәмил» диеп аңа исем куштык,
Үзе генә белми исемен...
Хисләреңнең күбесен аңлыйм хәзер,
Чөнки инде үзем әтимен.

### «Заманалар тагын тыныч түгел»

Төн уртасы. Тып-тын. Бар да йоклый...
Елмая әнкәй — сине күрәдер.
Бу төн илдә күпме ятимнәрнең
Төшләренә ата керәдер...

Шөгыль белән үткән көндезләре,
Кичен мендәр яшькә чылана,—
Күпме толлар һаман ирләренең
Пальтоларын ябынып җылына...

Исән булып табышмаган күпме —
Аерым йоклый бала анадан;
Ояларын сугыш туздырган шул,
Кавышырлар микән яңадан?!

Ә соң әле күпме корбаннарын
Җир астына сугыш яшергән...
Төн уртасы, әткәй. Йокы алмый.
Шул көннәрне искә төшерәм...

*

Аяк очына басып түргә үтәм,
Кызым йоклый кысып курчагын;
Күз алдыма килә мәктәпләрдә
Укып йөри торган зур чагы.

Тәмле йокылары бүленмәсен —
Юрганнарын рәтлим үткәндә.
Кече улым матур көлеп куйды
Нәни битләреннән үпкәндә.

Җәмил инде җиде яшькә чыкты,
Китап дисәң — тыңлап туялмый.
Йокысы аның тыныч. Минем кебек
Сугыш күреп куркып уянмый...

Аяк очыма басып карап йөрим...
Тыныч алсыннар гел сулышны;
Киноларда гына күрсәләрче
Без күргәнне — сагыш, сугышны...

*

Аваз биргән саен, йокың бүлеп,
Иеләсең барып бишеккә;
Җил тидерми, сау-сәламәт итеп,
Үстерәсе килә ничек тә.

Озак үсә кеше...
                    Ел көтәсең
Киерелеп тәпи басканчы,
Тагын күпме кулдан төшми әле,
Сүз әйтергә авыз ачканчы...

Авыр үсә кеше...
                    Егерме ел,
Чирек гасыр кирәк үтәргә,
Шунда гына әле өметеңнең
Чынга ашуын була көтәргә.

Ата-ана, ил тырышып шулай,
Керфек какмый карап, гөл итә;
Сугыш исә шуны бер секундта
Чыгарала юкка, көл итә...

*

Төн утырып сиңа хат яздым мин,
Хәреф арты тезеп хәрефне.

Заманалар тагын тыныч түгел,
Еллар, әткәй, еллар хәвефле.

Сезгә каршы кылыч күтәргәннәр
Мылтык кора миңа атарга;
Улымны да ятим итмәкчеләр,
Җыеналар бәхетем таптарга...

Соңарганчы, бу кизәнгән кулны
Кирәк безгә каерып тотарга.
Сез сугышта җиңү яуладыгыз,
Без тынычта тиеш отарга...

...Син сүндертми, әткәй, саклап калган
Кремль йолдызларын күрдем мин.
Институт түгел — хыялымның
Ишеген шунда ачып кердем мин.

*

Әткәй, әткәй, сөйләр сүзләрем күп...
Кермәсә дә бу хат кулыңа;
Тегеләре кебек кире кайтмас,
Ахыр чиктә, җитәр улыма...

Оныкларың синең гомердән ул,
Гел тирәнгә китәр тамырлар;
Бакырчыга кайчан кайтсалар да,
Миңа охшатып, сине таныйлар...

«Бабасы күк җил-җил килеп йөри,
Коеп куйган Гали»,— диярләр.
Бер кан бит ул, әткәй, бер тән бит ул,—
Аркасыннан син дип сөярләр.

Син сагынган басуларда йөрер,
Яфракларга сыеныр йөз белән,
Нигезеңә синдәй аяк басар,
Көнгә карар синең күз белән...

*Сентябрь-октябрь, 1957*

## Бир, кире бир барсын да

Чәйләрем кайный, дисең,
Балларым айный, дисең;
Яна, дисең, учагым,
Кичен, дисең, буш чагым.

Баскычтагы келәгә
Үрелә ят күләгә.
Йөргәнмен юләр булып,
Хурланам үләр булып.

Күзләрең миңа хәрам,
Сүзләрем сиңа әрәм.
Боргаланма каршымда,
Бир, кире бир барсын да.

Ялгыш үткән көнемне,
Сөеп әйткән өнемне,
Әрәм иткән кичләрне
Һәм урланган хисләрне.

Бир, кире бир барсын да,
Боргаланма каршымда!

*Март, 1958*

## *Үпкән-кочкан...*

Яланда ялгыз каенның
Куены ачык тора.
Үткән-барган җилләр аны
Үбеп, йә кочып тора.
Җилләр гел искән саен,
«Үпкән-кочкан
җилгә очкан» дип,
Ваемсыз кала каен.

Каен чәчен, толымнарын
Төрле җилләр туздыра.
Каен, каен, аен-көнен,
Гомерен шулай уздыра.
«Үпкән-кочкан
җилгә очкан» дип,
Шыр ачык булма күңел,
Мин җансыз каен түгел!

*Март, 1958*

* * *

Күзләреңдәй кара карлыганнар...
Иренеңдәй чия өлгергән,
Битләреңдәй яна алмалар да,
Китмәс идем моннан мин бер дә.

Бакчагызда йөрттең, сыйладың син;
Тәме булып ул як җиренең
Күңелемдә калды тере чия —
Унсигез ел пешкән иренең!..

*Март, 1958*

## *Кем әйтә ала?*

... Егет утырып таяк юна,
Кызы баш игән.
Кем әйтала, ник баш игән,
Егет ни дигән?

Кыз күңленә, ахры, бар да
Түгелдер ачык,
Күңелне бит алдап булмый,
Булмый һәм качып...

Ашыктыра бугай егет,
Вакыты тардыр,
Уйлана кыз, уйланырлык
Урыны бардыр...

... Кыз толымын сүтә-үрә,
Егет баш игән.
Кем әйтала, ник баш игән,
Кызы ни дигән?

*Март, 1958*

## *Тамчылар тамар чаклар**

(Җыр)

Тамчылар тамар чаклар,
Ташулар агар чаклар,
Бергә булган вакытларны
Сәгатьләп санар чаклар.

Кама буйлары тал-тирәк,
Тирәксез җирләр сирәк.
Яшьлек яздай шаулар-китәр,
Сөеп калырга кирәк.

Таллар уйлана инде,
Бөре уяна инде,
Язларында ялгыз йөрсәң,
Йөрәкләр яна инде...

Тамчылар тамар чаклар,
Ташулар агар чаклар,
Кадерен белгән кешегә
Минутлап санар чаклар...

*Март, 1958*

* Фасил Әхмәтов музыкасы.

## Көянтә алып бирим...

Көянтә алып бирим,
Иңеңә салып бирим;
Торсын ул кочып кына,
Йөрерсең очып кына.
Чәчәкле көянтәсе,
Нәрсә дияр әнкәсе?

Аксын ла, аксын чишмә,
Серең бүтәнгә чишмә.
Иртәсен дә, кичен дә
Гел мине тот исеңдә!
Бизәкле көянтәсе,
Нәрсә дияр әнкәсе?

Суны чүмеч үпсен лә,
Әй үпсен лә, күпсенмә,
Гөлләр көтсә көтсен лә,
Көннәр бергә үтсен лә!
Алмалы көянтәсе,
Нәрсә дияр әнкәсе?

*Март, 1958*

## *Күгәрченнәр үбешәләр*

Язгы суда кояш уйный,
Алтын нурлар коела;
Шул нурларда, шул суларда
Күгәрченнәр коена.
Язгы гөрләвекләр кебек,
Күгәрченнәр гөрләшә,
Гөрләшәләр, серләшәләр —
Дуслыкларын көнләшәм.
Күгәрченнәр су коенгач,
Канатларын тарыйдыр;
Күгәрченнәр үбешәләр,
Шәт, безгә дә ярыйдыр?..

*Март, 1958*

## *Күпме күзләр күреп онытылган...**

(Җыр)

Күпме күзләр күреп онытылган,
Күпме йөзләр чыккан исемнән,
Күпме сүзләр киткән хәтеремнән,
Ә син һаман, һаман исемдә.
Ничә тапкыр гүзәлләрне күреп,
Мин минутлык хискә исердем.
Айныдым да, сөенеп туялмыйча,
Тагын сине искә төшердем.
Йөрәгемне, ахры, тутыргансың,
Башкаларга анда урын юк.
Күңелемдә синнән бүтәннәргә
«Сөям» дигән назлы җырым юк!

*Март, 1958*

*Мирсәет Яруллин һәм Рифкать Гомәров музыкалары.

## Ярый ла сөйгән әле

Кайсы юллардан китсәк тә,
Кайсы якларга үтсәк тә,
Ярың чибәр лә, диләр.
Ялгыз җибәрмә, диләр.
Авылым — Тигәнәле...
Ярый ла сөйгән әле,
Үземә тигән әле!

Көнләшәләр, кара аны,
Бозмакчылар араны!
Гайбәт ишеттерәләр,
Имеш, ирештерәләр!
Авылым — Тигәнәле...
Ярым бер дигән әле,
Яратам дигән әле!

Басмакчылар эзенә,
Кермәкчеләр күзенә...
Җитәр, артык сөйләнмим,
Яхшы чакта өйләним!
Авылым — Тигәнәле...
Ярый ла сөйгән әле,
Үземә тигән әле!

*Март, 1958*

## *Дулкыннар ярга кага...*

Дулкыннар ярга кага,
Иделдә саллар ага.
    Идел, Идел киң икән,
    Күңелемә тиң икән
    Дулкынланган чагында...
    Салда китте егетем,
    Агып китте өметем.
Карап күзем талдырдым,
Ташлап кынай калдырды...
Ярда яткан балык мин,
Ярда яткан балык мин...
Торам чак тын алып мин,
Торам чак тын алып мин...

Саллар лай китте алдан,
Ялгыз бүрәнә калган.
Буксир тавышы ерак,
Кычкырмый гына йөрәк!..
Дулкыннар ярны ашый,
Күземнән яшьләр ташый.
    Идел, Идел киң икән,
    Күңелемә тиң икән
    Дулкынланган чагында...

*Март, 1958*

## *Камаларны нигә соң кичтем?..*

Кама буйларында кар әле,
Дулкыннарга урын тар әле.
Дулкыннарны тыйган боз гына,
Күңлем ашкындырган кыз гына.

Ерак якларда мин ник үстем,
Камаларны нигә соң кичтем?..
Йөрәгемдә шаулый яз инде,
Тыныч минутларым аз инде.

Кама өсләреннән боз китәр,
Кама буйларыннан кыз үтәр...
Китәм инде мин дә еракка,
Алып китәм кызны... йөрәктә.

Кем уйлаган Кама ярында
Яшәр диеп сөйгән ярым да.
Ерак якларда мин ник үстем,
Камаларны нигә соң кичтем?..

*Март, 1958*

## *Чәчәкләр белми хәлемне**

Ялгыштым ла, ялгыштым ла,
Үкенсәм дә соң инде,
Йөзләремдә күләгә лә,
Күзләремдә моң инде.
Җырлый-җырлый
чалгы янадың,
Тавышыңнан сине таныдым.

Тормышымның кызыгы юк,
Күпме сагыш йоттым мин,
Сине ташлап ник бүтәнгә,
Ник бүтәнгә чыктым мин.
Җырлый-җырлый
чалгы янадың,
Тавышыңнан сине таныдым.

Чәчәкләр үсә болында,
Чәчәкләрнең саны юк,
Чәчәкләр белми хәлемне,
Чәчәкләрнең җаны юк.
Җырлый-җырлый
чалгы янадың,
Тавышыңнан сине таныдым.

*Март, 1958*

* Әхмәт Гадел музыкасы

## Утыр әле яннарыма*

(Җыр)

Онытмәшәкатьләреңне,
Оныт инде беразга,
Сыйпап-сыйпап чәчләремне
Бер иркәлә, бер назла.
    Утыр әле яннарыма,
    Ял булсын җаннарыма.
    Син утырсаң яннарыма,
    Ял була җаннарыма.

Йөзләреңә төбәп карап;
Килә бер сөенәсем,
Килә бер иркәләнәсем,
Килә бер сөеләсем.
    Утыр әле яннарыма,
    Ял булсын җаннарыма.
    Син утырсаң яннарыма,
    Ял була җаннарыма.

Күземә ашыгып кына
Салкын карап үтмә син,
Өстәп тор сөю ялкынын,
Гел өсти тор, бетмәсен.
    Утыр әле яннарыма,
    Ял булсын җаннарыма.
    Мин утырсам яннарыңа,
    Ял булыр җаннарыңа.

*Март, 1958*

* Ифрат Хисамов музыкасы.

## *Янып-көясем килә**

(Җыр)

Туйдырды пыскып яшәүләр,
Янып-көясем килә.
Яныг-көясем килә лә,
«Бәгърем» диясем килә!

Сөеп, сөенеп үзеннән
Күз алалмаслык булсын,
Ияреп кителсен артыннан,
Һич калалмаслык булсын!

Төннәр буе йоклый алмый,
Керфек ормаслык булсын,
Ишекле-түрле йөрелсен,
Утырып тормаслык булсын.

Сагынылсын, саргаелсын,
Ашау үтмәслек булсын,
Мәхәббәтем аңлатырга
Сүзләр җитмәслек булсын!

*Июль, 1958*

* Мирсәет Яруллин музыкасы.

## *Зәңгәр чәчәк*

Төшләремә керә урман,
Инеш, кыр, тугай,
Инеш, кыр, тугай,
Бакырчым, читтә мин бүтән
Торалмам бугай,
Торалмам бугай...

Йөрсәм дә утлар балкыган
Казанда кичен,
Казанда кичен,
Сагынам утсыз урамың,
Арышың исен,
Арышың исен.

Зәңгәр чәчәк, зәңгәр чәчәк,
Юл читләрендә,
Юл читләрендә...
Сагынуның җиттем, ахры,
Соң чикләренә,
Соң чикләренә...

*Июль, 1958*

## *Сиңа әйтер сүзем бар*

Күктә инде ай да бар,
Сүз башларга җай да бар;
Күрмик лә бураннарны,
Урыйк ла урамнарны.
Шыгыр-шыгыр килә кар,
Сиңа әйтер сүзем бар.

Бураннары басылды,
Басылды, күк ачылды,—
Бигрәк зәңгәр икән күк,
Зәңгәр синең күзләр күк.
Әллә инде таң да ата,
Мичләр тәмәке тарта?

Киленнәр таңнан тора,
Тәрәзәләр яктыра.
Бездә ут алынмаган,
Мичкә дә ягылмаган...
Карт шул инде әни дә,
Йә, сузасың син нигә?

Көтмик лә, көтмик көзне,
Узма бу юлы безне!
Бәлки, күңле сизгәндер,
Әнкәй коймак изгәндер...
Керик, инде ай да юк,
Болай йөреп файда юк!..

*Август, 1958*

## «Ак калфаклы кыз китә» дип...

Кычкырдык ярдан чапканда:
«Әлә-лә-лә, боз китә,— дип,—
Ак калфаклы кыз китә»,— дип,
Чиремшәндә су акканда.
Ташыган иде сулар,
Күңелдән ташый шулар,
Күңелдән ташый...

Тальян гармуннар чыңласа:
«Ул кыз ник акты икән,— дип,—
Ярларга бакты микән»,— дип,
Уйладым җырлар тыңласам.
Ярда яккан учаклар —
Күңел җылысы ул чаклар.
Күңел җылысы...

Ел саен шулай боз акты.
«Әлә-лә-лә, боз китә,— дип,—
Ак калфаклы кыз китә»,— дип,
Яшьлекне, ахры, озаттык...
Гомерләр ага бит ул,
Күңелгә кага бит ул,
Күңелгә кага...

*Август, 1958*

## *Чиккән мендәрләр чанада...*

Чиккән мендәрләр чанада,
Чиккән сөлге дугада,
Чиккән алъяпкычын бәйләп,
Йөри килен суга да.

Әйтерсең авылдаш түгел,
Кирәк бит, әй, йөрергә!
Күрше-күләннәр, оялтып,
Керә кәләш күрергә!

«Камыры уңган килennең,
Аш-суга,— диләр,— оста».
Күз кысып йөри яшь кияү:
«Без өйләнгәч төн кыска...»

... Өч көн туен иттеләр дә,
Өч төн уен иттеләр.
Егет-кыз чаклар шау-шуда
Әллә кая киттеләр...

— Кияү кеше, сүзем шушы:
Улың җитмичә буйга,
Яшь кәләш күрсәтергә дип,
Бүтән чакырма туйга!

*Август, 1958*

## Кыр казлары кайта каңгылдашып

Кыр казлары кайта каңгылдашып,
Зәңгәр һава тирән, тирән;
Тау битендә яшел бәбкәләрдәй
Борын төрткән чирәм, чирәм.

Ул кыз белән төштек җитәкләшеп,
Соңгы карлар инде эри;
Болдырларда усал ата казлар
Бәбкәләрне көтеп йөри.

Әби әйтә: «Кыр казларын күргәч,
Җирдән бер уч салам алсаң,
Тезелешеп үсә бәбкәләре,
Казның оясына салсаң...»

Шуңа ышанып ул чак, салам алып,
Чаптык икәү без өйләргә;
Тезелешеп үсә дүрт балабыз,
Шуннан ары ни сөйләргә?!

*Август, 1958*

## *Яшен яктысында*

(Этюд)

Чыбыркы шартлатып куып,
Бер тынга төн карасын,
Яктыртып җибәрде яшен
Ике урман арасын.

Яшь юкәләр караңгыда
Сагаеп тора икән,
Күкрәгән якка, сискәнеп,
Башларын бора икән.

Юеш җирдә ялтыр-йолтыр
Тамчылар уйный биеп,
Черем итәләр арышлар
Арган башларын иеп.

Шадралана су өсләре,
Әйтерсең балык уйный.
Яктыртып карый гел яшен,
Җиргә сокланып туймый!..

*Ноябрь, 1958*

## *Юк синсез яши аласым...*

Туган җир, сиңа мәхәббәт
Күптәннән килгән икән;
Әнием күкрәгеннән имгән
Сөт белән кергән икән.

Сихерләгәнсең икән син
Таңнарың яме белән;
Өлгереп җиткән арышның
Кыр тулган тәме белән.

Балтырганың, кузгалагың,
Алмаларыңа булсын,
Теш өшетердәй суларга —
Салгансың икән тылсым.

Юк синсез яши аласым!
Кайтырмын кайлардан да.
Чит җирдә якты табалмам
Кояштан, айлардан да...

...Бу сөю җиде бабамнан
Килә туктаусыз үсеп;
Яшәр ул үземнән соң да
Оныкларыма күчеп!

*Ноябрь, 1958*

## Юллар бар бөтен якларга

Еракта шул, бик еракта
Ул йөргән урам.
Арабызда озын юллар,
Юлларда буран.

Шул якка чакырып җилләр
Чабудан тарта.
Бурап яуган буран кебек,
Сагышым арта.

Миннән башка урманнарны
Күпме кичкәндер,
Сагыну моңнарын ятлап
Миләш үскәндер...

Атлыгып торма син, йөрәк,
Кавышу ул юк,
Юллар бар бөтен якларга,
Үткәннәргә — юк...

*Декабрь, 1958*

## Күзләреңә карап бер сөйләшсәм...

Ник карадым икән гел айга мин,
Күзем аерып айдай йөзеңнән?
Нигә сүзсез йөрдек икән шулай
Ялтырап яткан чана эзеннән?
Барыр иде язган сәламнәрем,
Хат җитмәслек ара түгел дә...
Үзеңә генә әйтер күп сүзләрем
Җыела бара һаман күңелдә.
Күзләреңә карап бер сөйләшсәм,
Китәр иде күңлем бушанып.
Иң кирәге калган әйтелмичә,
Булмый аны хатка ышанып!..

*Март, 1959*

* * *

Күңелләрем чәчәк ата
Бакчаларда шомырт булып.
Сөенечем ташый минем
Ярдан ярга Идел тулып.
Минем дәрт ул, минем дәрман
Актарылган ташуларда.
Тургай булып менә йөрәк
Сокланырга басуларга.
Җылы җилләр — иркәләвем,
Назым үсә — гөлләр булып.
Мәхәббәтем җирдә шулай
Балкый якты көннәр булып!

*Апрель, 1959*

## *Ник шуларның берсе син түгел?**

(Жыр)

Сагынуларым көндә арта бара,
Язгы ташулардан ким түгел.
Боз карарга күпме кызлар төшкән,
Ник шуларның берсе син түгел?

Ник үсмәдең Идел ярында син,
Язгы юллар нинди яктылар!
Синнән аерым үткән көннәремдәй,
Күпме салкын бозлар актылар...

Болыннарда сиңа дип өзәсе
Күпме чәчәк калды утырып.
Сулышым белән тартып алыр булып,
Карыйм, карыйм күзем тутырып.

Торган саен арта сагынуларым,
Язгы ташкыннардан ким түгел.
Көнгә чыккач күпме кызлар күрәм,
Ник шуларның берсе син түгел?

*Март, 1959*

*Рөстәм Зарипов музыкасы.

## Яшьлек кебек сөендереп...

Яшьлек кебек сөендереп,
Күзләрне чагылдырып,
Күңелләр бозын эретеп,
Яз килә сагындырып.

Нурлары үбеп уяткан
Бөреләр күзен ача.
Күбәләк шикелле кызлар
Кайда йөргән моңача?

Зәңгәр чәчәк кебек күзләр,
Мәк шикелле иреннәр...
Шау чәчәктә алмагачлар,
Шау чәчәктә сиреньнәр.

Килә яз, күпме хисләрне
Ул көйгә салып килә.
Килә яз, күпме йөрәккә
Мәхәббәт алып килә!

*Апрель, 1959*

## *Моңа хәтле ничек күрмәгәннәр*

Ак халатын җилдә җилфердәтеп,
Җәйләүләрдә күпме йөрмәгән,
Яңгыратып күпме көлмәгән,
Бер егет тә аны күрмәгән.

Бидоннарын төяп машинага
Урамнардан күпме үтмәгән,
Җилдән бүтән аны үпмәгән,
Капка төпләрендә көтмәгән.

Моңа хәтле ничек күрмәгәннәр,
Мин килгәнче ерак арадан,
Бу егетләр нәрсә караган?
Күрмәүләре, хәер, яраган!

Ак халатын җилдә җилфердәтеп,
Җәйләүләрдә йөргән ярым бар.
Сагынулар бераз барын бар,
Кеше кызыгырлык парым бар!

*Июль, 1959*

## *Сөенечкә дисәм...**

(Җыр)

Кар сулары бетте,
Ярсулары үтте,
Ташлар тәгәрәми ташкында.
Минем генә йөрәк,
Сагынудан йөдәп,
Бәйгедәге аттай ашкына.

Аерым торып еллар,
Аймыл булып юллар,
Нигә синнән читтә узган соң?
Бар шул инде парың,
Янып сөйгән ярың,
Кулларыңны аңа сузгансың...

Арта уйлар һаман,
Тарта сиңа табан,
Кыен миңа ялгыз чакларда,
Сөенечкә дисәм,
Көенечкә икән,
Очрашулар сезнең якларда...

*Апрель, 1959*

* Котдус Хөснуллин музыкасы.

## *Үкенерсең үкенүен...*

Килми дә килми хатларың,
Кәгазең кызганасың;
Беләсең бит йөрәгемнең
Сызасын, сызланасын.

Күңел хакы өчен генә
Бер язсаң нәрсә булган?
Бөтен күз алларым синең
Сурәтең белән тулган...

Көтәм дә көтәм мин һаман,
Күңелне чикли алмыйм;
Уемнан сине чыгарып,
Йөрәкне бикли алмыйм.

Үкенерсең үкенүен,
Син дә бер сызланырсың;
Ак кәгазь кебек буш калган
Көннәрең кызганырсың!

*Апрель, 1959*

## *Ник яңара сагышлар**

(Җыр)

*(Тол хатын авызыннан)*

Шомырт тагын чәчәк койды,
Сиңа дип өзалмадым,
Ак чәчәкләр очкан чакта
Сагнуга түзалмадым...

Шул чәчәкләргә кушылып,
Очар идем җилләрдә,
Табышмыйча калмас идек,
Йөрсәң дә кай илләрдә...

Калды күңел әрнетергә
Киткән юлларың гына,
Калды охшатып карарга
Кызың, улларың гына.

Унбишенче яз инде бу,
Күптән тынды сугышлар.
Яз килгән саен яңара,
Ник яңара сагышлар?

... Шомырт тагын чәчәк койды,
Сиңа дип өзалмадым,
Ак чәчәкләр очкан чакта
Сагнуга түзалмадым...

*Май, 1959*

*Альфред Сәйдәшев музыкасы.

* * *

Йөрәгемнән хисләр ташый гына,
Каян килгән икән бу муллык?
Җитсә җитәр гомрем җитмеш елга,
Мәхәббәтем минем — мең еллык!

*Июль, 1959*

* * *

Ник яраттым икән шул кадәрле
Шушы якның кырын, үрләрен;
Мондагыдай зәңгәр урманнарны
Булмагандыр төсле күргәнем.

Әкияттәге кебек матур бу як,
Һәр почмагы — рәсем итәрлек;
Барлык кошлар бергә җыелса да,
Мәңге мактар өчен җитәрлек.

Җилләре дә монда йомшагырак,
Кояшы да көләч, яктырак;
Юлларыннан әллә син йөргәнгә,
Бу як бөтен җирдән яхшырак!

*Июль, 1959*

## Өлешеңә чыккан көмешең...

Тездән ерып салкын чыкларны,
Бармы таңда кырга чыкканың?
Күк читләре ул чак ялкын бит,
Кояшы да нинди — алтын бит!

Киерелсәң, озак сузылсаң,
Көн авышкач кына кузгалсаң,
Кояш бүтән — беткән ялкыны,—
Көмеш булып калган алтыны...

*Июль, 1959*

## Әллә бергә үскәнгәме...

Кояшка сөенеп җилдә,
Чәчәкләр биеп тора.
Таллар гына никтер моңсу —
Башларын иеп тора.

Чылтыраган чишмәләрнең
Җырларын отып алам,
Башакларның пышылдавын
Ишетеп туктап калам.

Шаулаша зифа камышлар,
Матурлык бүлгән төсле.
Әллә бергә үскәнгәме,
Телләрен беләм төсле...

*Июль, 1959*

## *Раушаниям, бәгърем**

(Җыр)

Диңгезнең дә була төрле чагы,
Бер давыллап ала, бер тына,
        Раушаниям, бәгърем,
Бер давыллап ала, бер тына,
Күңелләрем сиңа омтыла.

Хат-хәбәрең юк бу араларда,
Сәлам әйтми синнән җилләр дә,
        Раушаниям, бәгърем,
Сәлам әйтми синнән җилләр дә,
Ансыз кыен ерак җирләрдә.

Акчарлаклар очкан Агыйделдә
Тугайларны ялгыз гизәмсең,
        Раушаниям, бәгърем,
Тугайларны ялгыз гизәмсең,
Чәчәкләрне миңа өзәмсең?

Мин, меңнәрнең мәхәббәтен саклап,
Диңгез кичәм ерак якларда,
        Раушаниям, бәгърем,
Мин меңнәрнең мәхәббәтен саклыйм,
Ә син тырыш берне сакларга!

*Июль, 1959*

* Васил Хәбисламов музыкасы.

## *Саумысез, арышларым!* *

(Җыр)

Исәнме, иркен кырларым,
Саумысез, арышларым,
Сез минем сабый чагымнан
Иң якын танышларым.

Еракларда, чит җирләрдә
Нихәтле торып та мин,
Исләремнән чыгармадым,
Сагындым, онытмадым.

Агайлар килсә авылдан,
Сүзне гел сезгә бордым,—
«Игеннәр ничек быел?» дип,
Хәлегезне белеп тордым.

Сезнең өчен сусадым мин,
Яңгырлар яумаса да;
Сызландым, өзелгән башак
Тузанда аунаса да.

Сөенәм мин, бүген сезнең
Шаулап үскәнне күреп;
Башыгыздан сыйпыймчы бер
Юлымнан читкә кереп.

Ятсынмагансыз лабаса,
Куенга үреләсез;
Сез миңа ничә кайтсам да,
Яшәреп күренәсез.

Исәнме, иркен кырларым,
Саумысез, арышларым;
Бөтенләйгә булсын иде
Бу кайтып барышларым!

*Июль, 1959*

*Мәсгудә Шәмсетдинова музыкасы.

## *Килгән идем Агыйделгә*

Барган идем бу язда мин
Уфа ягына,
Килеп чыккан кебек булдым
Яшьлек чагыма...

Нәкъ шушылай нурлы иде
Ул көннәрем дә,
Нәкъ шушылай җырлы иде
Ул төннәрем дә.

Якты урамда торасың
Көлеп каршымда,
Аяк тавышыңа кадәр
Таныш барсы да.

Аерылганнан бирле инде
Ничә ел үткән.
Мин үбәргә кыймаганны
Бүтән ир үпкән.

Кыюрак хәзер мин дә,
Үзең дә үзгә,
Ирек бирә алабыз тик
Сагынган сүзгә.

Китәргә туры килде шул
Уфа ягыннан,
Кабат аерылгандай булдым
Яшьлек чагымнан...

*Август, 1958*

## *Юл җыры**

(Җыр)

Паровоз чакыра тагын
Ерак җирләргә,
Өйдә яту эшмени ул
Бездәй ирләргә!
Тәгәрмәчләр,
Тәгәрмәчләр
Йөгереп үтә,
Алда без шәһәр салачак
Далалар көтә.
Сөйгән ярлар да көтсен бер,
Сагынсын әле,
Караңгы якта да утлар
Кабынсын әле!
Тәгәрмәчләр,
Тәгәрмәчләр
Йөгереп үтә,
Алда без юллар сузачак
Урманнар көтә.
Җилкендереп күңелләрне
Ерак җир тарта,
Йөргән саен, күргән саен
Барыр җир арта!
Тәгәрмәчләр,
Тәгәрмәчләр
Йөгереп үтә,
Безне якты гомер юлы,
Зур тормыш көтә!

*Сентябрь, 1959*

*Шакир Мәҗитов музыкасы.

## *Тып-тын урамнардан*

Сузып-сузып кына килә бер җырлыйсы
Тын беткәнче,
Тып-тын урамнардан килә бер йөрисе
Төн үткәнче...

Меңенче кат уйланасы килә тагын
Карап айга,
Мондый тыныч күләгәләр юктыр бүтән
Һичбер кайда.

Көпчәк шине сүтелеп калган кебек, юллар
Шома, якты.
Шул эзләрдән язгы гөрләвектәй күпме
Нурлар акты...

Кешеләрне уятмыйм дип, шыпырт кына
Ага елга.
Нихәтле җыр өйрәткәндер шушы инеш
Үткән юлда.

Йокы аралаш ишеткән җыр матур була,
Бер сыздырыйм...
Теләсә нинди төштән матур төнне йоклап
Ник уздырыйм!

*Сентябрь, 1959*

## Оныткан дисеңме?

Оныткан, дисеңме,
Уйламый, дисеңме,
Кабатлап йөрим мин
Гел синең исемне.
Тик миңа түгел шул,
Иркәм, дип дәшәргә,
Гомергә сагынып,
Юксынып яшәргә...
Онытыр, дисеңме,
Уйламас, дисеңме?
Кызыма кушармын
Мин синең исемне.

*Ноябрь, 1959*

## Шомырт чәчәкләре ак кына...*

(Җыр)

Бакчаларга тулган шомырт исе,
Тәрәзәдән кергән өйләргә,
Исереп бер шомырт исләреннән,
Исереп бер яшьлек хисләреннән,
Җырлыйк әле шушы көйләргә...
Шомырт чәчәкләре ак кына,
Сөюләрең булса хак кына,
Сөенешеп йөрер чак гына...
Чыгыйк әле кырга икәүләшеп,
Дөнья җитә миңа син булгач.
Ник карыйм ди ятлар күзенә мин,
Ник карыйм ди кеше сүзенә мин,
Икебезнең йөрәк тиң булгач!
Шомырт чәчәкләре ак кына,
Сөюләрең булгач хак кына,
Сөенешеп йөрер чак кына!..

*Декабрь, 1959*

* Хөснул Вәлиуллин музыкасы.

## *Тынгы бирми миңа шушы төннәр*

Аяк асты — челтәрләнгән бозлар,
Челтәрләрен ташлап чыккан кызлар,
Ничек түзәсең...
Түкмә, егет, түкмә бар моңыңны,
Тартма, егет, тартма гармуныңны,
Үзәкне өзәсең!

Елгаларда инде боз кузгала,
Күңел кузгалгандыр, кыз бала.
Шундый ул күңел...
Шаулап ага язгы су арыктан,
Язны көткән гөлдәй мин зарыктым,
Шуннан ким түгел!

Тынгы бирми миңа шушы төннәр,
Шушы төннәрдәге моңнар, өннәр.
Йөрик бер тыңлап...
Язгы төннәр кыска, бик тиз үтәр,
Яшьлек тә бит шулай үтәр-китәр,
Көлмә син, чынлап!

Аяк асты — челтәрләнгән бозлар,
Кара, ничек чибәрләнгән кызлар,
Ничек түзәсең ...
Кар суында агыз бар моңыңны,
Тик алай ук тартма гармуныңны,
Үзәкне өзәсең!

*Декабрь, 1959*

## Кызлар, кызлар бииләр...

Шәлләр иңнән алынды,
Бияләйләр салынды.
Тыпыр-тыпыр — итекләр,
Җилфер-җилфер — итәкләр...
Клубны дер селкетеп,
Йөрәкләрне җилкетеп,
Кызлар, кызлар бииләр,
Аяк талды, димиләр.
Күз кысып гармунчыга,
Сәйдәсе чәчрәп чыга.
Ә егет көлә генә,
Уйнавын белә генә:
— Бас, Сәйдә, бас әйдә,
Сындыр идән тактасын,
Сындырсаң идән тактасын —
Үзем түлим акчасын!
— Рәхмәт, яхшы уеңа,
Акчаң сакла туеңа.
Син дә бие, Хәйбулла,
Биегән кеше бай була!..
— Күз тимәсен үзеңә,
Борыч сипкән сүзеңә!
— Жәл түгел, син дигәндә,
Аякларым идәндә!
Сәхнәдәнме төшкәннәр,
Гел биепме үскәннәр —
Күз иярми ләбаса,
Ай-һай, болар шәп баса!
Рәис тә кергән икән,
Ул да хуп күргән икән:
— Сезгә эш тә ят түгел,
Бию дә оят түгел.
Биик итек тузганчы,
Артистларны узганчы!

*Декабрь, 1959*

* * *

Казаннарга тагын поезд китте,
Поезд китте туган якларга.
Күңелләрем әллә нишләп куя
Поезд аваз биргән чакларда.

Мин кайтканчы әле, вагоннардай,
Күпме көннәр тезелеп үтәсе,
Әле күпме ялгыз уфтанасы,
Күпме сагынып, күпме көтәсе...

Читтә үткән шушы айларымда
Кавышасы көнем юаныч,
Аерым чакта ярар моңайсам да,
Бергә чакка калсын куаныч.

Килер ул көн, кая басканыңны
Белмичә син очынып йөрерсең,
Вагон-вагон сөенечләр алып,
Бер кайтырмын әле, күрерсең!

*Март, 1960*

## Уйламый идем…

Уйламый идем, шулхәтле
Сагынып буладыр дип,
Вокзалына аяк баскач
Күңелләр туладыр дип…

Тансыклап, сокланып карыйм
Тәүге кат күргән кебек.
Ничек мин мондый калада
Гамьсез йөргәнмен элек?

Идел-диңгез буйларыннан
Рәхәт икән барасы…
Казаным, күзгә күренеп,
Көннән-көн яңарасың!..

Электрлы баганалар —
Ландышлар тезгән сыман,
Сөембикә манарасы
Шатлыгым сизгән сыман…

Уйламый идем, шулхәтле
Сагынып буладыр дип,
Тойгылар язгы Иделдәй
Мөлдерәп туладыр дип.

Һәр урамың якын икән,
Күңел кылларын тарта.
Аяк атлап баскан саен,
Җырлыйсы җырым арта.

Яратканга сагынганмын,
Күңелем атлыккандыр,
Киләчәктә йөрим сыман —
Бәлки, бу шатлыктандыр?

*1960*

* * *

Нигә миңа диңгез зәңгәрлеге,
Синең зәңгәр күзләр булмагач!
Нигә миңа ай-кояшлы көннәр,
Синең нурлы йөзең булмагач...

Нигә миңа матур-матур көйләр,
Берьялгызым гына тыңлагач!
Нигә миңа аерым шатланулар,
Сөенече уртак булмагач...

Нигә миңа тәмле-татлы төшләр,
Очрашулар өндә булмагач...
Нигә миңа дөнья тулы кызлар,
Үз дигәнем янда булмагач!

*Апрель, 1960*

* * *

Без беренче тапкыр икәүләшеп
Якты болыннарны урадык,
«Яратамсың?» диеп сорашмадык,
Ромашкалар өзеп юрадык...

Онытылмас мондый рәхәт көннәр,
Сөенә-сөенә болай гизгәннәр.
«Ярата» да гел «ярата», диләр,
Ромашкалар каян сизгәннәр?!

*Сентябрь, 1960*

## *Ай-Петрида ята партизаннар...*

«Ай-һай, биек...» дигән Ай-Петриның
Күтәрелдем иң-иң очына.
Бөркет кенә йөргән биеклектә
Канатлана күңел, очына.

Мактанасы килә:
«Күрәсезме,
Мендем нинди тауның башына!»
Күзем төште шунда,
Йолдыз куйган,
Исем уйган кабер ташына...

Партизаннар күптән йөргән икән,
Фашист юлын монда бүлгәннәр.
Туган җирне үлеп яратканнар,
Ил яшәсен өчен үлгәннәр.

...Ай-Петрида ята партизаннар,
Болытларга аккан каннары...
Алар саклап калган байрак мәллә —
Бигрәк алсу көньяк таңнары!

*Июль, 1960*

## *Тыелган дәрт, тезгенләнгән хисләр*

Терекөмеш кебек тере күзләр
Кая барсам, шунда авыша.
Сагынылган күпме көннәрдән соң,
Күзләр белән күзләр кавыша...
Колач җәеп үзең атылыр идең
Рәхәтләнеп минем каршыма.
Тыеласың, берни сиздермисең,
Күңелеңдә кала барсы да.
Йөрәгеңне кулда тотасың син,
Хисләреңне бәйдә тотасың.
Көенсәң дә, эчтән тынасың син,
Яшеңне дә эчтән йотасың.
Менә-менә атылырсың кебек,
Барсын онытып, минем каршыма.
Тыелган дәрт,
тезгенләнгән хисләр —
Күзләреңдә синең барсы да...

*Сентябрь, 1960*

* * *

Миндәй сине беркем яраталмас,
Миндәй сине беркем сагынмас,
Миндәй сине беркем иркәләмәс,
Миндәй бүтән кеше табылмас.

Синдәй мине беркем якын күрмәс,
Синдәй мине беркем назламас,
Синдәй мине беркем юксыналмас,
Синдәй бүтән беркем сызламас...

*Сентябрь, 1960*

## Илһам Шакировка

Ишеттем мин читтә «Туган тел»не,
Халкым, нинди моңлы көең бар...
Тукаемны йотылып тыңлаганда,
Тамагымда кайнар төер бар.

Кем ничектер, әмма мин бу җырны
Тыңлыйм да гына тыңлыйм, туялмыйм.
Әсәрләнәм сабый бала кебек,
Ир булсам да яшем тыялмыйм!..

*Сентябрь, 1960*

## Кушылганнар юллар юлларга*

(Җыр)

Кушылганнар юллар юлларга,
Үрелгәннәр куллар кулларга,
Йөрәкләрнең якын арасы.
Офык арты офыкларны үтеп,
Гел барасы иде, барасы...

Табыштылар безнең йөрәкләр,
Кавыштылар безнең теләкләр,
Шатлансын да дуслар, соклансын.
Мәхәббәтнең шушы кайнарлыгы
Гомер буйларына сакласын!

Аерылмасын күзләр күзләрдән,
Борылмасын йөзләр йөзләрдән,
Үteләсе юллар үткәнче,
Үтеләсе юллар үткәнче дә
Безгә дигән гомер беткәнче!

*Октябрь, 1960*

---

* Васил Хәбисламов музыкасы.

## *Күңел тартты тагын шул якларга*

...Сугыш үзе якын булмаса да,
Давыллары килеп тигәннәр.
Имән кебек ирләр ауган чакта,
Ирләр кебек ауды имәннәр.

Җәрәхәтле коштай тыпырчынды,
Бәргәләнде җиргә усак та.
Уфылдашып ауган юкәләрнең
Канатлары янды учакта.

...Ышанырсың төсле, илдә ирләр,
Җирдә урман калмас, дисәләр,
Сырма чалбар кигән тол хатыннар
Фронт өчен урман кисәләр.

Килер көннәр гүзәллеген саклап,
Күпме матурлыкны ектык без...
Карга бата-бата, ир затлары
Уналтынчы яшькә чыктык без.

... Күңел тартты тагын шул якларга,
Танымаслык монда үзгәреш,
Күтәрелгән дәррәү яшь урманнар,
Үзгә хисләр хәзер, үзгә эш.

Яңа буын үсеп буйга җиткән,
Урамнарда бүтән үсмерләр,
Бер күрүдә танымаган кеше
Әтиләрен уйлап төсмерләр...

Дошман безне җиргә сеңдерәм дип,
Юкка гына, юкка каныккан,
Илем кебек урман күтәрелгән,
Имән кебек ирләр калыккан!

*Сентябрь, 1960*

## Кипарислар мине аңламаслар

Гүзәллеккә, ансы, гүзәл бу җир,
Якты нурлар белән тулган як.
Шат чагында яхшы, ят якта да,
Моңайганда кирәк туган як...

Мин бит монда бары кунак кына,
Чирәмендә аунап үсмәгән,
Матурлыгы — рәсем кебек кенә,
Күңелемә яшьтән күчмәгән.

Арышлы кыр, таллы инешләрне
Өстен куярга мин җыенмыйм,
Тик шулай да күңел ашкынганда
Кая барып бүген сыеныйм?

Кипарисы мине аңламастыр,—
Көязләнеп күккә караган.
Пальмасы да, ахры, төшенмәстер,
Чәчен нинди купшы тараган...

Ят икәннәр банан, магнолияләр,
Сердәш түгел икән каштаннар,
Таулар биек — алар ишетмиләр —
Болытлардан өскә ашканнар.

Дулкынланып көнен, төннәрен дә
Тынгы белми шаулый гел диңгез.
Чыгыйм әле шунда!
Синең белән, диңгез,
Аңлашырбыз, дим, без!

*Октябрь, 1960*

## *Казлар оча шәһәр өстеннән*

Самолетлар оча көн буе,
Ник берәрсе шуңа карасын —
Җирдә дә бит тона колаклар,
Мотор тавышыннан арасың.

Кинәт бар да күккә текәлгән,
Көтмәгән хәл анда һич кенә:
Үзәк өзеп каңгылдашалар
Киек казлар шәһәр өстендә!

Шул казлардай күңел талпынды,
Онытылды көннең шау-шуы,
Шушы мизгел — уйнак хыялның
Сабый чагым белән каушуы...

Үскән җирен искә алмыйча,
Яшәсә дә кеше шәһәрдә,
Ашкынмыйча калмас күңеле,
Кыр казлары күрсә әгәр дә.

Йорт казыдай күкне оныткан
Сабыр йөрәк ярсып кагыныр,
Бер минут та бүтән түзмәстәй
Туган ягын әрнеп сагыныр.

*Октябрь, 1960*

* * *

...Сабый чагым. Менеп читәнгә
Кыр казларын карап озатам.
Киләчәккә алар оча күк —
Серле, татлы уйлар кузгата!..

Киләчәктә йөрим мин хәзер —
Күпме казлар канат кагынган...
Кыр казлары инде язларын
Кайтадыр күк сабый чагымнан...

*Октябрь, 1960*

## Сузма һаман сагыш көйләреңне

Сузма һаман сагыш көйләреңне,
Мин үзем дә беләм моңлысын,
Җырлачы бер шатлык җырларыңны,
Дәртле җырлар килә тыңлыйсым.

Җиңеләйтсен җырың адымнарны,
Сөенечне, көчне арттырсын,
Күтәрелеп китсен күңелләрем,
Күз алларым минем яктырсын.

Яшәү бит ул үзе гүзәл бер җыр,
Җырлама син һаман моңлысын,
Сыздыр әле шатлык көйләреңне,
Дәртле җырлар килә тыңлыйсым!

*Октябрь, 1960*

## *Ап-ак карда йөрим*

Иртән чыксам, күзләр камаша:
Мамык карлар җирне каплаган.
Җиңеләеп китәм, йөгерәм,
Сабый төсле көләм, шатланам.

Йомшак карны алып йомарлыйм:
«Бер уйныйсы иде кар атып!..»
Йомарлагым чөям еракка —
Бала чакка табан каратып...

Гашыйк булгангадыр тормышка,
Сөенәм мин юкка-барга да;
Кар шикелле ап-ак чәчәккә,
Чәчәк кебек ап-ак карга да.

Үз урынында матур кышлар да,
Кызыклары аның азмы соң?
Күзем камашырлык ак булып,
Күз алдыма килә язмышым.

...Ап-ак карда йөрим, тышта шәп.
Яз киләсе булгач — кыш та шәп!

*Октябрь, 1960*

## Җирдә ята икмәк сыныгы...

Юлда ята икмәк сыныгы,
Юк аңарга күз дә салучы;
Җирдә ята икмәк сыныгы,
Юк иелеп шуны алучы...

Кайнашса да, монда көн буе,
Күрми аны бала-чагалар;
Тамак та тук, өс тә бөтен шул,
Шырпы кабы эзләп чабалар.

Яна өйләнешкән парның да
Күңел күзе түгел икмәктә —
Шифоньерда, биек көзгедә,
Кандилләрдә — башка хикмәттә.

Авыр еллар күргән агай да
Күрми узды икмәк кисәген,
Онытып бара ул да кадерен,
Бүтән нәрсәләрдә исәбе...

Җирдә ята икмәк сыныгы,
Әллә рәнҗеп, әллә үпкәләп.
Чуар күлмәк кигән үсмерләр
Шаярышып китә, типкәләп...

Юлда ята икмәк сыныгы,
Һаман шулай ятыр шикелле.
Ята икмәк, сугыш беткәчтен
Онытылган батыр шикелле...

*Октябрь, 1960*

## *Туры Тукай*

Ул ятим дә, ул мескен дә диеп
Сөйләнелгән элек-электән,
Күз алдына аны боек итеп
Китерергә күпләр күнеккән.

Әйтерсең лә Тукай бар гомерен
Арка туңып кына яшәгән?
Ләхәүләсен укытып Ишмиләрнең
Яшен булып шагыйрь яшьнәгән!

Әйткән сүзе — аткан угы һәрчак
Туры тигән, читкә китмәгән,
Зирәк халык аны юкка гына:
«Туры Тукаебыз» димәгән!

Мескен халык,
мескен хаклык булмый,
Мескен шагыйрь була дисеңме?
Батыр дигән сүзгә рәттән куйыйк
Тукай дигән горур исемне!

Якты йолдыз булып атылган ул,
Зәгыйфь чәчәк булып сулмаган.
Туры Тукай, моңлы Тукай булган,
Бөек булган, боек булмаган!

Тукай — остаз, безне өйрәттең син
Халкыбызның улы булырга,
Һәр сулышта, һәрбер җырыбызда
Үзең кебек туры булырга.

*Ноябрь, 1960*

## Чулпы чыңы

«Китап сатып алыр өчен, әни... Һади абыйга үзенең чәченә үреп йөри торган тәңкәләрен бирәм-бирәм бирә торган иде».
*(Хәнифә Такташева истәлекләреннән)*

Чылтыр-чылтыр чулпы чыңлавы...
Елтыр күзле малай бишектә,
Биләүләрдә яткан чактан ук,
Шушы җырны Һади ишеткән.

Таныш көйләр һаман чыңлаган,
Таныш чыңнар бер дә тынмаган.
Йөрәгенә моңын сеңдереп,
Тыңлаган да Һади тыңлаган.

Сөйләшәләр нидер тәңкәләр,
Серләшәләр нидер тәңкәләр.
Тәңкәләрнең телен кем белгән,
Бала күңлен белә әнкәләр.

...Уеннарын ташлап, беркөнне
Чабып керә Һади ишектән:
— Бик кызыклы китап саталар,
Алыйк әле, әнкәй, ничек тә!

Шәмсениса апа ни дисен,
Юк акчаны кайдан аласы?
Зәңгәр күзен төбәп, ялварып,
Өметләнеп тора баласы.

Чылтыр-чылтыр чулпы чыңлавы
Тынып кала ана кулында.
Ана кулы — калын толымда,
Толымдагы тәңкә — улында...

Ничәнче кат Һади шатлана.
Ничәнче кат Һади очына —
Ничәнче кат инде әнкәсе
Көмеш тәңкә сала учына.

Күзен алмый ана улыннан,
Күзен алмый улы китаптан.
Тәэсирләнеп йөри ничә көн —
Күңелендә яңа көй тапкан...

Аһаңендә чорлар чыңлавы,
Бик борынгы җыр-моң яңара,
Мәйданнарга чыга даһилар,
Гасыр белән бергә янарга...

*Ноябрь, 1960*

# 60 нчы еллар

* * *

Икәү генә үткән сукмаклар бар,
Икәү генә менгән үрләр бар.
Икәү генә йөргән тугайлар бар,
Икәү генә белгән серләр бар.

Икебезгә килгән мәхәббәт бар,
Икебезгә дигән көннәр бар.
Икебезгә уртак гомерләр бар,
Бездән бәхетлерәк кемнәр бар?!

*Февраль, 1961*

## *Кырга чыксам*

Бабайлардан килгән кан ашкына,
Иркенлеккә мине чакыра —
Кырга чыксам, уйлар канатлана,
Күңелемдә җырлар яктыра.

Басуларның саф һавасы белән
Чистарганда каннар, үпкәләр,
Онытыла тормыш ваклыклары,
Күңелдәге рәнҗү, үпкәләр...

Нәрсә җитә басу юлларында
Моңны җырга, көнгә ялгауга —
Табигатьтә бар да табигый шул,
Юк гайбәт тә монда, ялган да.

*1961*

## *Бабайлардан калган...*

Игенченең исе китмәгән шул,
Начар булган «архив» яклары;
Сакланмаган өйдә эткәйнең дә
Шахталардан салган хатлары...

Бабай язган васыять кәгазен дә
Куралмадым, — күптән җуйганнар;
Әллә шунда кыяр орлыклары,
Теш карасы төреп куйганнар...

Борынгылар җыйнак булмаган, дип
Әйтер идең, алар аклана:
Шкаф өсләрендә төргәк-төргәк
Налог кәгазьләре саклана.

Йөз саргайткан сары кәгазьләргә
Карап утырдым да буш чакта,
Тузан җыеп аунап ятмасын дип,
Илтеп аттым янган учакка.

Йодрык-йодрык мөһер сурәтләрен
Утта яндырдым мин үч итеп;
Карап тордым кызыл ялкыннарга,
Бабайлардан калган төс итеп...

*Март, 1961*

## Тыйнвар яңгыры

Яз төсләре инде офыкларда,
Вак яңгырлар карны тиштеләр,
Юешләнде юллар, рәшәткәләр —
Язгы көннәр искә төштеләр.

Искә төште бозлар айкалган чак,
Су җәелгән чаклар болынга,
Әйтерсең лә карлы чыбык түгел,
Чәчәк аткан шомырт кулымда...

Тамчылар да, апрельдәге кебек,
Нинди якты, нинди тереләр!
Яз җиткәнме диеп, гаҗәпләнеп,
Күзен ачып карый бөреләр...

*Март, 1961*

## Май аенда яуган кар кебек

Март аенда яшен яшьнәп куя —
Кызык хәлләр була кайчакта;
Ишелеп-ишелеп әнә карлар ява,
Табигатьтә бүген май чакта.

Безнең тормышта да көтмәгәндә,
Бозылгалый шулай һавалар —
Кышларында яшен яшьнәп китә,
Җәйләрендә карлар явалар...

Мәхәббәтең синең —
кайнар кояш,
Охшатырга урын бар кебек:
Елмайдыңмы, ачуларым эри,
Май аенда яуган кар кебек!

*1961*

## «Казан сөйли!»

Унтугызынчы гасыр ахырында Казан шәһәрендә халык күп үлгәнлектән, рәсми статистика: 1960 елга Казан халкы үлеп бетәчәк, дип белдергән.

*(Календарьдан)*

Кара язмыш каркылдаган алар безгә:
«Озакламый шундый көннәр килеп җитәр —
Бер кеше дә калмас Казан каласында,
Казан халкы үлеп бетәр. Үлеп бетәр!»

Сезнең уйча, уралачак булган халык
Ак биләүләр белән түгел — кәфен белән...
Гасырларны үттек инде, ишетәмсез,
Саф татарча җырлап торам, әфәнделәр!

Сезнең уйча, Казан дигән таш каладан
Булган икән җансыз өем — таш каласы?
Тыңлыйсызмы, ишетәмсез: «Казан сөйли,
Республикам Татарстан башкаласы!»

Яши Казан һәм яшәрә, чибәрләнә,
Уңышлары белән илгә шаулый Казан:
Сөендереп, сокландырып, таң калдырып,
Җиребезгә яңа җиңү яулый Казан!

Киләчәктә таңнарының, даннарының
Якты, яхшы булачагын белә Казан;
Идел-диңгез көзгесендә үзен күреп,
Сезнең сүздән рәхәтләнеп көлә Казан!

Халкымның бар гөрләп торган таш каласы,
Бар әле аның зур-зур эшләр башкарасы.
Ишетәмсез: «Казан сөйли! Казан сөйли —
Республикам Татарстан башкаласы!»

*Март, 1961*

## *Тукай Кырлаенда*

### 1. Йөгереп чыгар кебек

Тукай-Кырлай авылы... Урамыннан
Тыныч кына ничек үтәсең,—
Кәләпүшен тотып, тыкырыктан
Йөгереп чыгар кебек көтәсең...

Аны сагынып, аны көтеп таллар
Еламсырап башын игәнме?
Ничек көтмәсеннәр — ишеткәннәр
«Ул һаман да яши» дигәнне.

Юксынса да таллар, моңаймасын,
Шомланырга урын калмыйдыр —
Ул һәр җирдә тансык, кайтыр юлга
Вакыт кына таба алмыйдыр...

### 2. Тукай каеннары

Урманнарда үскән пар каенны
Урамына язын күчергән,
Сусатмаган, инешләрдән ташып,
Кушуч белән сулар эчергән.

Авыл кызларыдай тыйнак кына,
Тату гына алар үскәннәр,
Ике игезәк, икәү җитәкләшеп,
Бик күп төннәр, еллар кичкәннәр.

...Ул язны да алар яфрак ярган,
Бөреләре җилдә яуганнар.
Күкрәп үсеп утырганда, кинәт
Шагыйрь кебек җиргә ауганнар...

### 3. Шагыйрь өе...

Кырлай урманында бүрәнәнең
Шәм шикелле шәбе табылыр,
Йомычкалар очар чирәмнәргә,
Пычкы чыжлар, балта чабылыр...

Исән чакта аның булмаган шул,
Утырып шигырь язган үз өе.
Озакламый монда салыныр, диләр
Шагыйрь өе — Тукай музее...

### 4. Горур башын түбән имәгән

Кулдан-кулга күчкән бала чакта,
Юлдан-юлга йөргән соңыннан;
Скрипка күк үксеп елар иде
Агачлар да аның моңыннан.

Үзем ятим диеп зарланмаган,
Халкым ятим диеп янган ул,
Горур башын түбән имәгән ул —
Һәйкәл булып басып калган ул!

*Март, 1961*

## Таң шатлыгы

Тантаналы офык белән бергә
Күңелләрем минем яктыра:
Таңнарының алсу таҗын киеп,
Күз алдымда туган як тора.

Җылы, рәхәт җилләр китерделәр
Дымлы туфрак һәм чык исләрен,
Яңардылар шулчак күңелемдә
Онытылып барган хисләрем.

Әллә кайчан ялгыз җырлап кайткан,
Сагындырган җырлар кузгалды...
Таң күрмичә әрәм үтеп киткән
Көннәремне бүген кызгандым.

Һәр көннең бар үзенең гүзәллеге —
Таңнар таңга бер дә охшамый,
Таңнар күреп йөргән кешеләрнең
Күңелләре җырдан бушамый.

*Март, 1961*

## Чәчәкләрне юлда таратсам да

Сөенсен дип, сиңа чәчәк җыйдым,
Күбәләкләр белән ярышып,
Каршы чыгып кызлар сузылганда
Ничек тормак кирәк карышып?

Болыннарда чәчәк бик күп әле,
Башларыңны түбән имә син,
Чәчәк белән бергә хисләреңне
Өләшкәнсең инде, димә син.

Чәчәкләрне юлда таратсам да,
Ышанычыңны мин аклaдым —
Йөрәгемә куллар үрелсә дә,
Мәхәббәтне сиңа сакладым!

*Март, 1961*

## Һавада очканда

Атна буе болыт булды,
Кызыгы, ай, аз икән...
Ә болыт артында — кояш,—
Һаман чалт аяз икән!

Кузгалыр җил, болытларны
Таратыр, куар әле;
Ачылыр күк, кояш җиргә
Елмаеп куяр әле.

...Күңелне дә күләгәләп,
Ваклыклар үтеп тора.
Бирешмә, кайгы артында
Шатлыклар көтеп тора!

*Июль, 1961*

## Тимерче Гомәр һәм гомер

(Баллада)

Маңгайга чак кына
Этәреп бүреген,
Елмая-елмая
Баса ул күреген.

Ул гомер-гомергә
Шушында эшләгән;
Кайчандыр әбигә
Ураклар тешәгән.

Тупсалар, йозаклар
Ясаган ул байга;
Шөшлеләр, пычаклар
Ясаган бабайга...

Сизә ул тәнендә
Шулкадәр җегәрлек —
Тагын бер Гомәргә
Гомергә җитәрлек!

*

Беркөнне аңарга
Әйтәләр уллары:
— Эшләмә, рәхәт күр,
Ял итсен кулларың!

Карышып карый да
Егетләр тыңламый —
Шул көннән Гомәрнең
Чүкече чыңламый...

Утыра болдырда
Кулларын кушырып;

Чүкечләр типми шул
Йөрәккә кушылып...

Ул һаман эшкә дип,
Уяна таң белән;
Уяна таң белән —
Чакырган чаң белән.

Нишләрсең, күзеңә
Һич йокы кермәсә;
Әнә бит, чаң ничек
Юксынып эндәшә...

Йомшыйлар буыннар,
Тимерче сыгыла,
Көннәрдән бер көнне
Аяктан егыла...

Гомәрнең йортыннан
Табиблар өзелми,
Сырхауның хәл мөшкел —
Яхшыру сизелми.

Күмердәй карала
Иреннәр шул чакта,
Сүрелә, сүнә лә,
Бер сүнә учак та...

Эх, басып булсачы
Гомернең күреген!..
Тимерче яңадан
Сорады бүреген.

Улына тотынып,
Басты ул аякка,
Куллары калтырап,
Таянды таякка:

— Торасым килә бер
Нигездә утырып,
Кояшка карыймчы
Күземне тутырып...

Күперне чыктыңмы —
Алачык — ул әнә!
Тимерче, атлыгып,
Шул якка юнәлә:

— Чыгасым килә бер
Түрендә утырып;
Учагын карыймчы
Күземне тутырып...

Күзләргә учактан
Очкыннар кабына;
Сандалга килә карт
Абына-абына.

— Улларым, бу сезгә
Иң соңгы үтенеч,
Чүкечне тотыйм бер,
Калмасын үкенеч...

Маңгайга чак кына
Этәреп бүреген,
Үрелеп, сак кына
Баса ул күреген.

Гөжелдәп кабына
Күмерләр учакта,
Көч кайта Гомәргә,
Кан уйный шул чакта!

Учагың сүнәргә
Иртәрәк, күрәсең,

Син үлгән гомергә,
Гомәр, җан өрәсең!

Егылмас ул бүтән —
Чүкече түнмәсә,
Сүнмәс күк тормышы —
Учагы сүнмәсә!

*

Йөрәк ул — юрга ат,
Тыйганны тоймасын,
Бәйгедә булсын гел,
Омтылып туймасын!

...Маңгайга чак кына
Этәреп бүреген,
Елмая-елмая
Баса ул күреген!

*Апрель, 1961*

## Сугышлардан калган мина...

...Әтиеңне мин фронтта күрдем.
Әйтми йөргән идем кайберен —
Алдына ук аның бомба төште...
Син эзләмә аның каберен...

...Күз яшемне йоттым эчтән генә,
Кайгыдан мин изрәп төшмәдем,
Кайгы килгән чакта, эткәй кебек,
Иренемне генә тешләдем.

Өйгә кердем.
Әнкәй син юрыйсың
«Атаң кайтыр!» — диеп төшеңне.
Унсигез ел элек югалткансың
Унсигез ел көткән кешеңне...

Бу хәбәрне сиңа җиткерергә
Сүз тапмадым, телем тартмады.
Сугышлардан калган мина булып,
Йөрәгемдә кайгы шартлады...

*1961*

## *Патша-туп бар Кремль уртасында...*

Патша-туп бар Кремль уртасында —
Күргәзмәгә күптән куелган;
Адәм башларына төшәр ядрә
Баш-баш итеп, зурдан коелган.

Заманында ул дәһшәтле булган,
Бер тапкыр да әмма атмаган;
Чуен бугазыннан үлем чыгып,
Аяк асларына ятмаган.

Карточкага төшә хәзер монда
Башкалага килгән кунаклар.
Кеше тынгач, бу борынгы тупка
Күгәрченнәр килеп кунаклар.

Аяз көннәр нинди яктылар да,
Тыныч сулар нинди тоныклар...
Атылмаган ракетаны шулай
Күрсә иде безнең оныклар!

*Июнь, 1961*

## Кулын кыса алмадым

Күзем җиргә төбәп, кул салынып,
Ялгыз утырам кәеф кырылып.
Янәшәмә кемдер килеп басты,
Карыйсы да килми борылып.

Уйнап-көлеп миңа сүз куша бу,
Узган-барганнарга эндәшә.
«Бар бит җирдә ваемсызлар» — диеп,
Шатлыгыннан аның көнләшәм.

Шактый шаян кеше булып чыкты.
Утырсам да башта иренеп,
Җан кертте бу минем телләргә дә,
Киттем мин да сүзгә бирелеп.

— Рәхмәт, туган, син булмасаң әле,
Утырыр идем кәеф кырылып!
Күзләренә карап җор егетнең
Кулын кысыйм дидем, борылып...

Утны-суны кичкән дәртле егет,
Ничә күрдем, һаман шук иде,
Кулын кысалмадым,
Ике кулы,
Ике кулы аның юк иде...

Дөнья тыныч түгел.
Юк, ярамый,
Җебеп калып күзне йомарга.
Буш җиңнәргә карап тешең кыс та
Исән кулларыңны йомарла!

*Июль, 1961*

## *Петропавел крепостенда*

### Казаматлар карап йөргәндә

Яманаты чыккан шомлы җир бу,
Күпме гомер монда сүнмәгән...
Намусыңны сатсаң — чыгарганнар,
Ләкин Кеше моңа күнмәгән.

Үлсә үлгән,
Себер юлларыннан
Богауларын сөйрәп атлаган;
Тик вөҗданга богау салдырмаган
Һәм йөрәген ул хөр саклаган!

Көн күрсәтми, кара табутларда
Тотсалар да күпме ялгызын,
Сукрайса да, Кеше югалтмаган
Алда янган өмет йолдызын.

Онытылмый андый батырлыклар —
Еллар юшкыннары басалмый.
Геройларга Алтын Йолдыз хәзер
Юкка гына монда ясалмый!

### Дары базларында

Стеналар әллә ничә аршын —
Әүвәл монда дары тотканнар.
Аннары соң дары базларында
Еллар буе яткан тоткыннар.

Сизгән залим:
Революционер ул
Хәтәр нәрсә, дары төслерәк.
Төшенмәгән ләкин: ярсу йөрәк
Шартлаткычлардан да көчлерәк.

Килгән бер көн, ничә гасырдан соң
Беренче кат халык шатланган;
Коткармаган калын стеналар —
Патша хакимлеге шартлаган!

**Булган заман...**

Батыр рухлы тере һәйкәлләрне
Таш капчыкка патша тутырган;
Бакыр бүкән кебек, тере мәет
Мәйданнарда үзе утырган.

«Мәңгеләштең» дигән сүз түгел шул
Зур-зур сыннарыңның күплеге;
Тарих түрләренә тыкшынганны
Көтә һәрчак заман чүплеге!

**Кибальчич ***

...Тиздән аны дарга илтәчәкләр,
Булды попның соңгы вәгазе.
Кулларында, васыять язар өчен,
Кәфендәй ак төрмә кәгазе.

Һәм Кибальчич яза бәйнә-бәйнә,
Күк «капусын» ничек ачасын...
Нәкъ сиксән ел элек алдан белгән
Гагаринның күккә ашасын!

...Чертеж-васыятен алып аның
«Яшерен» дигән печать басканнар,
Ә соңыннан үзен — Рәсәй данын
Ул омтылган күккә асканнар...

* Н.И.Кибальчич — дөньяда беренчеләрдән реактив очкыч проектын эшләгән рус революционеры.

АКШтагы князь Гагаринның
Юк уртаклык һич тә табасы —
Галәмгә юл ачкан Гагаринның
Шул Кибальчич була бабасы!

### Бәхеткә без, ахры, күнегәбез

Төш җиткәчтен, сәгать уникедә
Туп гөрселди крепость ягында.
Шул тавышка карап, Ленинград
Сәгать дөресләгән чагында,—

Җан өшеткеч шыксыз казаматтан
Чыгып бастым Нева ярына.
Бүтән күзләр белән карадым мин
Тормышыма, көнгә — барына.

Тиешенчә шатланмыйбыз төсле,
Тиешенчә, гүя, көлмибез...
Ил ирекkә чыккач тугангамы,
Ирекнең без кадерен белмибез!

Бәхеткә дә, ахры, күнегәбез,
Күнеккәндәй һава суларга;
Ничә буын аны яулап биргән,
Без бурычлы, дуслар, шуларга!

...Төш җиткәчтен көн дә уникедә
Туп гөрселди крепость ягында;
«Көчле рухлыларга салют бу!» — дип,
Уйлап куйдым мин шул чагында.

*Июль, 1961*

## Юллар заманы

Офыкларда ак болытлар
Тагын яулык болгыйлар,
Тепловозның терсәкләре
Көпчәккә юл чолгыйлар...

Гел озату, гел вокзал дип,
Хафаланма, көрсенмә,
Кайтуларсыз калдырмыйм ич
Китүләрнең берсен дә!

Аерылып, ничә тәүлек
Юл барсам да тоташтан,
Корыч рельслар белән мин
Барыбер сиңа тоташкан!

Бик сагынсаң поездларны
Була кире борып та,
Кайберәүләр аерым әле
Гел-гел бергә торып та...

Мин күбрәк читтә йөрсәм дә,
Зур булса да арабыз,
Гомер юлларыннан һаман
Без янәшә барабыз!

*Июль, 1961*

## *Көньяк төнендә*

Төнне тотып торган текә таулар
Аксыл томан белән өртелгән,
Тау буена баскан кипарислар
Йолдызларга барып төртелгән...

Кайда гына тагын күрерсең син
Бу яктагы кебек кызыкны:
Диңгез, һава — тоташ, күреп булмый
Офык дигән таныш сызыкны.

Пароходта янган утлар әллә,
Йолдызлармы әллә күз кыса?
Ярда калган маяк «кайт...кайт» диеп,
Шул якларга карап сүз куша.

Бүтән утлар белән буташтырмыйм,
Сәфәр чыксам да мин кай якка —
Туган ярга, сөйгән ярга кайтам —
Мәхәббәтем дигән маякка!

*Июль, 1961*

## *Могҗизалары сөюнең*

Яшәгәнсең, гүзәл дигән
Даннарың таралмаган,
Күзеңә керердәй булып,
Егетләр карамаган...

Могҗизалары сөюнең,
Серләре бетәр микән,—
Икәүдән-икәү калганда,
Син бит бөтенләй бүтән!

Күз алдымда үзгәрәсең,
Нурланып яктырасың,
Нигә шундый гүзәллекне
Яшереп яткырасың?!

...Ай кояштан нурлар ала,
Матур була тулганда:
Гомергә чибәр йөрерсең,
Мәхәббәтең булганда!

*Июль, 1961*

## *Төннәрен дә уза яшьлек*

Тартып-тартып гармун уйна,
Сузып-сузып җырлыйк бер,
Черем иткән чибәрләрнең
Йокыларын урлыйк бер.

Серле күзләрен ачсыннар,
Юрганнарын типсеннәр,
Иртәгә иртә ятмаска
Бүген тәүбә итсеннәр.

Капка төпләренә җиткәч,
Катырак бас бакасын:
Моңландырсын анасын да,
Уйландырсын атасын!

Сузып-сузып уйнап җибәр,
Җырлыйк әле хор булып:
— Төннәрен дә яшьлек уза,
Йоклап ятма хур булып!

Ятма ястыкка сыланып,
Мамык мендәр кочаклап,
Бернинди сәбәп белән дә
Булмый моны һич аклап!

... Җырлыйсы килеп китте бер
Чын-чынлап юри генә.
Рояльләр өйдән чыгалмый,
Гармуннар йөри менә!

*Июль, 1961*

## Бушка янмасыннар

Кара төндә алтын нурлар чәчеп,
Бушка янган утлар газ икән,
Карап торсаң — үзе сокланырлык,
Рәсем итеп тот та яз икән...

Мәгънәсезлек шулай купшы була,
Ә без мактап җырлап йөрибез,
«Каравыл...» дип кычкырасы чакта,
«Урра!» диеп зурлап йөрибез.

Азмыни соң тышкы бизәкләргә
Маңгай күзе йөри алданып;
Шуңа күрә, җырга ялган керә,
Хакыйкатькә шома ялганып...

Ачынуны, минем борчылуны
Каләмдәшләр дөрес аңласын;
Замандашлар күңлен җылытсын дим —
Йөрәкләр дә бушка янмасын!

*Июль, 1961*

## Мәхәббәтемә

Үләрмен мин болытлы бер көнне,
Күңелләрем шулай сизенә.
Мин яшәсен дисәң, кояш күрсәт,
Илһамымны уят тиз генә.

Коткаралсаң тик син коткарырсың,
Табиб халкы моны белми ул:
Кояш барда илһам якын йөри,
Илһам барда шагыйрь үлми ул!

*Июль, 1961*

* * *

Үкенечле булыр, көтмәгәндә
Гомер җебе китсә өзелеп,
Күңелемдә җырланмаган җырлар
Чират көтеп калса тезелеп...

Шулкадәрле әйтер сүзем барда,
Мин дәшмичә ничек чыдармын?
Чыдый алмам, язлар килгән саен,
Чәчәк булып үсеп чыгармын!

*Июль, 1961*

* * *

Мәхәббәткә сусап йөргән чакта
Чишмәсенә килеп юлыктым.
Йотылып-йотылып эчтем хисләрне,
Бар дөньямны шулчак оныттым.

Кайнар чүлдә калган юлаучыга
Бик ихтимал минем охшавым —
Эчкән саен эчәм, һич басылмый,
Арта гына бара сусавым!

*Сентябрь, 1961*

* * *

Кыраулар да үткән, кырпак төшкән,
Кар түшәлгән инде бакчага.
Пешми калган борыч кузаклары
Менеп тезелгәннәр матчага.

Яшел помидорлар мич башында,
Итек балтырында кызара.
Орынып үтсәң, суган үремнәре
«Кыш-ш...» дип пышылдаша үзара...

*1961*

## *Очрашкач беренче сүз*

*Ерактагы дусларга*

Килдек без Идел иленнән —
Татарстан җиреннән.

Дуслык хакын хаклап килдек,
Уртак юлдан атлап килдек,
Якын итеп, сагынып килдек,
Кошлар кебек кагынып килдек.
Колач җәеп көткән дуслар,
Туганнарча үпкән дуслар,
Күптән таныш, күптән дуслар,
Бергә гомер иткән дуслар —
Исәнмесез,
Исәнмесез!

Мең еллык җырлары булган,
Баһадир уллары булган,
Кояшлы юллары булган,
Шатлыклы еллары булган,
Идел мәңге аккан яктан,
Татар бәхет тапкан яктан,
Тукайга моң биргән җирдән,
Сәйдәшкә дәрт биргән җирдән,
Мусага көч биргән җирдән:
Сәлам сезгә,
Сәлам сезгә!

*Ноябрь, 1961*

## Кызыгып кайтам

Урам буйлап яшьләр килә,
Йөгерешеп, шаярып;
Сөйләшәләр яңгыратып,
Көләләр һава ярып.

Киләләр буран уйнатып,
Көртләргә чума-чума.
Мин кайтам инсафлы гына.
Борыным туңа-туңа...

Кызыгып кайтам. Юкса бит
Бер чама яшебез дә.
Кайчакларда эчпошыргыч
Тәртипле яшибез лә!

*Ноябрь, 1961*

* * *

Мең аерылу бар йөрәктә,
Мең кавышу бар йөрәктә.
Дәшми йөргән мең кешенең
Мең тавышы бар йөрәктә.

Сыеныйм дигән күңелләргә
Йөрәгемдә мең урын бар;
Чикләмәгез йөрәгемне,
Мең язмышка
мең җырым бар!

*Декабрь, 1961*

## *Кол Галигә*

Сигез гасыр элек җырларыңны
Яраткан да халык, ятлаган,
Шуннан бирле аны онытмаган,
Күңелендә көйләп саклаган.

Каерылган күпме канатларның
Каурыеннан каләм очладың?
Көнләгәнсең әле: шул кошлардай
Ник иректә бераз очмадым...

Кушаматың нигә «Кол» икән дә,
Кемнәр сиңа богау кидерде?
Мәхәббәтең — җырның канатлары
Сине азат көнгә китерде.

Күңел белән күрәм мин барыбер
Колларыңны бәйсез кул итеп;
Галине дә мөмкин кол итәргә,
Чын шагыйрьне булмый кол итеп!

*Февраль, 1962*

* * *

(Больницага язган хаттан)

Тимә, сырхау, Хәсән абыйга*,
Хуҗа булма анда, кит түрдән;
Зәңгәр күкне тимер челтәрдә
Бүлгәләнгән килеш күп күргән...

Тотма, сырхау, Хәсән абыйны,
Ишекләрне тагын бикләмә,
Елмаюын аның сагындык,
Хатлар белән сүзен чикләмә.

Җибәр, сырхау, Хәсән абыйны,
Ятим күңел үзен юксына...
Казан кояшына күз кысып,
Колач җәеп тизрәк чыксын ла!

*Февраль, 1962*

* * *

Шәһәрләрдән, шигырьләрдән арып,
Арыш кырына кайтып егылдым.
Офыкларда рәшә уйнагандай,
Күзләремә яшьләр тыгылды...

Сез шагыйрьдән бүген җыр көтмәгез,
Үзе өчен генә моңлансын;
Үзе өчен генә бер җырласын,
Арышларын кочып җыласын...

*Июнь, 1962*

* Хәсән Туфан.

## *Аталы-уллы солдатлар*

(Баллада)

Сугыш пыскып сүнгән җирдә,
Бик ерак якта,
Аталы-уллы солдатлар
Торалар сакта.

Егерме ел алмашмыйча
Тора атасы.
Улы килгән өченче ел,
Быел — кайтасы.

Күңеле сизгер егетнең,
Күзләре үткер.
Һәйкәл-әткәй, дәшмәсәң дә,
Сүзләрең күптер...

Җиңүгә ул тик бер адым
Барып җитмәгән.
Аның өчен әле һаман
Сугыш бетмәгән.

... Ике сагынуны алып,
Улы кайтасы.
Алмашынмас сакта торып
Кала атасы.

*Май, 1962*

## Кыя һәм Кеше

(Баллада)

*Хәсән Туфанга*

Диңгез ярында
Алар икесе;
Торалар бергә —
Кыя һәм Кеше.
Кыя — мәңгелек,
Какшамаслык таш.
Тамыры белән
Тауларга тоташ.
Ә Кеше яшь-яшь,
Үзе бик чандыр.
Күзләре уйчан,
Нигә уйчандыр...
Өермәләрне
Сизми дә Кыя.
Кешене җил дә
Кузгатып куя...
Давыллы еллар
Екмасмы аны?
Көрәш диңгезе
Йотмасмы аны?

Эндәшә Кыя:
— Егет-егетем,
Пос син ышыкка,
Тыңла үгетем!
Беләм, карышып
Файда юклыгын...
Эх, булса синдә
Кыя ныклыгы!
Мин бит — мәңгелек,
Какшамаслык таш.
Тамырым белән
Тауларга тоташ!

*

Ул көннәрдән соң
Күп еллар үткән.
Дауларда Кеше
Күп юллар үткән.
Кырык давылда
Чайкалган Кеше,
Кырык батып та
Сау калган Кеше.
Чәче — ак дулкын,
Үзе гел чандыр...
Бу якларда ул
Булган кайчандыр.

Бүген дә алар
Тагын икесе:
Торалар бергә —
Кыя һәм Кеше.
Күптәнге бәхәс
Инде чишелгән —
Кыя яртылаш
Иңгән, ишелгән...
Сизә, карышып
Файда юклыгын:
— Эх, булса миндә
Кеше ныклыгы!..

Сораган Кыя:
— Әйт, Кеше, сөйлә,
Мондый көч сиңа
Кайлардан килә?
Һәм Кеше әйткән:
— Кыя, кыя-таш,
Йөрәгем минем
Халыкка тоташ!

*Май, 1962*

## Яңгыр ява...

Яңгыр ява, яңгыр ява,
Рәхәтләнеп, биеп ява,
Шатландырып, шаулап ява,
Күр, чистарып китте һава!

Яшәү биреп, ямьнәр биреп,
Тере суы иңә күктән.
Яусын, яусын, сеңеп яусын,
Бар тереклек күптән көткән.

Шундый кызык, шундый хозур,
Каралтыга ник керим мин,
Тәнгә сихәт, җанга рәхәт —
Шул яңгырда гел йөрим мин.

Табигатьне туендырып,
Болыт җиргә яңгыр сава.
Сусаганнан яңгыр шифа,
Саргайганнан яңгыр дәва.

Куенымнан яңгыр ага...
Кинәт мин сискәнеп китәм —
Радиоактив түгел микән,
Күктән афәт иңми микән?

*Июль, 1962*

## *Имгәнгән күңел*

Йөрәген ул һаман саен
Тыеп килгән,
«Ярамый!» — дип, төрле чикләр
Куеп килгән.

Акыл биргән үз-үзенә:
Эчтән тын, дип,
Сүзең — көмеш, эндәшмәвең —
Чын алтын, дип.

Инде хәзер теләсә дә
Кузгалалмый,
Дәрт булыр, дәрман бирерлек
Сүз табалмый.

Тынмаган да, ашкынуын
Ул ашкына,
Бик кыюсыз, сабыр гына,
Юаш кына...

...Офыкларны иңләп-буйлап
Очар бөркет
Чыпчык булып чүпли хәзер
Җирдә бөртек...

*Август, 1962*

## Тик аны гына сөйлә

Сөйлисең миңа ул кызның
Килешмәгән якларын,
Саныйсың кимчелекләрнең
Эреләрен, вакларын.

Сизәмен: телисең бугай
Күңелне суытырга;
Синеңчә, андый кешене
Тиеш мин онытырга.

Рәхәтләнеп тыңлыйм сине;
Нәрсәләр генә димә —
Тик аны гына телгә ал,
Тик аны гына сөйлә!

*Август, 1962*

* * *

Әй күп тә соң, диңгез, тозлы суың!
Ә бәлагә килеп юлыксаң,
Дулкын арасында тилмерәсең
Ирен чылатырлык су юктан...

Кай арада тормышта да шулай:
Таныш-белеш тә күп тирәңдә,
Табалмыйсың әмма бер йотым хис,
Кайгы тозы җанга тигәндә...

*Сентябрь, 1962*

* * *

Күрәсеңме зәңгәр һаваларны,
Зәңгәрлеге карап туймаслык.
Күрәсеңме минем сөенечне,
Зәңгәр һаваларга сыймаслык!

Зәңгәр офыкларга ак каеннар
Якты нурлар булып сузылган.
Әле генә чыккан сыман идек,
Күпме гомер инде узылган...

Икәү бергә чакта шундый рәхәт,
Көн үткәнне сизми күңелләр;
Сизелмичә үтсә, үтсен, әйдә,
Синең белән үтсен гомерләр!

*1962*

* * *

Су читенә төшеп чишенә кыз,
Җәлеп итеп бөтен халыкны;
Авыз ачып кала барлык ирләр:
— Биргән икән Ходай байлыкны!

Сокланып һәм мактап карачыны
Әле бик күп күрерсең, иркәм.
Япа-ялгыз шушы гүзәллекне
Ничек саклап йөрерсең икән?

*Сентябрь, 1962*

* * *

Дулкыннарда сугыш шаулаганга
Күпме гомер инде үтмәгән,
Ә шулай да, балык белән бергә,
Мина чыга кайчак ятьмәдән.

Шартлаткычын борып алганчы, ул
Эзләп йөргән һаман корбанын.
Күрсәк иде, дөнья халкы җирдә
Сугышның да муенын борганын!

*Сентябрь, 1962*

* * *

Карадагны сүнгән вулкан, диләр,
Миллион еллар элек ут булган.
Кем әйталсын, нинди матурлыклар
Диңгез төбенә китеп юк булган?..

Планетабыз — кызган вулкан төсле,
Утлы ташлар кинәт яумасын,
Айга буе җиткән кешелектән
Кара таулар гына калмасын!

*Сентябрь, 1962*

* * *

Мамай Курганында мәңгелек ут
Ялкынланып яна һаман да.
... Сугыш дигән афәт беткәч җирдә,
Бездән соңгы тыныч заманда.

Син сүндермә, Кеше, бу ялкынны,
Янып торсын шулай ялт итеп;
Шәһитләрне онытмаска диеп,
Сезнең исемнән дә ант иттек!

*Сентябрь, 1962*

* * *

Карлы басуларда тургай сайрый,
Уҗымнарны җырлап терелтә,
Нурларны да шул яктырак итә,
Март бозын да шулар эретә.

Кояш янында ук тургай сайрый,
Юлда туктап тыңлыйм, кымшанмыйм.
Тургай сайрап кына салкын карлар
Эрисе юк, димә, ышанмыйм!

*Сентябрь, 1962*

* * *

Илне тукландыру синең өстә,
Синең кулда халык язмышы.
Күпме яну, борчу белән үтә
Җәйгесе дә эшнең, язгысы...

Әйе, агай, җаваплылык синдә
Министрдан һич тә ким түгел.
Министрлар алар алмашына,
Игенчедә андый чин түгел!

*Сентябрь, 1962*

* * *

Озак йөреп туган якка кайттым,
Кардәш-ыруларым саулармы?
Гаҗәпләнеп карыйм тар инешне,
Кечерәеп калган тауларны.

...Бераздан соң күрдем:
якташларым
Сынатмыйча еллар кичкәннәр;
Таулар кечерәйгән, ә кешеләр,
Ә кешеләр — нинди үскәннәр!

*Сентябрь, 1962*

* * *

Рәхмәт сиңа, безне ашатучы,
Рәхмәт сиңа, безне яшәтүче,
Рәхмәт сиңа, илгә көч бирүче,
Рәхмәт сиңа, иген үстерүче!

Насыйп булсын иде илгә-көнгә
Синең кебек хезмәт итәргә;
Сине олылап җирдә бар халыклар
Табын саен икмәк күтәрә!

*Сентябрь, 1962*

* * *

Гади генә шушы кырларымның
Нинди хикмәтләре бар икән;
Куна-төнә эшләп арыганда да,
Җаным белән монда ял итәм.

Ниләр генә сөйләшенми икән
Басу белән икәү калганда...
Иң бәхетле чагың кайчан дисәң,
Иген кырларыннан барганда!

*Октябрь, 1962*

* * *

Кырга чыксам, җаным рәхәтләнә.
Иркенлеккә күңелем күнеккән;
Бу туфрактан күпме моңнар туган,
Ничә буын монда көн иткән...

Әллә шуңа, әллә бүтән сәбәп,
Түзә алмыйм хисләр ташуга;
Мәҗлесләрдә җырламаган кеше,
Җырлап җибәрәм мин басуда!

*Октябрь, 1962*

* * *

Кайнар комга килеп утырам да,
Сабый төсле, суга таш атам.
Диңгезне мин дулкынланып торган
Арыш басуына охшатам.

Күз алдыма килә офыкларга
Мөлдерәмә иген тулганы.
Кеше шулай инде, яратучан
Сөйгәненә охшаш булганы...

*Октябрь, 1962*

* * *

Кояш исе сеңгән чәчләреңнән
Ник бер генә тагын үпмәдем?
Күкрәгеңә төшкән толымнарны
Ник бер генә тагын сүтмәдем?

Ник бер генә тагын сүтмәдем дә,
Ник бер генә тагын үрмәдем?
Сагынырмын диеп белмәдем шул,
Үкенермен диеп белмәдем...

*Октябрь, 1962*

* * *

Салкын һава тынны куырып ала,
Әче җилләр битне өтәләр.
Кыш үтмәстер төсле. Ә уҗымнар
Сабыр гына язны көтәләр.

Кар астында һаман эңгер-меңгер.
Кышкы айлар, ай-һай, озыннар...
Күктә кояш барга ышанганга,
Яз килерен белә уҗымнар.

*Октябрь, 1962*

* * *

Сугышка дип чыгып киткән иргә
Кайтыр юллар булу икеле.
Ирләр халкы каты күңелле шул,
Бер дә исе китми шикелле;

Соңгы тапкыр таныш урамнарны
Күкрәк киереп урап йөриләр,
Дәшми үтсәк, ялгыш еларбыз, дип,
Сузып-сузып җырлап йөриләр...

*Октябрь, 1962*

* * *

Исәннәрнең исенә төшереп,
Утта үткән еллар хакында —
Һәр кешене күздән кичереп,
Солдат тора юллар чатында.

Булсын безнең гомер юлы да
Алар үткән юлга ялгарлык;
Һәйкәлләрнең күзенә тартынмый,
Кызармыйча туры карарлык!

*Октябрь, 1962*

* * *

Текә кыяларның кәрнизеннән —
Упкын кырыеннан юл бара.
Бормаланып бара-бара да ул
Болытларга кереп югала.

Аска карыйм — биек дигән таулар
Нинди нәни булып калганнар.
Мин үтәргә куркам бу юллардан,
Ә кемнәрдер шуны салганнар!..

*Октябрь, 1962*

* * *

Сапун гора — Сабын тавы икән,
Тайгак икән аның балчыгы.
...Яңгыр кебек яуган ул елларда
Бу җирләргә корыч ярчыгы.

Җиргә сыенып алга үрмәләгән
Солдатларны гүя күрәм мин.
Алар моннан шуышып үткәнгә дә
Йөрим бүген аягүрә мин...

*Октябрь, 1962*

* * *

Яр буенда янган барлык утлар
Таң алдыннан күзне йомалар.
Сулык-сулык типкән йөрәк кебек
Яна маяк — тынгы юк аңар.

Өмет уты шулай янадыр ул,
Өмет уты шулай сүнмидер.
Маяк кебек йокламыйча җирдә
Күңел көтә һаман кемнедер...

*Октябрь, 1962*

* * *

Хушлашкачтын һәрчак үкенәсең,—
Артык ашыктың күк тоела.
Бик урынлы икән юл чыкканда
Утырып ала торган бер йола...

Туган бусагадан атлаганчы
Тынып, сабыр уйга калыйк бер,
Соңгы юлга сәфәр чыкканнарны
Сүзсез генә искә алыйк бер...

*Октябрь, 1962*

* * *

Уллар әйтә: «Яхшы — юлларның
Мин күрмәгән якка киткәне».
Кызлар әйтә: «Яхшы — юлларның
Сөйгән ярым ягына илткәне».

Ата-ана көн дә һәр иртә
Каерып ачар иде капканы;
Әйтер иде: «Яхшы — юлларның
Туган якка алып кайтканы!»

*Октябрь, 1962*

## *Нәсыйхәт*

Исәннәрнең кадерен бел,
Үлгәннәрнең каберен бел!

*16 март, 1963*

* * *

«Халкым!», «Халкым!»
дигән сүзләреңне
Уңга-сулга сибеп талпынма.
Синең әйтү генә җитми әле —
«Улым!» дисен сиңа халкың да!

*Март, 1963*

## Җир язмышы

Җир язмышы — һәрчак ил язмышы,
Ил язмышы ул — ир язмышы.
Бу заманның безне бөтереп алган
Кырыс давыллары азмы соң?

Илгә килгән — иргә тими калмый,
Түзалмасаң үзеңә үпкәлә.
Чебен генә кыен вакытларны
Мәрткә китеп качып үткәрә.

*Март, 1963*

* * *

— Ир-егеткәй, нигә йокламыйсың?
— Йоклый алмыйм эчем пошканга;
Әллә ничек шунда, урынсызга,
Бер авыр сүз әйттем дусларга...

— Ир-егеткәй, нигә йокламыйсың?
— Йоклый алмыйм эчем пошканга;
Әйтим дигән каты сүзләремне
Әйтә алмый калдым дошманга.

*Март, 1963*

* * *

Үкенечле мәхәббәтләр көчле була,
Таһир-Зөһрә, Ләйлә-Мәҗнүн төсле була.
Әгәр алар безнең көндә табышсалар?
Хәвеф-хәтәр, фаҗигасез кавышсалар?

Ярапышып көн иткәннәр азмы әллә,
Исе китмәс берәүнең дә мондый хәлгә?
Бәхет бит ул була күзгә чалынмаучан,
Бәхетлеләр була телгә алынмаучан.

*Март, 1963*

* * *

Сирәк күрәм сине. Очрашсак та
«Исәнме?»дән башка сүз булмый.
Күзләрнең шул сүзсез сөйләшүе
Озаккарак нигә сузылмый?

Сине күреп калган көннәр миңа
Кадерлерәк була барсыннан;
Тормышымда үзем белмәгән бер
Зур шатлыгым минем бар сыман...

*Апрель, 1963*

## Хәдичә

Кара күзле бер кыз бар иде,
Кара толымнары — тезеннән.
Моңа хәтле аның турында
Сөйләмичә ничек түзелгән?..

Язгы кояш кебек яктырып,
Хәтеремдә көлгән чаклары,
Гашыйк булып бөтен дөньяга,
Очып-очып йөргән чаклары...

Бигрәк матурланды ул елны,
Бигрәк чәчәк атты ул кышта.
Тик егетләр генә күрмәде,
Алар ул чак бар да сугышта...

Кара күзле бер кыз бар иде;
Фермадан ул кайтып кермәде.
Терлекләрен яхшы карады,
Үзен генә карый белмәде...

Кышы бигрәк салкын булды шул,
Алды җирне шактый тирәннән.
Алмагачлар, алмагачлар да
Үлде ул кыш салкын тигәннән...

...Кара күзле бер кыз бар иде...
Авылдашым минем — Хәдичә.
Истә һаман япь-яшь көенчә,
Түзәлмәдем сөйләп бирмичә.

*Июнь, 1963*

* * *

Сыбызгылар ясыйм балаларга,
Ошатырмы алар, хуплармы?
Бер узгынчы әйтә, вакланмаса,
Ташла, зинһар, җыен юк-барны!

Сыбызгылар ясыйм балаларга,
Сөйләсеннәр әле, әй, дәшмим;
Беләм ич мин; нәни сыбызгысы
Булган башта бөек Сәйдәшнең!

*Июль, 1963*

* * *

Бер сулыш тынды —
Бер кеше үлде,
Бер дөнья бетте,
Бер кояш сүнде...

Әнә бер бәби
Күзләрен уа —
Бер кояш чыга,
Бер дөнья туа!

Шулай ялгана,
Бу дөнья үлми,
Шуңадыр, бәлки,
Бу кояш сүнми!

*1964*

## Ике дус турында баллада

Иван Ильченко белән Бари Шәвәлиевнең якты истәлегенә багышлыйм.

Иван белән
Бари бергә
Сулар кичкән,
Утка кергән.

Тәмәкене
Бүлеп төргән
Һәм эзгә-эз
Басып йөргән.

Ир дуслыгы
Тыныч була,
Тыныч була —
Кырыс була.

Алда ДЗОТ—
Тимер калкан,
Күпме егет
Ята чалкан...

Фашист уты
Юлны бүлә,
Һәр адымга
Гомер түлә...

Бари, Иван
Карашалар,
Күзләр белән
Аңлашалар.

Сикереп торып
Утка таба

Икәүләшеп
Алар чаба.

Кочаклашып —
Гүя кушлар,
Пулеметка
Ава дуслар.

Кушыла бергә
Каннары да,
Рус, татарның,
Даннары да.

Ачыла юл,
Кача дошман.
Дошманнарга
Салып пошман,

Иван белән
Бари бергә
Әле һаман
Йөри бергә!

Гаҗәпләнмә,
«Йөри» дисәм,
Дуслар үлсә —
Дуслык исән!

Тыныч була,
Кырыс була,
Мондый дуслык
Корыч була!

*Август, 1961*

## *Дога*

Сине генә уйлыйм күккә
Карап мин,
Адым саен исемеңне
Кабатлыйм.

Мин бәндәңне нигә һаман
Кагасың,
Газаплаудан әллә кызык
Табасың?

Минем хәтле сиңа беркем
Табынмас,
Минем кебек табынганнар
Табылмас.

Теләкләрем сиңа барып
Ирешсен,
Бергә булыйк, җанкисәгем,
Килеш син!

*Август, 1963*

* * *

Игенчеләр
Тимер төрән белән
Җирне ерта —
Ниятләре изге.

Бакчачылар
Үткен пәке белән
Ботак кырка —
Ниятләре изге.

Докторлар да
Скальпельләр белән
Тәнне яра —
Ниятләре изге.

Әдипләр дә
Кайчак каләм белән
Чәнчеп ала —
Ниятләре изге!

*Февраль, 1964*

## Каен турында йөзенче җыр

Безнең туган якларда ла,
Ак каеннар ак карда;
Нурланып китә күңелләр
Каен күргән чакларда.

Сылукайлар, каенкайлар,
Алар мине таныйлар,
Күзләремә карыйлар да
Күңелемне аңлыйлар.

Яшьли сөйгән ярлар кебек,
Сез пакьләр дә, сафлар да;
Искә төшә шул көннәрем,
Сез очраган чакларда.

Сафлыксыз яши алмыйм мин.
Сафлыкны сагынам мин,
Сафлыкка мәңге гашыйк мин,
Сафлыкка табынам мин!

*Март, 1964*

## Бер кызга*

(Җыр)

Талпынып торган чагың да
Тупырдап торган чагың,
Гармун булса-булмаса да,
Тыпырдап торган чагың.

Язгы кояш кебек балкып,
Нурланып торган чагың,
Күңелдә үзеңнән-үзең
Җырланып торган чагың.

Йоклаган йөрәкләрне дә
Уята торган чагың,
Бар дөньяны онытгырып
Уйлата торган чагың.

Булмаган шатлыкларны да
Бар итә торган чагың,
Гомергә сөеп туймаслык
Яр итә торган чагың!

*Март, 1964*

* Рөстәм Зарипов музыкасы.

* * *

«Сөймәгәннән хат килсә,
Турап-турап суга ат —
Күңелләре суынсын.

Сөйгәнеңнән хат алсаң,
Дөрләп торган утка як —
Мәңге сүнмәслек булсын!»

...Кемдер әйткән ырым бу,
Ышанмыйм мин юк-барга.
Ә шулай да хатымны
Яктың, ахры... утларга.

*Январь, 1965*

* * *

Сиңа сөйләр күпме-күпме сүзләр
Еллар буе килгән җыелып!
Очрашасы иде, бер йөрисе иде
Сүзсез генә сиңа сыенып...

*Апрель, 1965*

* * *

Аерылганга шактый гомер үтте,
Оныттым да инде тавышың...
Әрнеттереп торган шатлыгым син,
Сөенечләр биргән сагышым.

*Апрель, 1965*

## *Тукайга*

Тормышыңда бәйрәмнәр аз булган —
Тартыш белән тулган көннәрең.
Шуңа, ахры, искә алынмыйча
Үткән синең туган көннәрең...

Бәйрәмнәрең алда икән әле,
Кара, шагыйрь, бүген текәлеп —
Халкың килде сиңа, мәхәббәтен
Ал чәчәкләр итеп күтәреп.

Син күрмәгән яңа буын килде,
Котлап бүген туган көнеңне,
Киләчәккә барган улларыңнан
Ишетәсең «Туган тел»еңне.

Буын арты буын алмашыныр,
Гасыр арты узар гасырлар.
Шигърияте өчен рәхмәт әйтеп,
Язлар сиңа гөлләр ташырлар.

Халык моңы — синең моңың булды,
Халык күңеле — синең күңелең.
Ил гомере, халык гомере кебек
Озын булсын, шагыйрь, гомерең!

*Апрель, 1965*

* * *

Әйттеләр,
Өйрәттеләр,
Күрсәттеләр,
Кисәттеләр,
Төзәттеләр —

Ничегрәк
Аңлау тиеш,
Нәрсәне
Җырлау тиеш?

Әйе, әдип
Беркайчан да
Битараф булмау тиеш.
Ә менә киңәшчеләрдән...
Вөҗданын тыңлау тиеш!

*1965*

* * *

Очрашу бар безгә, кавышу юк,
Күңелләрдә — моңлы җәрәхәт...
Ә шулай да җирдә син барлыкны
Тоеп яшәү үзе бер рәхәт.

*Июль, 1965*

## *Мин сине эзлим*

Әлегә сине
Күргәнем дә юк,
Янәшә атлап
Йөргәнем дә юк.

Кайда икән син,
Иң якын кешем.
Иң якын кешем —
Яратыр кешем?

Йөрәк ашкына,
Күңел талпына,
Сине юксына,
Сиңа тартыла...

Сиреньнәр өзсәм,
Йөрим күтәреп,
Узган бер кызга
Карыйм текәлеп,

Текәлеп карыйм,
Үзем дә сизмим.
Мин сине эзлим,
Мин сине эзлим!..

*Апрель, 1965*

## Хәтерлим*

(Җыр)

Җиләк өзеп бирдең син миңа
Һәм өздереп күзгә карадың.
Күзләреңнән сине аңладым,
Җиләкләрне генә алмадым...
Җиләк күргән саен хәзер мин
Уфтанам да сине хәтерлим.

Чәчләремә чәчәк кададың,
Иңнәремә кулың салмадың.
Әллә инде ялгыш аңладың —
Озатырга нигә бармадың?
Чәчәк күргән саен хәзер мин
Күрсенәм дә сине хәтерлим.

Бер сүз әйткән идең син миңа
Очраганда кабат кич белән,
Тынгы белмим инде һич кенә,
Һаман шуны уйдан кичерәм.
Хәтерлим мин, барсын хәтерлим,
Оныталмыйм сине хәзер мин...

*1965*

* Әнвәр Бакиров музыкасы.

* * *

Син чаңгыда җилпендең дә уздың,
Килә кабат борылып карыйсы;
Яңа гына пешкән алма төсе,
Яңа гына төшкән кар исе...

*Гыйнвар, 1966*

* * *

Яшь кыз күкрәгедәй саф, гөнаһсыз,
Беркем кагылмаган кар монда.
Күңелләрне хушландыра торган
Күктән иңгән пакьлек бар монда.

*Гыйнвар, 1966*

* * *

Көртләр ерып йөрим урамнарда,
Йортлар ак челтәргә урала.
Күңелләрне әллә нишләтергә
Әллә нәрсә бар шул буранда...

*Гыйнвар, 1966*

## *Муса елмаюы турында баллада*

Муса битендә
Тимерчыбыктай
Сагышлы сызык;
Үтә көннәре,
Үтә теш кысып,
Әрнеп тә сызып.

Караңгы күзләр,
Караңгы уйлар,
Караңгы чырай...
Сынарсың микән,
Сүнәрсең микән
Тоткында шулай?

Дошманнар көлә:
«Елмаюларны
Онытты Муса...»
Шаян сүз белән
Күңелләрне бер
Җылытчы, Муса!

Күтәрелсеннәр
Иелгән башлар,
Сыгылган иңнәр,
Йөзе яктырып
Аякка бассын
Егылган ирләр!

... Көйгән иренгә
Беренче тапкыр
Елмаю поса.
Ширпы утыдай,
Учында кәгазь
Яшерә Муса.

Сиздерми генә,
Шаян юлларын
Әсиргә суза.
Өметсезләрнең
Йөрәкләрендә
Ялкын кабыза...

Елмая йөзләр,
Яктыра күзләр,
Күрәмсең, Муса?
Елмайган кеше
Тормыш сөйгәнне
Беләсең, Муса!

Тормыш сөйгәннәр
Көрәшче була,
Сизәсең, Муса!
Ә көрәшчеләр
Бирешмәгәнне
Беләсең, Муса!

Әсир юк хәзер —
Яуга омтылган
Көрәшче көлә,
Җиңүгә өндәп
Чакырып торган
Юлларны күрә.

... Сизенә дошман.
Тик газаплаулар
Һәммәсе бушка.
Караңгы базда,
Таш капчыкта да
Елмая Муса.

Таш капчыкта да
Шигырьләр яза,
Елмая һаман.
Шомлана фашист,
Ул инде көлми,
Күрә, эш яман.

Елмаюны ул,
Диварга терәп,
Мылтыктан атар;
Эзе калмасын,
Югалсын җирдән
Бу хәтәр татар!

*

Илгә кайткан да,
Һәйкәлдән карап
Елмая дуска,
Елмая дуска
Җиңүче Муса,
Үлемсез Муса!

*Гыйнвар, 1966*

* * *

Каерып алып, суырып үптем —
Тойгыларым сүзгә сыймады.
Сугарга дип күтәрелде кулың,
Туктап яңагымнан сыйпады...

*Февраль, 1966*

* * *

«Онытырсың...» диден, ә мин,
«Онытмам» дип алдадым.
Дөресен әйткәнмен икән —
Аерылгач аңладым...

*Февраль, 1966*

* * *

Теңкәбезгә тиеп торалар,
Оныттырмый үзен юньсезләр;
Күз алдында синең гел шулар,
Шулар тирәсендә гел сүзләр.

Истән чыга яхшы кешеләр,
Игътибардан алар мәхрүмнәр,
Соңга калган җылы сүзләрне
Ишеталмый китә мәрхүмнәр...

*Март, 1966*

# *Ике язмыш*

## 1.Югалган шагыйрь

Китапларның да язмышы була.
*Борынгы мәкаль*

Ерак төбәктә, тын бер авылда
Яшь бер мөгаллим күзләрен йомды;
Кулыннан төште каурый каләме,
Яшь бер шагыйрьнең йөрәге тынды.

Юк, ул чак шагыйрь үлмәде әле!
Сөйгән ярында җырлары калды,
Яулыкка төреп сандыкка салды,
Качып укырга кулына алды.

Үтте күп гомер, саргайды кәгазь,
Саргайды кыз да, дөньядан кичте,
Көмеш чулпылар, җыр дәфтәрләре,
Истәлек булып, кызына күчте.

Яшәде кызы, баш күтәрмичә,
Мәшәкать, шөгыль азмы тормышта?
Борыннан килгән шәҗәрә белән
Шагыйрь йөрәге ятты тырыста.

Юк, ул чак шагыйрь үлмәде әле!
Ничәмә тапкыр калды янгыннан,
Туып та үсеп һәм дөнья куып,
Ничәмә буын үтте яныннан.

Укый белмәгән бер онык аны,
Әбидән калган дога дип белеп,
Әвернәләр һәм каба кырына
Кыстырып куйды, чормага менеп.

Юк, ул чак шагыйрь үлмәде әле!
Килер ул телгә, ал гына, укы.
Җырлар күптәнге, әмма бүген дә
Таныш андагы мәхәббәт уты.

Кешегә дигән күпме сөенеч
Онытылып ята, ята күмелеп,
Пәрәвезләрдән аны аралап
Аласы гына юкса үрелеп...

... Чынмы, ялганмы — хәбәр таралган,
Әгәр дә өйдән табалар икән
«Комган хәрефле» иске бер китап,
Тотып төрмәгә ябалар икән!..

Шүрләгән хуҗа, шагыйрьне дә ул
Тиз генә йолкып төшкән чормадан
Һәм китапларның барысын бергә
Киндерә белән кат-кат чорнаган.

Шагыйрь яраткан якты бер төндә
Айның батканын сагалап торган,
Авыр таш бәйләп чоңгылга аткан,
Җырларны шулай суга батырган.

... Куыклар гына чыккан бик озак,
Элмәктәй боҗра уйнаган күлдә.
Ерак төбәктә, өч йөз яшендә,
Ил белми калган зур шагыйрь үлгән...

*Март, 1966*

## 2. Билгесез кабер

— Болай булды бу. Армиядән мин
Утыз җидедә хат алдым өйдән:
«...шундый хәл монда, башкача булмый,
Китапларны мин озаттым»,— дигән.

Өстәгән эти: «Мин күрәлмәсәм,
Әниең әйтер, әйлән шул якка —
Булмабыз аннан без дә еракта,—
Борынгыларның урын зиратта...»

Кинаясен мин төшендем аның,
Кара син, нинди хәйләсен тапкан —
Мәрхүмнәр азат диеп тентүдән
Казып зиратка күмгән китаплар.

Сигез ел йөреп кайтып ирешсәм,
Әни бик авыр хәлдә — урында.
Күземә карый, сүз дәшә алмый,
Соңгы сулышын алды кулымда...

Зиярәт кылам, хәзер дә алар
Тормыштагы күк — янәшә бергә.
Кайдадыр тагын өченче кабер,
Күмелеп ята васыять-сер дә...

Эзләнеп, ташсыз түмгәкләрнең мин
Текәлеп карап йөрим һәрберен —
Күпме билгесез язмышлар ята,
Кайсысы шуның китап кабере?..

...Китапларның да язмышы була,
Китапларның да гомере була,
Китапларның да үлеме була,
Китапларның да кабере була...

*Март, 1966*

## *Минем гомер*

Минем гомер, нәсел җебе буйлап,
Бик еракка барып тоташа —
Килгән күпме үлемнәрне җиңеп,
Килгән күпме хәвеф, ут аша.

Гасырларны кичеп, миңа иңгән
Ерак бабаларның каннары,
Сеңгән аңа күз яшенең тозы,
Алсулыгы сеңгән таңнарның.

Кубыз, сорнай, гөслә моңнарыннан
Нечкәргәннәр күңел кыллары,
Ә күзләргә рәсем булып төшкән
Болгар сылуының сыннары.

Бөтен тарих үткән йөрәк аша,
Берсеннән дә читтә калмаган —
Гүзәллекләр аны иркәләгән,
Хаксызлыклар аны талаган.

Гомер арты гомер алмашынган,
Офык арты офык ачылган,
Тел очына килгән җыруларны
Әйталмаудан бабай ачынган.

Күңелләрдә калган бик күп хисләр
Бөреләнгән икән җыр булып;
Каләм төрткәч, гасыр төпләреннән
Чишмә сыман чыга ургылып.

Алар әйтеп өлгермәгәнне дә
Мин әйтергә бүген тиешле,
Шигырь ритмын бирә буыннардан
Күчеп килгән йөрәк тибеше.

Ничек миңа шуның кайнарлыгын
Һәм исерткеч дәртен тоймаска,—
Минем халкым мең ел куәт җыйган,
Яна-яна эшләп кояшта!

*Март, 1966*

## Тормыш сәхнәсендә

Иксез-чиксез зур бер сәхнә — тормыш,
Уртасында йөргәч тоймыйбыз,
Гомер буе шунда һәркайсыбыз
Үзебезнең рольне уйныйбыз.

Баш режиссер монда заман үзе,
Вакыт-гримче, карап яшенә,
Кемнәрнедер алсу битле итә,
Кемнеңдер чал кертә чәченә.

Өс-баш үзгәрүгә өлгералмый,
Костюмчылар тора офтанып.
Сөйләттермәк булып әзер сүзләр,
Суфлерлар да йөри буталып...

Көнгә-төнгә карамыйча, монда
Караңгылык була, яктылык;
Явызлыклар кайчак өстен чыга,
Соң булса да җиңә яхшылык.

Мохтаҗлык юк һич тә конфликтка,
Һәммәсе дә гаҗәп тормышчан;
Без һәрвакыт аның уртасында,
Үлгәнгәчә алып тумыштан...

Маскалар бар, киючеләр дә бар,
Яраталар әйбәт битлекне;
Елмаеп теш күрсәтә дә... тешли,
Бик астыртын эшли этлекне.

Бер күрүдә аерылса икән:
Кайсы уңай, кайсы тискәре...
Таный белү өчен кешеләрне
Карый белү кирәк эчкәре.

...Син дә шушы тормыш сәхнәсендә,
Үз хакыңда ничек уйлыйсың:
Үзеңә бер читтән кара әле,
Үзең нинди рольне уйныйсың?

*Март, 1966*

## *Сабыйга*

Ирнеңдәге сөт тамчысы кебек
Пакь әле син, сабый.
Бу йортта иң сафы —
Намуслы,
Тәүфыйклы,
Инсафлы.

Ят әле сиңа
Яклашу,
Белмисең
Яраклашуны,
Азат син
Мәкердән,
Икейөзлелектән,
Мәгънәсез үзсүзлелектән...

Син әле саф, сабый,
Тыныч ят,
Бишегеңне тарсынма.
Берзаман өйрәтерләр
Тәпи йөрергә,
Сөйләшергә,
Барсына, барсына;

Өйрәтерләр
Ялгыш юлдан йөрергә,
Ялган сөйләргә,
Эчәргә-тартырга,
Үз җаеңны көйләргә...

Өйрәтерләр,
Үзләре кебек итәрләр,
Аннары
Искелек калдыгы дип орышырлар,
Үзләре бозыклар киңәш бирерләр,
Төзәтергә тырышырлар.

Алай да, шүрләмә,
Арын biләүләрдән,
Тор син бишектән,
Зур дөньяга чык,
Төбенәчә ачып,
Тар ишектән!

Син әле саф, сабый,
Әшәкелек күреп дөньяны тарсынма,
Өйрәтә алырсың барсын да —
Сафлыкка,
Намуска,
Хаклыкка —
Яхшылыкларның барсына, барсына!

*1966*

* * *

Үткәннәрне уйлыйм да мин,
Үкенерлек хәлләр табам —
Ансы алай, бу болай дип,
Үземне битәрләп алам.

Үткән — беткән, бушка сыкрап,
Истәлекләр уятма син,
Үкенерсең озакламый
Бу көнеңне уйлап та син...

*1966*

## *Тормыш-көндәш...*

Киенә дә белә ул,
Кылана да белә ул,
Бик килешле итеп кенә
Сылана да белә ул.

Кояштай көлеп тора,
Каршыңда биеп тора.
Күргән кеше: шундый ярың
Булсачы, диеп тора.

Утында янар идем,
Бәхеткә санар идем.
Тормыш тоташ бәйрәм булса,
Мин аны сайлар идем...

*1966*

* * *

Ачуланган сүзләреңне
Тыңлап карыйсым килә,
Сагынуларга салып сине
Сынап карыйсым килә.

Ничегрәк булырсың икән,
Ирешсәм зурлыкларга?
Йөз чөермәссеңме икән,
Юлыксам хурлыкларга?

Моның һәммәсен белергә
Бер гомер кирәк икән...
Тормыш юлларына чыктык,
Сыната күрмә, иркәм!

*Март, 1966*

## Надан аяклар

Иңнәрең биетәсең,
Кашларың сикертәсең,
Елмаеп синең каршыңа
Чыкканымны көтәсең.

Бәхет үзе килгәндә,
Елмаеп кул биргәндә,
Кузгалмыйча басып торам
Дерелдәгән идәндә.

Кызарып башым иям,
Бии белмим шул, диям,
Артымда торган егеткә
Читкә китеп юл бирәм.

Берәрсе, бәлкем, яклар,
Ялкау түгел, дип аклар —
Сугыш вакытында шулай
Надан калган аяклар...

Инде читләп үтәсең,
Дәшмим, ни хәл итәсең —
Бии белгән аякларга
Син ияреп китәсең...

*Март, 1966*

## *Сөйгән ярым минем тылсымчы*

Ул югында дөнья сүрән, төссез,
Тирә-якны күпме күзләмә...
Ул килдеме, әкияттәге сыман,
Бер мизгелдә барысы үзгәрә;

Зәңгәрләнә күкләр, яктыра көн,
Каеннарның арта аклыгы,
Куакларда кошлар телгә килә,
Иңә җиргә таңның сафлыгы.

Йокымсырап, оеп йөргән чакта,
Килә дә ул әллә нишләтә —
Канны кайнарлатып, ут уйнатып,
Искитәрлек эшләр эшләтә.

Үзгәртә ул шулай бар дөньямны —
Сөйгән ярым минем тылсымчы.
Минем янга килсә ул тылсымчы,
Минем янда гына торсынчы!

*Март, 1966*

* * *

Күз күнекмәгән
Яңа җирләргә
Күңел тартыла,
Табардыр кебек
Эзләгәнен ул
Офык артында.

...Әйләнеп кайттым
Ерактан урап,
Күп җирләр гизеп.
Гаҗәпләндем мин
Таныш якларда
Үзгәреш сизеп.

Хыялымдагы
Серле дөнья күк
Текәлеп карыйм,
Гүя балачак
Яшергән татлы
Көннәрне таныйм;

Басулар өсте
Тетрәнеп торган
Сагыну тулы,
Тузанлы юллар,
Көпчәк эзләре
Рәхәт бер моңлы.

Тургайлар сузган
Кылга кагылып
Җил үтә көйләп,
Җыр очып чыгар
Кебек пырылдап
Арыштан кинәт...

Язларын кайткан
Кошлар тавышын
Искә төшердем,
Алар сагышын,
Алар шатлыгын
Яңа төшендем...

...Туган җирләрне
Сагыну көтә
Офык артында...
Күңел тартыла
Чит җиргә бары
Шуны татырга.

*Март, 1966*

* * *

Мин сине күрергә телим,
Күрергә генә,
Икәүләп йөрергә телим,
Йөрергә генә...

Бергәләп китәргә телим,
Китәргә генә,
Бәхеткә җитәргә телим,
Җитәргә генә...

Һәм гомер итәргә телим,
Итәргә генә.
Минем синнән теләгәнем
Бары шул, менә!..

*1966*

* * *

Җир баласы идем, үлән ашап,
Каеннарны имеп үскәндә,
Чишмәләрдән кайнап чыккан суны
Ташка ятып кына эчкәндә.

Җир баласы идем, чап-чап басып
Яланаяк йөгереп йөргәндә,
Җиргә якын, туфракка үз идем,
Салмак атлап сабан сөргәндә.

Куркасы юк кием буялыр дип,
Теләгәнче сузылып ят инде!
Киемнәре пөхтә вәкилләр
Безнең янда ул чак ят иде.

Мин үзем дә хәзер асфальт таптыйм,
Әмма шунсын үтим ачыклап:
Шигърияттә кырлар илчесе мин,
Игеннәрне кайтам тансыклап.

Җырларымны дөресләргә кайтам,
Сыенырга кайтам, җан тартып,
Толстой да яланаяк йөргән,
Җиргә якынлыкны яңартып...

Туган туфрагымнан, игенчедән
Яшим табигыйлек, көч алып.
Кайчан гына кайтып күрешсәм дә,
Ачык миңа кырлар кочагы.

*Май, 1966*

* * *

Сабыр диеп,
Тыйнак диеп,
Мактадыгыз безне
Аркабыздан сөеп,
Күкләргә чөеп.
Тыңладык без
Җылы сүздән оеп,
Горур башны
Түбән иеп.

Баксак —
Тынычландыру икән,
Юашландыру икән
Сезнең максат!

Шуңа күрә минем
Кызасым килә,
Тузасым килә,
Үзем турындагы
Шәп фикерне
Бозасым килә!

*Июль, 1966*

* * *

Мин үтәм урамнардан,
Күңелемә җыр тулган.
Әллә инде җыр тулган,
Әллә инде нур тулган,
Әллә инде син тулган...

Уйлыйм да мин сөенәм,
Кояшлы көн туганга,
Якты көнем булганга,
Якын кешем булганга,
Янымда син булганга...

*Сентябрь, 1966*

* * *

Борын заман гаҗәп тыныч булган —
Булса булган су һәм җил шавы.
Юллар озын...
Вакыт салмак аккан...
Галәмәт зур булган Җир шары!

Хәзер — үзгә...
Шар да бик бәләкәй;
Бер хәл булса берәр ягында,
Орынмыйча һич тә үтә алмый,
Йөрәгеңә килеп кагыла.

*Март, 1967*

## *Тукай васыяте*

Соңгы сулышта,
Үләр алдыннан,
Шагыйрь васыять
Әйтеп калдырган:

— Әсәрләремнән
Килер акчага
Тәрбияләгез
Бер ятим бала...

Ул чак бу теләк
Үтәлми кала,
Ачтан үлгәндер
Ярдәмсез бала...

Җуйдыртмады җыр
Ул васыятьне,
Тормышка ашты
Шагыйрь нияте;

Шигърият дигән
Гүзәл дөньяда
Үстерә Тукай
Меңләгән бала!

*Февраль, 1967*

## Тирән тамырлар

*Галимҗан Ибраһимовка*

Йөз еллар үткәннәр —
Имән сау,
Сәмумнар өткәннәр —
Имән сау,
Яшеннәр теткәннәр —
Имән сау,
Тираннар беткәннәр —
Имән сау,
Ни хикмәт, могҗиза —
Имән сау?!

Имәннәр бездән дә
Калырлар,
Тагын күп буынны
Танырлар,
Кояшка үрелә
Барырлар!
Ни хикмәт, могҗиза?!
— Тамырлар!
Тамырлар —
Нык,
Тирән тамырлар!

*Февраль, 1967*

* * *

— Яшьләр, яшьләр, кая ашыгасыз?
— Ни кызык бар безнең якларда?!
Сәфәр чыктык яңа җирләргә без,
Офыкларны үтеп атларга.

— Картлар, картлар, кая юл тоттыгыз?
— Сагындырды илләр ифрат та!
Читтә йөреп гомер әрәм үтте,
Кайтып ятыйк туган туфракка...

*Март, 1967*

* * *

Исемеңне алып җырга куштым,
Җырым китте илләр буена.
Исемеңә туры килә диеп
Җырлаганнар, диләр, туеңда...

Җырдан алып хәзер исемеңне
Кызларына күпләр кушалар.
Һай, ул кызлар синдәй гүзәл булса,
Синнән бәхетлерәк булсалар!..

*Март, 1967*

# Челләдә

(Балачак истәлеге)

Көтүеннән качып кайткан сарык
Ышыккарак барып сыена,
Тавык-чебеш, тузгып, кабарынып,
Нигез туфрагында коена.

Казык башларында авыз ачып,
Әлсерәгән итек тик тора.
Аксыл чирәмнәргә палас җәеп,
Әби карчык бодай киптерә.

Чолан җиләсендә бала-чага,
Ялый-ялый агач кашыкны,
Ак мыеклар ясап, гадәтенчә,
Ялт иттерә салкын катыкны.

Ишегалды мич башыдай кайнар,
Яланаяк бассаң пешерә.
Каралтыга сөялгән дә чана,
Салкын кышын искә төшерә...

*Июнь, 1967*

* * *

Кайдадыр гармун уйныйлар,
Җырлаучысы без түгел,
Уйнаулар да шаярулар
Ахры, инде төс түгел...

Яшьлек ягыннан килә күк,
Гармункай, тавышларың;
Нигә соңарып сиздерден
Гомернең авышканын...

*Июль, 1967*

* * *

Бишегеңдә мине тирбәтмә син,
Тургай җыры, арыш басуы.
Бу тынгысыз чордан калмас өчен
Кирәк миңа шәһәр шау-шуы.

Авылымны сагыну гомер бетмәс,
Сирәк кайтам ләкин мин һаман;
Сөйгән ярга тартылабыз шулай,
Әниләрне онытып бер заман...

*Ноябрь, 1967*

* * *

Минем өчен соңгы мизгел килер,
Кинәт туктар да бер тибүдән,
Туган җиргә төшәр йөрәк-тургай,
Җырланмаган бик күп көй белән...

*Сентябрь, 1967*

## Үкенүләр

Искә төшсә
Үткән көннәр,
Үкенүләр,
Үкенүләр:
Күрер кешеләрне
Күрмәгән өчен,
Йөрер җирләрдә
Йөрмәгән өчен;
Җитәр теләкләргә
Җитмәгән өчен;
Әйтер сүзләрне
Әйтмәгән өчен...

Ул арада үтә
Бүгенге көнең,
Өстәлмиме яңа бер
Үкенүең?..

*Октябрь, 1967*

* * *

Бәйрәм итә халык рәхәтләнеп,
Шау-шулы җыр, дәртле биюләр!..
Уен кәефенә кучәлмичә,
Уйчан йөрим һаман мин юләр.

Тантанадан пыялалар зыңлый...
Абзаң маңгай җыерып утырмыш;
Әгәр мин дә каләмемне куйсам,
Туктап калыр сыман бу тормыш.

*Ноябрь, 1967*

## *Хакыйкать*

Туры сүзне кисеп әйткән чакта
Кая хәтер саклап торышлар.
Бер-беребезгә бигрәк мәрхәмәтсез,
Каты бәгырьле без тормышта...

Сискәндерә мине шундый уйлар,
Берәр иптәш китсә арадан...
Ә тереклек үзенекен итә,
Шул ук принцип яши яңадан.

Һәр кешегә ярап, мыштым гына
Йөри алырмын дип уйлама.
Яшәүдән һәм үлемнәрдән көчле
Хакыйкать бар әле дөньяда!

*Ноябрь, 1967*

* * *

Сиздермисең, әмма дулкынлану
Яна битләреңдә.
Яктырырга тора елмаюлар
Ирен читләреңдә.

Адымнарың бию булып китә,
Үзең сизмәгәндә.
Кайда гына йөрдең, гүзәлкәем,
Күңел эзләгәндә?

Очып китәрсең күк, кул салмасам
Әгәр иңнәреңә.
Ярый, китеп калыйм... Бәхетле бул.
Юлык тиңнәреңә...

*Ноябрь, 1967*

* * *

Көнкүрештә мәшәкать күп —
Тегесе йә монысы;
Тормыш ямен күмеп китә
Кайчак ыгы-зыгысы.

Тәгәрмәчтәге тиендәй
Бөтерелүдән тынып,
Дөньяга карыйм текәлеп,
Күзләремне тутырып.

Күнеккәнбез: имеш, бәхет
Гел киләчәктә көтә.
Сизмисең дә, менә шулай
Бәхетле еллар үтә...

*Декабрь, 1967*

* * *

Оныткандыр диеп йөрисеңдер,
Рәнҗегән дә чагың буладыр.
Ни булса да, мине уйлыйсыңдыр,
Төшкә керүләрең шуңадыр?..

Үзем дә еш карыйм күңелемнең
Истәлекләр дигән киносын:
Күз алдыма кояшлы көн белән,
Ромашкалар белән киләсең.

Ә күзләрең моңсу, сагышлылар,
Әйтелмәгән үпкә — иренеңдә.
Син үзеңнең тәүге мәхәббәткә
Бүтән язмыш көткән идең лә...

Уртаклашыр уйлар туадыр да,
Юксынган да көннәр буладыр;
Яшьлегемә кайтып, сине күреп,
Йөрүләрем, ахры, шуңадыр...

*Ноябрь, 1967*

## Алмагач

1

Алмалардан авырайган чакта,
Ботаклары каерылыр чакта,
Һәммәсе дә сөйли шушы хакта:
— Һай, авырдыр мескен алмагачка!

Ә ул тоя шундый җегәрлек,
Ә ул тоя шундый җиңеллек,
Алсу таңга карап, җилкенеп,
Җил-җил килеп атлап китәрлек!

Хәтерләтә япь-яшь ананы,—
Иң сәламәт чагы бу аның,
Иң-иң рәхәт чагы бу аның,
Иң бәхетле чагы алманың.

2

Ак кыраулар җиргә яудылар,
Алмагачны куырып алдылар,
Ак чәчәкләр кара яндылар,
Ал алмалар тумый калдылар...

Багалмасы юк шул кочакта,
Җилләр уйный җиңел ботакта;
Иң авыры аның шул чакта,
Сез беләсез микән бу хакта?

*Декабрь, 1967*

## *Чаң турында баллада*

Тобол музеенда 1591 елда Углич шәһәреннән «сөрелгән» бер чаң бар. Аңа «Беренче сөргенче» дип язылган.

Күкерт иде халык нәфрәте,
Очкын булып чәчрәп чыкты чаң,
Ил алдында, утлар чатнатып,
Патша яңагына сукты чаң.
Түзеп-тынып гомер итәрме —
Халык айнып башын күтәрде.
Онытып законны һәм языкны,
Каерып алды имән казыкны!
Кинәнеп бер әй соң тукмады!

Ә чаң, ә чаң моны хуплады,
Көрәш авазларын туплады.
Беркөнне ул кинәт туктады...

...Күк читендә кызыл таң ата,
Байрак булып җирдә кан ята,
Яраланган җирдә чаң ята,
Күктән төшерелгән чаң ята...
Ахмак димә, патша — мәкерле,
Җәза-газап анда мең төрле;
Чаңның телен йолкып алдылар,
Камчы белән аны ярдылар,
Муенына элмәк салдылар...

Шактый тәҗрибәле патшалар —
Телсез калдыралар башта алар...

Ирек даулап аваз салганда,
Озаттылар чаңны сөргенгә,—
Баш күтәргән ирләр, баш иеп,
Җирдән сөйрәп барды Себергә...

Кешеләрдән элек, беренче,
Шул телсез чаң булды сөргенче...

*Декабрь, 1967*

## Язгы сөенечләр

Яз килә, яз — җирнең яшьлеге,
Бөтен җирдә — яшәү яшеле!
Боз салкыны китә илләрдән,
Җан җылысы килә җилләрдән!
Гомерләре кими төннәрнең,
Шатлыклары арта гөлләрнең.
Булса булыр тагын кыраулар,
Гел әйбәткә безнең юраулар.

Яз килә, яз, хисләр яңара,
Яңа, якты уйлар ярала.
Ташуларда ага чүп-чарлар,
Барыр юлдан китә юк-барлар.
Туң йөрәкләр бетә баралар,
Бетә бара уе каралар.
Күләгәләр көн дә кыскара,
Сандугачлар җырга остара.

Яз килә, яз, әләм күтәреп,
Күңелләргә нурын үткәреп.
Йөз халыкның илдә йөз моңы,
Һәркайсының газиз үз моңы.
Миң халыкның җирдә мең җыры,
Мең җырның да җирдә бер юлы —
Җырлар бара кояш ягына,
Киләчәккә җырлар агыла.

Яз килә, яз, эшчән яз килә,
Зәңгәр һавалардан наз иңә.
Чәчәк булып илгә ямь килә,
Җимешләргә тулыр тәм килә.
Соңгы карлар тиздән китәрләр,
Калган бозлар китеп бетәрләр.
Тартышлардан дөнья арыныр,
Йолдыз арты йолдыз кабыныр!

*Март, 1968*

* * *

Мәхәббәт мине
Юктан бар иткән.
Мәхәббәт мине
Сиңа пар иткән.

Миннән соң да ул
Бу җирдә яшәр.
Һәм мәңгелектән
Юксынып дәшәр...

*Июнь, 1968*

## *Илһамсыз чак*

Яшәү — авыр
Йөк шикелле,
Бер кызыгы
Юк шикелле;
Ник яшерим,
Нигә таныйм —
Тоткын сыман,
Көннәр саныйм.
Ташып торган
Дәртләр көтеп,
Көн үткәрәм
Мәрткә китеп.
...Шат рухлы дип,
Макта, макта,—
Була менә
Шундый чак та...

*1968*

## *Карашларың шундый ягымлы!**

(Җыр)

Карашларың шундый ягымлы!
Мәхәббәттән күзем чагылды,
Мәхәббәттән күзем чагылды,
Кулларыңа синең кагылдым.

Тәүге очрашулар шул иде,
Алдыбызда ап-ак юл иде.
Алдыбызда ап-ак юл иде,
Бөтен дөнья тулы нур иде.

Нурлы иде коңгырт күзләрең,
Нурлы иде һәрбер көлгәнең,
Нурлы иде һәрбер көлгәнең,
Нурлы иде ап-ак күлмәгең...

...Уртак бәхетебез табылды.
...Чигәләргә еллар кагылды.
Чигәләргә еллар кагылды,
Ак күлмәкле кызны сагындым...

Син күрсенмә бер дә моңарга,
Син бирелмә бер дә моңнарга,
Синең белән минем арада
Шул кыз йөри нурлы юлларда!..

*Июль, 1968*

* Васил Хәбисламов музыкасы.

## *Нюра*

Ул сугыштан бала белән кайтты —
Зифа буйлы шәфкать туташы.
Кеше сүзләреннән качып булмый,
Тормышның бу, сеңел, уртасы.

Башын ия дә ул, чәчен чөя,
Чыш-пышлардан нигә куркасы —
Хат җибәреп тора, акча сала,
Яшь капитан — кызның атасы.

...Сугыш бетте дигәч, хәбәр килде...
Карточкасын үбеп җылады...
Ә кыз үсте, рәсмен: «Әткәм»,— диде,
Ирнен тешләп ана тыңлады.

«Әткәң исән,— диде,— кайтыр!» — диде,
Эчтән генә йотты күз яшен:
«Кайгымны бер үзем генә белим,
Нарасыем боегып үсмәсен...»

Ә беркөнне дустыннан хат килде:
«Капитаның исән ләбаса,
Эз югалтыр өчен генә үзен
Үлгән хәбәр иткән ләбаса.
Яңа семья корган...»

...Уен гына
Булды микән бөтен узганнар?!
— Нәрсә булды, әни, ник җылыйсың?
— Әтиең үлгән, диеп язганнар...

*Сентябрь, 1968*

## Хәтимә апа

Ишетелеп тора: өске катта
Тып-тып басып бала йөгерә.
Чырык-чырык килеп туп сикертә,
Җылап алырга да өлгерә.

— Борчымыймы?
— Рәхәтләнеп тыңлыйм!
Ә үземә насыйп булмады...
Өч кенә көн торып калдык. Сугыш
Йолкып алды Насыйбулламны...

Хаты да юк, үлгән хәбәре дә.
Күңел һаман көтә, ышана.
Үткен егет иде, кайтыр кебек,
Юллар нинди урау булса да...

Япа-ялгыз көн кичерәм шулай,
Тыңлап кына бала уйнавын...
Тәрбиягә үзем алмак булдым,
Ә аннары кире уйладым.

Кеше әйтте: ирең кайтып керсә,
«Нинди бала?» — диеп шикләнер.
Ә аласы калган... Күрер идем,
Инде үсеп буйга җиткәнен.

...Үзе сөйли, үзе оек бәйли,
Оек бәйли күрше баласына.
Ә аннары, ак йон җебе алып,
Шарф башлый Насыйбулласына...

*Сентябрь, 1968*

## *Сувенир чабаталар*

Сувенирлар эзләп йөргән чакта
Гаҗәпләнә дә кулың чабакла —
Сатып тора бирәү киндерәле,
Бәп-бәләкәй, чып-чын чабата!

Тире тегеп, күтәртмәләр тагып —
Ничек кенә сине кимәдек!
Тик тормасаң ул бик җылы, дидек,
Беркайчан да начар димәдек.

Без мыексыз чаклар, син — мыеклы,
Кайчакларда кырып аксаттың...
Нәрсә киеп чыгудамы хикмәт —
Дөрес булсын барган максатың.

...«Оригиналь нәрсә таптым!» диеп,
Юлыкканнар моңа сөенер.
Дөнья шулай: безнең нужалар да
Бүгенгә тик мәзәк сувенир...

*Октябрь, 1968*

* * *

Карыйм да мин, сеңелем, гаҗәпләнәм —
Бер дә сәбәпсезгә көләсең.
Шундый тыелгысыз шатлык биргәч,
Күңелледер дөнья, күрәсең.

Иң бәхетле көннәрнең дә әллә
Мәшәкатен генә тояммы?
Артыграктыр, ахры, каш җыерам —
Шуның өчен әле оялдым...

Төрле чагы була бу дөньяның,
Кәефсез дә чагы юк түгел...
Җирдә яшәү әмма күңелле эш,
Беркайчан да авыр йөк түгел!

Күңелне дә саклый белү кирәк,
Ирек бирмә артык сызларга.
Инде бер дә дәва табалмасаң,
Кара көлеп торган кызларга!

*Октябрь, 1968*

* * *

Караңгы төн. Җир өстендә
Шартлап-чәчрәп яна учак.
Ахак күмерләргә карап
Уйлануы татлы шулчак.

Истәлекләр? Хыяллармы?
Әйтеп булмый өзеп кенә.
Шук очкыннар, уйнап-уйнап,
Йолдызларга очып менә.

*Октябрь, 1968*

* * *

— Үзем! — дисең,
— Үзем булып калыйм,— дисең,
— Үзлегемне саклыйм,— дисең,
— Югалтмыйм! — дисең.
Нык торасың.
Тик торасың.
Оттырасың!

Үзең булып яшәү сере
Бу тормышта
Үзгәдер лә —
Үзең булып калыйм, дисәң,
Кирәк һаман
Эзләнергә,
Үсәргә һәм
Заман белән бергә
Үзгәрергә,
Үзгәрергә!

*Гыйнвар, 1969*

* * *

Күзләр карарга ояла,
Иреннәр тартыналар —
Сүз әйтергә талпыналар,
Әйтәлмичә тыналар.

Вакыты җиткәч, күзләрең
Йомылып кала икән,
Иреннәр дә сүзсез генә
Аңлаша ала икән...

*Февраль, 1969*

* * *

*Кол Галигә*

Сез тарихның ар башында,
Безнең урын — бүгендер.
Сез — беренче Гали, әмма
Без соңгысы түгелдер;

Булыр әле зур тарихта
Тагын бик күп алмашлар —
Хис белән, фикер белән дә,
Рух белән дә адашлар!

*Март, 1969*

## *Сынатма*

Берәр җиргә җыенганда, әнкәй
Искәрткәне әле исемдә:
— Сынатма —
Кемнеке дигәндә,
Галиулла улы! — дисеннәр.

Мин укырга кердем. Әткәйнең дә
Озатуы әле исемдә:
— Сынатма —
Кемнеке дигәндә,
Һидият нәселе! — дисеннәр.

Мин шәһәргә киттем. Авылдашлар
Башка нинди киңәш бирсеннәр:
— Сынатма —
Кемнәр бу дигәндә,
Тау ягыннан болар! — дисеннәр.

Илләр гизеп сәфәр йөргәндә дә,
Каләм алганда да исемдә:
— Сынатма —
Кемнәр бу дигәндә,
Татарстан улы! — дисеннәр.

*Март, 1969*

* * *

Айлы төндә йолдызларга баксам —
Мин һәрвакыт хыял иркендә:
Серле, татлы үзгәрешләр көткән
Үсмер чактай күңел җилкенә.

Ирешәсе максатлар да алда,
Мәхәббәт тә әле алда дип,
Киләчәгем иксез-чиксез диеп,
Торам шулчак ихлас алданып...

*Март, 1969*

* * *

Сугышларда калган егетләрнең
Баш очында — ялкын-йолдызлар.
Януларын тышка чыгармыйча,
Сыңар-сыңар яши тол кызлар.

Тол кызларның күңелен,
толкызларның,
Аңласагыз иде әгәр сез!..
Күпме яңа, туар буыннар бит
Югалдылар анда хәбәрсез...

*Март, 1969*

* * *

Каберләре бөтен Европада...
Исемнәрен бергә җыйганнар —
Авылдашлар мәйдан уртасына
Уртак бер таш — һәйкәл куйганнар.

Взвод-взвод баскан солдатлар күк,
Исемлекләр, саф-саф торалар...
Үткәннәрдә алар калсалар да,
Киләчәкне саклап торалар.

*Март, 1969*

* * *

Сәхнәдәге Хәлил, Галиябану —
Тормышта да сөйгәннәр иде.
Бигрәк матур табышканнар иде,
Бигрәк тә пар килгәннәр иде!

Спектакльдән соң, исән күргәч,
Әй сөенгән идем, нарасый!
Булган икән әле, ярын саклап,
Сугыш кырларында авасы...

*Март, 1969*

* * *

Ул фронтка бәхилләшеп китте,
«Кайтып булмас, диеп, туганнар...»
Күз яшьләре белән озаттык без...
Ә районнан кире борганнар.

Өч көннән соң кабат чакырдылар.
«Бәхил» сүзен ул да катмады.
«Кайтасың!» —
дип, без дә көлеп калдык.
Китте... Ләкин кире кайтмады...

*Март, 1969*

* * *

Әткәй рәсмен илтсәм фотографка,
Ул әйбәтләп аны зурайтыр —
Шомартыр да, миңа якын булган
Бит җыерчыкларын югалтыр.

Һәр сызыгы газиз әткәм бит ул,
Онытуга килми бирәсем.
Стенада түгел, күңелемдә
Торсын әйдә һаман бу рәсем...

*Март, 1969*

* * *

Ымсындырып, кызыктырып килә
Күз алдына ерак киләчәк.
Без күрмәбез... Кемдер шул елларны
Бүгенгесе итеп күрәчәк.

Үзебез дә шундый киләчәктә,
Тик кадерен генә белмибез —
Сугышлардан кайтмый калганнарның
Киләчәгендә лә йөрибез...

*Март, 1969*

* * *

Ерак планетаның вәкилләре
Килеп төшсә җиргә, фаразан,
— Ничек аңлашырбыз? — диеп инде,
Галимнәр баш ватып караган.

Төшенерләр иде дуслык ымын,
Бер-берсенә кулны сузганда!
Аңаргача, җирдә яшәүчеләр,
Аңлашалсак иде үзара!

*Март, 1969*

* * *

Иртән кышның кырыслыгы иде,
Яз сулышы иңгән кай ара —
Якты җилләр яфрак кунаклыйсы
Җиңел ботакларда шаяра.

Тамчылар да әнә терелделәр,
Нинди җитез, нинди тереләр!
Каз бәбкәсе кебек борын төртә
Кояш җылысында бөреләр.

*Март, 1969*

* * *

Кашлаклардан карлар тизрәк китә,
Яз җылысын тоя тамырлар.
Тамыркайлар, җирдән туң киткәчтен,
Рәхәтләнеп язылып калырлар.

Кояш нуры күзгә кереп тора,
Мондый якты көнне кем йоклар —
Өнемме бу, төшемме бу диеп,
Киерелешеп исни кыяклар...

*Март, 1969*

* * *

Җир җылысын тоеп чалкан ятам
Уртасында тып-тын аланның.—
Болытлармы шулай агылалар,
Җир белән мин йөзеп бараммы?..

Бер ихтыяҗ була — ялгыз калып,
Уй-хыялга бирелеп алырга.
Күңел канатларын тоеп шунда
Ваклыклардан кеше арына.

*Март, 1969*

* * *

Күлмәк эченә башак куя идем,
Кыймылдасам йөри иде ул —
Йә муеннан үтә, йә аркадан,
Әйтерсең лә тере иде ул!

Инде онтылган кебек булгач
Бала чагындагы йолалар,
Күңелемнең әллә кай төшеннән
Шул башаклар төртеп чыгалар.

*Март, 1969*

* * *

Нарат төбенә көмеш акча күмдек —
Киләчәккә булсын бер мәзәк.
Сүз куештык, шушы хәзинәне
Килеп алырга дип бергәләп.

Икәүләшеп бара алмадык шул,
Ә ул яклар һаман тарталар.
Нарат төпләрендә яшьлегемдә
Яшерелгән хисләр яталар...

*Март, 1969*

* * *

Бер авылда үстек... Бер мәктәптә,
Бер класста бергә укыдык...
Мәхәббәтне сиздермичә генә,
Бер партада бергә утырдык.

Яшьлек бергә үтте... Беләм, шуннан
Аерылдылар, диеп көтәсез?
Бер шәһәрдә, бер үк фатирда
Яшибез без — гафу итәсез!

*Март, 1969*

## *Мәхәббәт һәм биография*

Төрле-төрле мәгълүматлар
Саный кеше,
Биографиядә тик сөюен
Язмый кеше.

Ә мәхәббәт хәл итә бит
Язмышларны —
Хыялларны, омтылышлар,
Уңышларны!

Уйладым мин хаксызлыкны
Төзәтергә —
Сөюгә дә бер графа
Күрсәтергә.

Тик нәни эш әверелде
Бигрәк зурга —
Һәр язганым әйләнә дә
Китә җырга!..

*Март, 1969*

* * *

Биш ел буе чут төймәсе тарттым
(Төп эштән соң яздым шигырьләр).
Журналист та булып ун ел чаптым
(Төп эштән соң яздым шигырьләр).

«Эш!» — диделәр, эшне сорадылар,
Беркем сорамады тегесен.
Эштән арып кайткач, ялны урлап,
Эшләнелгән минем төп эшем!

*Март, 1969*

* * *

Кай арада, белмим, күнеккәннәр —
Көлгән, көлдергәнне көтәләр.
«Ник үзгәрдең?» — диеп, шул ролемә
Керергә гел мәҗбүр итәләр.

Сер бирмәскә тырышып көлгән идем,
Һәм шаярткан идем кайчандыр...
Ә бәлки, мин үзем моңсумындыр,
Табигатем белән уйчандыр?..

*Март, 1969*

## *Кыңгыраулы мәктәп еллары**

(Җыр)

*89 нчы мәктәпне тәмамлаучы*
*яшьләргә багышлыйм.*

Кошлар да бер шулай таралалар,
Сау бул инде, туган оябыз,
Офыкларга карап очар өчен,
Иңнәрдә без канат тоябыз.
Әйтерсең лә пар атларда үтте
Кыңгыраулы мәктәп еллары;
Күңелләрдә гомерлеккә калыр
Шушы соңгы, моңлы чыңлавы,
Кыңгыраулы мәктәп еллары,
Кыңгыраулы мәктәп еллары!..
Зур юлларга безне чыгардың син,
Күңелләргә бирдең омтылыш.
Соңгы звонок булсын беренчесе —
Син каршыла безне, зур тормыш!
Әйтерсең лә пар атларда үтте
Кыңгыраулы мәктәп еллары;
Онытылмас, кая юл тотсак та,
Сагындырыр таныш чыңлавы,
Кыңгыраулы мәктәп еллары,
Кыңгыраулы мәктәп еллары!..
Алда әле заман имтиханы,
Күп сынаулар әле үтәсе,
Максатларга әле ирешәсе,
Хыялларны чынлык итәсе!
Әйтерсең лә пар атларда үтте
Кыңгыраулы мәктәп еллары;
Киләчәккә безне озатканда
Онытылмас дәртле чыңлавы,
Кыңгыраулы мәктәп еллары,
Кыңгыраулы мәктәп еллары!..

*Май, 1969*

*Хөснул Вәлиуллин һәм Рим Хәсәнов музыкалары.

* * *

Ничек икән синең тормышларың,
Йөрисеңме икән шатланып,
Яшерәсеңме кайнар яшьләреңне
Мендәрләргә әллә капланып?..

*1969*

* * *

Ничә көннәр буе үз-үземә
Урын таба алмый йөдәдем.
Күкрәк читлегеннән чыга калса,
Сиңа очар иде йөрәгем...

*1969*

## *Баш очымдагы дүрт юл...*

Ничек сыйсын бөтен әйтер сүзем,
Бар гомерем шушы дүрт юлга?
Сыя икән — юллар астында бит
Үзем ятам мәңге шушында...

*1969*

* * *

Илләрдән дә кителә икән лә ул,
Дөньяларны гизеп йөрелә икән.
Тәбәнәк лә тауның биеклеге
Ераккарак киткәч күренә икән!..

*1970*

* * *

Мәңгелектән
Тамчы булып
Мин тамганмын.
Кемдер әле
Тумый калган...
Мин туганмын!

Нәрсә гаҗәп:
Кабат китсәм
Мәңгелеккә? —
Бу дөньяда
Булмаганмын
Мин элек тә...

*Гыйнвар, 1970*

## Календарь бүләк иткәндә

Ил алдында бурычың бар,
Ватан кушкан урының;
Юллары төрле якларда
Татарстан улының.

Төрле кыйтгада төрлечә
Чыга да байый кояш...
Кайсы улың кайсы көндә
Изге сагыну тоймас?

Ностальгия* белән авырый
Һәрбер рухы сәламәт...
Еракта улларыңа,
Туган җирем, сәлам әйт.

Һай, белмисездер — чит җирдә
Кылдай тартыла хисең...
Татарча календарь сорый
Төрле яктан дус-ишең.

Казан вакытын күрә дә,
Казан кояшын таный —
Баеган сәгатен түгел,
Чыккан сәгатен карый!

...Кайсы елгы календарь һәм
Кемнән килгән булса да,
Язмыш кая ташласа да,
Кайтыр көннәрне сана!

*Апрель, 1970*

*Ностальгия — туган илне сагыну.

## *Бер мең дүрт йөз унсигез көн...*

Бөек Ватан сугышы 1418 көн дәвам итте.

Фашист кыяфәтле үлем
Ябырылып килде өскә,
Сугыш булды өндә, төштә,
Каршы тордык явыз көчкә —
Бер мең дүрт йөз унсигез көн,
Бер мең дүрт йөз унсигез төн!

Яулап тыныч киләчәкне
Җир шарын шуышып үттек.
Һәр секундта без кан түктек,
Һәр минутта без кан түктек —
Бер мең дүрт йөз унсигез көн,
Бер мең дүрт йөз унсигез төн...

Онытылмый икән бер дә,
Күңелләрдә һаман яңа,
Бәгырьләрне телеп яна
Гомергә төзәлмәс яра —
Бер мең дүрт йөз унсигез көн,
Бер мең дүрт йөз унсигез төн...

Соңгы сугыш, соңгысы дип
Ул чакта ышанган идек,
Кисәтә: уяу бул, диеп,
Шомлы аваз булып килеп —
Бер мең дүрт йөз унсигез көн,
Бер мең дүрт йөз унсигез төн!..

*Март, 1970*

* * *

Минем эзләгәнем син түгелдер,
Синең өметең дә мин түгел.
Елмаюың калсын хәтеремдә,
Айның яктысында бер күрен.

Таныш түгел шәһәр урамында
Икәү адашсак та курыкма.
Ай булганга түгел, син булганга
Якты төнне гомер онытмам...

*Май, 1970*

* * *

Борчулар йөрәкне таласа,
Күңелне шом уртәп торганда,
Тынычлык табам мин урманда,
Үзгәрәм дә куям мин анда.

Күтәрәм күземне түбәннән,
Текәләм наратлар башына;
Югала минутлык йомшаклык
Йөз еллык сабырлык каршында.

*Июль, 1970*

* * *

Күкнең зәңгәр тамчылары
Тамып-тамып төшкән мәллә,
Синең нурлы карашларың
Шул чәчәккә күчкән мәллә?

Чәчләреңә куярмын дип,
Зәңгәр чәчәк өзеп алам,
Зәңгәр офык якларына
Сине эзләп китеп барам.

*1970*

* * *

Тезләреңә кызыл бәрхет салдың,
Кулларыңа алдың баяның.
Моңы ташып торган күзләреңә
Бер юлыккан кебек кайдадыр...

Хисләр уртак икән, уйлар уртак,
Аңлашырга гына соңладым.
Көйләреңә синең көйләнеп мин,
Күзләреңне йотылып тыңладым...

*Август, 1970*

* * *

Эскәмиядән карны төшердек тә,
Утырдык без төнге бакчада.
Ireннәргә генә сыенып та
Җылынып була икән, баксана!

Ул чактан соң бик күп җәйләр килде,
Яшисеңме икән онытып?
Кышкы бакча, көртле аллеялар
Күңелемне тора җылытып...

*Август, 1970*

* * *

Җәйнең соңгы көне... Кояш, җылы.
Гап-гадәти бер көн күк тыштан,—
Көтмәгәндә яулап алыр өчен,
Сары яфракларга көз поскан...

Күбәләкләр, наян күбәләкләр
Сөенә-сөенә уйнап очалар.
Үзләренең соңгы бәйрәмнәре
Икәнлеген белми ич алар...

*Август, 1970*

* * *

Җәй әле, җәй кебек, кай ара
Изрәткән эсселек сүрелде?
Офыкта — тасмадай,
Урманда — тәңкәдәй
Сары төс күренде.

Җәй әле, җәй дисәң, көннәр бар!..
Ә үзең сагаеп күзлисең,
Кинәттән күңелдә тоясың —
Көз төсен, көз исен, көз хисен...

*Август, 1970*

* * *

Тар бүлмәләр, тар күңелләр
Туйдырган бер вакыт җитә —
Бераз күңел җилләсен дип,
Кырларыма чыгып китәм.

Офыкларда — шигъри эңгер...
Уйлау рәхәт бу киңлектә.
Шөкер әле, илһам-җаным
Туган шушы иркенлектә!

*Август, 1970*

## Ут

Мәңге сүнмәс утлар булмас,
Сүнәр әле бервакыт...

*Сугыш вакытында*
*таралган җыр*

Бар булганын, ахрысы, без
Озатканбыз фронтка —
Ут давылының артында
Кытлык булды гел утка...

Ут-егетләр булсын да ди,
Хәйләсенме тапмасын —
Шундый ипләп, шундый тәмләп
Чактык ул чак чакмасын.

(Илемне дә чакматашка
Чагыштырасым килде —
Дошман кылычы бәрелгәч,
Ут белән җавап бирде!)

...Яктыртты безнең табынны
Учактан төшкән якты,
Кабар нәрсә бар чагында,
Кашык авызны тапты...

Сүнмәсен дип соңгы очкын,
Күмерне күмдек көлгә —
Сакладык өмет чаткысын
Күчереп көннән көнгә...

Яшәсәк тә ут йотып без,
Дошманга сер бирмәдек —
Сукыр лампа яктысын да
Урамга төшермәдек.

Күрәлмәде самолеты
Бер йөрәк янганын да,
Чыраларның, күңелләрнең
Күмергә калганын да...

Яшермәдек дошманнан без
Утның тик бер төрлесен —
Күрсен, әйдә, белсен безнең
Нәфрәт утының көчен!

Сүндерде безнең егетләр
Соңгы ут ноктасын да —
Нокта куелды сугышка
Европа уртасында.

Сүнмәс кебек иде дә гел,
Сүнде бит сугыш уты.
Кабынды мәңге сүнмәскә
Мәхәббәт, тормыш уты!

*Октябрь, 1970*

# 70 нче еллар

## *Уй елгасы*

Троицк шәһәре Уй елгасы буенда,
Тукай анда 1912 елда булган.

Буын арты
Буыннарны
Танып килә,
Уй елгасы
Гасырлардан
Агып килә.

Кемнәр аңа
Керә алган
Бары тездән,
Кемнәр аның
Чоңгылларын
Иңләп йөзгән.

Уйга чумып
Тукай үтә
Шушы ярдан.
Үләренә
Аның бер ел
Гомер калган...

Тыныч кына
Ага бирә
Уй елгасы.
Үтә шагыйрь —
Уе моңсу,
Уе ачы.

Уй елгасы,
Уй елгасы
Күңелендә.
Заманыңнан
Качып шунда
Күмелергә?..

Юк, шагыйрьнең
Ялгыз гаме
Булмый, булмый —
Халкын уйлый,
Илен уйлый,
Телен уйлый...

Үтә шагыйрь,
Уй елгасы
Буйлап үтә;
Әйтми калган
Күп уйларын
Уйлап үтә.

...Үләренә
Аның бары
Бер ел калган.
Уй елгасы
Кебек чиксез
Гомер алда!

*Гыйнвар, 1971*

## Казан арты

Тукай ягы, шигъри кыйбла булып,
Халык мәхәббәтен казанды.
Казан арты иде... Бу якты як
Хәзер инде алды Казанның!

*Март, 1971*

* * *

Күз алдымда бөреләнде
Күпме язлар,
Күз алдымда чәчәк атты
Күпме кызлар!

Күз алдымда чәчәк койды
Күпме көзләр,
Күз алдымда җимешләнде
Күпме кызлар...

Чәчәкләрдән ала алмыйм
Карашымны —
Үзем — көздә,
Күңлем, язда
Каласыңмы?..

*1972*

* * *

«Сары чәчәк — хыянәт төсе» диләр,
Сөйгән ярга бүләк итмиләр.
Итмиләр дә, нигә соң шулай да
Сагыш сарылары бетмиләр?

Чәчәктәме хикмәт, бу юраулар —
Үткәннәрдән килгән фал гына.
Кайберәүләр, ак чәчәкләр биреп,
Чәч агартып ташлап калдыра...

*Ноябрь, 1972*

* * *

Җырлы чорлар, нурлы еллар
Зәңгәр томанда
Истәлекләр булып калды
Диеп торганда,

Карашың белән йөрәкне
Пешереп үттең,
Тәүге тетрәнүне искә
Төшереп үттең...

Юк, алданма, түгелмен мин
Син көткәннәрдән;
Син киләсең — киләчәктән,
Мин — үткәннәрдән...

*Гыйнвар, 1973*

* * *

Яшисең ил гамен кайгыртып —
Үткәнен, бүгенен, килерен.
Чиләнеп бетәсең чишкәндә
Мең төрле чуалчык төенен.

Гомернең буеннан-буена
Гел шундый борчылу озатты;
Шул минем гомерне кыскартты,
Шул минем гомерне озайтты.

*Гыйнвар, 1973*

* * *

Күңелемдә күп кешеләр тере,
Ни кылсам да читтә калмыйлар;
Сугыш ялкыннары арасыннан
Мөлдерәтеп күзгә карыйлар.

Сүзсез-өнсез димә син аларны,
Күңелеңә кагып дәшәрләр!
Алар хыялынча яшәсәң син,
Синең белән мәңге яшәрләр!

*Сентябрь, 1973*

* * *

Уйлап баксаң, кеше тозлы бит ул:
Эшләгәндә чыккан тир тозлы,
Елаганда тамган яше тозлы,
Ярасыннан аккан кан тозлы...

Кәеф-сафа корып яшәсә гел,
Төчеләнеп читтә торса ул,
Кешелеген саклый алмас иде —
Бозылыр иде тозсыз булса ул!..

*Сентябрь, 1973*

* * *

Диңгез офыгында зәңгәр тасма,
Туган якка дәшкән юл мәллә —
Күңелемә бик тә якын тора,
Яшьлек урманнарым шул мәллә?

Карурмандай шаулый кара диңгез,
Дулкыннары ыргый юртактай...
Чаба алар чая еллар кичеп —
Ашкынулар безнең уртактай.

*Сентябрь, 1973*

* * *

Асфальтны тишкән үсенте
Юлда очрады исә,
Сокланып туктап калабыз:
«Яшәү көче зур бит, ә!»

Гайре табигый бу хәлләр
Булмауга ни җитә соң —
Үсәргә дигән гомерләр
Асфальт тишеп үтмәсен...

*Апрель, 1974*

## *Халык җыры*

— Кая барсак та бер кояш,
Җирләре генә үзгә!
— Туган җирдә генә үз лә,
Читтә кояш ят безгә...

*Октябрь, 1975*

* * *

Бер файдасыз сагыну инде...
Нигә өмет өзмим икән?
Әрнеп, сине юксынып мин
Яшьлегемне эзлим икән...

*Июль, 1975*

* * *

Мин каңгырап йөрим чит вокзалда —
Күрсәңче бер таныш кешеңне!
Яшьтәшләре китеп, ялгыз калган
Картлар хәлен шунда төшендем.

*Июнь, 1975*

* * *

Килде давыл, айкалды көн!
Тулышып җиткән икән —
Тымызык көннәрдә күңел
Үзгәреш көткән икән.

Котыра җил, тамырыңнан
Куптарып алыр сыман...
Алышып карыйк, әйдә бер —
Безне дә, давыл, сына!

*Октябрь, 1976*

* * *

Чыгамын да иртән басуларга
Шөкерана кылып йөримен —
Тургай өстендәге күк имин дә,
Тургай астындагы җир имин!

*Апрель, 1977*

* * *

Камыр әчегәндәй ята басу,
Керә калсаң — билдән чумасы...
Җир тутырып апрель камыр изгән —
Ил тутырып икмәк уңасы!

*Апрель, 1977*

## Киләчәктә

Гаҗәп корылмалар калкыр җирдә,
Хәйран итеп анда яшәрләр...
Тик бер нәрсә үзгәрешсез калыр —
Кыр тутырып иген чәчәрләр!

*Октябрь, 1977*

* * *

Җәй кояшы булып йөргән идең;
Алмаларың инде аллана...
...Син киткәчтен бакчама көз килде,
Өзелеп-өзелеп сагына алмалар...

*Октябрь, 1977*

* * *

Мәңгелектән кайтыр әмәл булса:
«Ни кирәк, дип, сайлап ал шуны!»
Күзем ачып тик бер карар идем
Тургай сайрап торган басуны...

*1977*

* * *

«Чәчәк аткан болыннарым, кайда сез?»
«Яшьлек үткән юлларда!»
«Кара күзле толымнарым, кайда сез?»
«Чәчәк аткан елларда!»

«Сызланулар, сагынулар, кайда сез?»
«Син яшәгән елларда...»
«Үкенүләр, югалтулар, кайда сез?»
«Син үтәсе юлларда...»

*1978*

# 80 нче еллар

## *Хәсән Туфан белән хушлашу сүзе*

Чирек гасыр элек кояшлы көн
Могҗизалы хәбәр китерде.
Каршыладык сине, тарих кичеп
Такташ яннан кайткан шикелле.

Ятсынмаган идең бер генә дә,
Күрмәсәң дә безне таныдың,
Егерменче гасыр шигырендә
Туфан күтәрелде тагын бер.

Шигъриятнең ак намусы булып
Зәңгәр күзең безгә караган;
Әле генә тапкан идек ләса,
Югалттыкмы инде яңадан?..

«Югалтмадык»,— дигән нык ышаныч
Зур кайгыда терәк җаныма;
Син китәсең халык күңеленә —
Мәңгелеккә —
Тукай, Такташ, Сәйдәш янына.

*10 июнь, 1981*

## Юл өзелмәс

И сез, минем Әнгам, Илдар,
Шәүкәт, Марат, Рафаэль!*
..........................................
Аусам-нитсәм,
Юл өзелми —
Егетләр бар запаста.

*Хәсән Туфан*

Туфан фатихасын алган
Дусларны яшим барлап:
Уфадан җавап бирәләр —
Рафаэль, Әнгам, Марат.

Тынгысызлык — васыять безгә,
Ул — шигърият дигән гамь.
Эстафета сезнең җырда —
Марат, Рафаэль, Әнгам.

Сафларга текәлеп әгәр,
Хисаплар сораса ил —
Туфанча булыйк, егетләр,
Әнгам, Марат, Рафаэль.

Җырга-җанга моңнар биргән
Мәңгелек туган ил бар —
Киләчәккә җырлап үтик,
Бергәләп, әйдә, Илдар!

Тугандашлар —
Тукайдашлар, Туфандашлар
Шигъри сафка тезелгәч,
Дуслык юлы да нык булыр,
Җыр юлы да өзелмәс!

*Гыйнвар, 1982*

* Әнгам Атнабаев, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Марат Кәримов, Рафаэль Сафин.

## Канатлылар без — бердәм чагында

*Рафаэль Сафинга*

Казанга килеп, шигырь сөйләсәң,
Дуслык җепләре ныгый тагын да;
Канатлылар без — бердәм чагында,
Талантлылар без — бергә чагында!

Иделгә чыгып, гармун уйнасаң,
Тылмач кирәкми гармун теленә —
Башкорт моңы да якын күңелгә,
Татар моңы да якты күңелгә!

Кырлайга барып, сузып җырласаң,
Таныйлар сине җырчы урманнар,
Тукай җирендә, Туфан илендә
Күңелдәшләр без — шигъри туганнар.

Гел бергә-бергә гомер-гомергә —
Кан кардәшләр без ил кочагында;
Канатлылар без — бердәм чагында,
Талантлылар без — бергә чагында!

*Гыйнвар, 1982*

## *Яшьлек акылы*

«Тиле яшьлек» диючеләр
Хаксыз ук түгел, беләм:
Акылдан да бигрәк, яшьлек
Яши ул күңел белән;

Исәп белми, хисе белән
Җандашын-парын эзли,
Бердәнбер гомеренә ул
Меңнән бер ярын күзли.

Тәҗрибәсез шул чагында
Гомерлек дуслар сайлый:
Күңелдәшнең фикердәшләр
Булырын ничек аңлый?!

...Яшьлегемне сынап, раслап,
Үттем еллар аркылы;
Тиле яшьлек зирәк икән —
Хисе белән акыллы!

*Февраль, 1982*

* * *

Ромашкалар булып синең
Күзеңә карыйм әле,
Сандугач булып җаныңа
Сагыну салыйм әле!

*1982*

* * *

Тамчы булып өстәлсәң дә
Тыела алмас чагым —
Ташып түгелергә тора
Мәхәббәт тулы җаным...

*Март, 1982*

* * *

Кояшлы бер көне өчен
Җиргә килеп киту ярый,
Мәхәббәтле бер кешесен
Гомер буе көтү ярый...

*1982*

* * *

Үкенечле мәхәббәтем,
Әрнүләрем ачысы;
Төрле гасырларга бүлгән
Безне язмыш кайчысы...

*Март, 1982*

* * *

Галәмдәге Киек Каз Юлыдай
Исемеңнең нуры күңелдә —
Үткәннәрдән сагындырып саркып
Яктыра ул әле бүген дә...

*Март, 1982*

* * *

Гашыйклар йөри, бар илнең
Уртак шатлыгы сыман,
Гомер таңыбызда калган
Күңел сафлыгы сыман...

Аһ, килә тагын, шул хисне
Килә бер яңартасы,
Дөнья сафланырлык итеп
Бирәүне яратасы!

*Апрель, 1982*

## Моңсылу

Чыклы чирәмнәрдә синең эзләр,
Моңсылуым, Моңсылу!
Үзәгемне өзәр инде, өзәр,
Моңсылуым, Моңсылу!
Зәңгәр күктә синең күзләр генә,
Моңсылуым, Моңсылу,
Күңелемдә синең сүзләр генә,
Моңсылуым, Моңсылу...
Кай юллардан гына ялгыз гизәр,
Моңсылуым, Моңсылу,
Өзгәләнгән гашыйк җанны сизәр,
Моңсылуым, Моңсылу,
Мәңгелектән мине эзләр генә,
Моңсылуым, Моңсылу...
Яратуга ничек түзәр генә,
Моңсылуым, Моңсылу!

*1982*

* * *

Кабынмам кебек иде,
Сагынмам кебек иде,
Кагылмам кебек иде...

Тагылмам кебек иде,
Ялынмам кебек иде,
Абынмам кебек иде...

*Сентябрь, 1982*

* * *

Бәхетсезләр моңлы-көйле була,
Үзәк өзеп җырлап үтәләр —
Күпме күңелләрне сафландырып,
Күпме бәхет биреп китәләр!..

*Гыйнвар, 1982*

* * *

Гүләү ишетәм дә күккә карыйм,
Беразга эш тора бүленеп —
Зәңгәр күктә, камчы эзләредәй,
Ак сызыклар кала беленеп.

Самолетлар үтә... Күмелгәнче
Мин сагаеп калам, озатып.
Сугышлардан килә хатирәләр
Тыныч күңелемне кузгатып...

*1982*

* * *

Мин китәрмен җирдән, мәңге булсын
Җанга якын газиз моңнарым —
Якты көнгә чыккан агачларның
Тамырына сеңеп тыңлармын...

*1982*

## Авани, тус!*

Бабамның тусы бар иде,
Килсә — урыны түрдә,
Мичлек кирпечне бүтәннән
Эзләмәс иде бер дә.

Яльчик базарында алар
Икәү сыра күтәргән.
Нужалары уртак булгач,
Бергә җиңел үткәргән.

Әткәйнең тусы бар иде,
Хәтерлим чуваш тусны,
Безне салкыннан саклады —
Тун текте ул бер кышны.

Үз иттем мин дә агайны,
Сорыйм: «Чувашча өйрәт!»
Хәйләкәр карап әйтте ул:
«Ан шарлы, кашкыр килеть!» **

Әткәй утыны җылыткан
Бабай салышкан мичне.
Болар сәбәп кенә булган,
Җылыткан дуслык хисе!

Әткәй дә, тус та сугышта...
Әнкәйләр очраштылар,
Үз хисләрен хәлләмичә,
Ирләрен сораштылар.

* Исәнме, дус!
** Шаулама, бүре килә!

Аерым күргән төшләрен
Бергәләп юрадылар.
Тик дуслар гына кайтмады —
Хәбәрсез югалдылар...

Бергәләп явыз дошманны
Җиңделәр бит шулай да —
Дуслык-туслых югалмады,
Җиңеп чыкты ул Майда!

Ут күршеләр булган кебек,
Су күршеләр күптән без,
Уртак Идел-анабызны
Имеп бергә үскәнбез.

Атам-бабам дусларының
Җиренә кабат киләм,
Колач җәеп: «Авани, тус!»,
«Исәнме, дуслар!» — диям.

*Июнь, 1984*

## Югалмас сүз

*Хәсән Туфанга һәм аның әдәби*
*энесе Туфан Миңнуллинга*

Мәңгелеккә хөкем чыгаргандай
Ялтырады салкын күзлекләр —
«Туфан — искергән сүз» диеп хәтта
Әйттерделәр алар сүзлектән.

Тавыш эчкә киткән кеше сыман
Булды чорның сырхау чаклары...
Әмма халык җанга кадерлесен
Хәтер чормасында саклады.

Күпме авазларны йотты микән
Сикәлтәле чорның юллары?
Нидер сизгән сыман, бер авылда
Туфан атлы малай елады...

Бер сәбәпсез ярсый бит нарасый,
Хәерлегә булсын, диделәр.
Белмәделәр, адаш абыйсының
Эчкә йоткан яше иде лә...

Үсә төшкәч, малай көннәр буе
Кыр-болынны күпме гизмәде,
Борчылудан гаҗизләнгән ана
«Туфан, кайт!» дип көн дә эзләде...

«Туфан, кайт!» дип кабатлады урман —
Зур Туфанны эзли кайтаваз!
Көткән җырлар сыман каңгылдашып,
Ничәнче кат илгә кайта яз...

Бала Туфан үсте Тау ягында,
Тиешлесен инде белде ул —

«Туфан — искергән» дип үртәгәндә
Сер бирмәде, бары көлде ул.

Бер сәбәпсез көлә бит бу бала,
Хәерлегә булсын, диделәр.
«Хәсән Туфан кайткан» дигән сүзләр
Газетларны узып килделәр.

Бер сүзе дә югалмасын диеп
Туган телгә кайтты җан атып —
Сүз-намусны, җыр-вөҗданны мәңге
Искермәслек итеп яңартып.

Очрашыла икән исән булгач,
Озын юллар да ул тар икән.
Иңнән кагып әйтте олы Туфан:
— Әдәбиятта энем бар икән!

Яшь Туфанның елгыр, шаян чагы,
Ул үзенчә булмас дисеңме:
— Рәхмәт,— диде адаш абыйсына,—
Аклядыгыз минем исемне!

Ә чал шагыйрь, узган бар юлларын,
Бар моңнарын җыйган шикелле,
Җитди иде. Олы миссиясен
Шул мизгелдә тойган шикелле...

Сүз-намусны, җыр-вөҗданны инде
Энеләре хәзер саклыйсы.
Ул аклады халык ышанычын,
Безгә әле, безгә аклыйсы...

*Ноябрь, 1985*

## Сибгат Хәким белән хушлашканда

Энеләргә күз-колак бул, диеп,
Сине Җәлил, Кәрим җибәргән —
Үлемнәрне кичеп илгә кайттың,
Аталарча сөйдең иңнәрдән.

Без этисез моңлы балаларның
Җан-рухына терәк идең син,
Шагыйрьләре үлеп ятим калган
Халкыбызга кирәк идең син.

Уттан чыксаң да син утта булдың —
Һәр көнеңне янып озаттың.
Януларың, моңың, җырың белән
Татарның син гомерен озайттың.

Соңгы сүзең безгә дә шул булды:
«Бирешмәгез, дидең, эшләгез!»
Васыятең киләчәккә бара —
Изге эздән синең төшмәбез.

Бер тынычлан инде, шагыйрь абый,
Борчуларың безгә калсыннар...
Ә җырларың саф безнеңчә мәңге
Ил күңелен көйләп барсыннар.

*5 июль, 1986*

## *Мәхәббәт хикмәтләре*

*Диләра белән Рәискә*

**1**

Язгы болыннарда очкан
Күбәләк кебек кенә
Табыштылар, таныштылар
Уйнап та көлеп кенә,
Бер-берсенә караштылар
Назлап та сөеп кенә.

Әйттеләр парсыз калганнар:
— Бармас әле озакка —
Биерләр дә борылырлар
Икесе ике якка...

**2**

Мөлдерәмә мәхәббәттән
Сөенеп йөреп кенә,
Кавыштылар, яшиләр бит
Кадерен белеп кенә,
Эндәшәләр бер-берсенә
Иркәләп, сөеп кенә.

Әйттеләр моңсу киленнәр:
— Чуп-чупай айларында
Без дә шулар кебек идек,
Җиттек ай-вайларына...

**3**

Яши яшь пар үчти-үчти
Балалар сөеп кенә,
Кагып яшьлек канатларын
Җырлап та биеп кенә,
Сер бирмичә, нужасының
Артына тибеп кенә!

Әйттеләр әби-карчыклар:
— Чама белеп көлегез,
Яшегезне онытмагыз,
Өлкәнәя белегез!

4

Еллар чәчкә көмеш сипкән
Әйлән-бәйләннәрендә...
Мәхәббәтле дөньяларда
Тормыш та бәйрәм генә,
Болытлы көннәреңне дә
Кояшка әйләндерә!

Әйтте күпне күргән картлар:
— Яшиләр килештереп —
Карт күңелләрне уятып,
Яшьләрне ирештереп!

5

Көмеш туйлар узган-киткән
Тәүге туй кебек кенә;
Инде оныклары белән
Әвәрә килеп, менә,
Яши алар елмаешып,
«Тәтием!» диеп кенә.

Әйттеләр бар да сокланып:
— Әллә нишли замана —
Әби-бабай дисәләр дә
Болар япь-яшь һаман да!

6

Мәхәббәтнең чәчәкләре
Сибелмәде, тузмады —
Ымсындырып егетләрне,
Кызыктырып кызларны
Заманнары кичә-кичә
Киләчәккә узганы!

Ах, мәхәббәт хикмәтләре —
Серен аңлыйсы иде,
Гомерләрне болар кебек
Яшәп карыйсы иде!

*Октябрь, 1986*

## *Безнең нәсел — безнеңчә!*

*Фарукка*

Безнең нәсел — безнеңчә шул,
Хәрәкәтләр җилле лә —
Япь-яшь кенә энебез дә
Килеп җиткән иллегә!

Юк монда һич арттырулар,
Тумыштан батыр идең —
Утыз җиденче елны син
Шушы дөньяга килдең...

Ярты гасыр күп түгел дә,
Ярты гомер диярлек,
Иң кадерле яртысы шул,
Сагыныплар сөйләрлек.

Яшьлегеңнең нурлары да,
Мәхәббәтнең җырлары,
Хыялларың чынга ашып,
Җилеп үткән чорларың.

Гармуныңны тарта идең,
Ишет, дөнья, диептер,
Биеттең инде! Кайчакта
Дөнья сине биетте...

Язмыш басса — ялгыш басса
Буташтырып бакасын —
Тормыш-гармунны барыбер
Үзеңчә сайратасың.

Көй таныган бармакларың
Гармунга дәшә генә —
Дәртле чагың, дусларыңны
Җырлатып яшә генә.

Яңа бәхетләр алда дип,
Күңелеңне юат та,
Булганнарның кадерен бел,
Тапканнарны югалтма!

Безнең нәсел — безнеңчә лә,
Өйрәтәсе юк инде,
Шаян чагында — бик җитди,
Җитди чакта — шук инде!

*Гыйнвар, 1987*

* * *

Киек казлар тезелешеп очса,
Күктән күзне алмый идек без,
Күңелләрне ашкындырып үткән
Шул сафларны саный идек без.

Дөнья күргән өлкән авылдашлар
Без шукларны күпме кисәтте:
— Санамагыз! Таралырлар...— диеп,
Булә иде алар исәпне.

Юк-барга соң безме ышанабыз —
Көлеп кенә ул чак карадык.
Үзебезне дә язмыш санаган —
Төрле якка ерак таралдык...

*Октябрь, 1987*

## Ышаныч

*Миргазиян Юныска*

Тургай күзләп чапкан малай
Очып киткән —
Шулай биек күтәрелгән
Нинди көчтән? —
Бабайларның хыяллары
Аңа күчкән!

Кәгазь көймә йөздергәннәр
Диңгез кичкән —
Ничек ерак йөзгән алар,
Нинди көчтән?
Әткәйләрнең омтылышы
Безгә күчкән!

Басуларда иген үскән,
Уллар үскән.
Ярты гасыр илем үскән
Безнең көчтән —
Сугыш кискән абыйлардан
Теләк күчкән!

Дөнья өчен җаваплылык
Иңгә төшкән —
Кодрәт алып торабыздыр
Нинди көчтән?
Халык өмет-ышанычы
Безгә күчкән!

*Апрель, 1987*

* * *

Әткәй китте, җыры гына калды...
Бер ялгызым кырда калганда
Җырын көйләп аңа дәшә идем,
Атка менеп эшкә барганда.

Нечкәрсә дә күңел, өзелсә дә
Сулыгып та сыкрап үзәгем,
Өзелмәгән миндә әткәй җыры,
Тик шул кодрәт белән түзгәнмен.

*Октябрь, 1987*

* * *

Әтиләләр әти кадерен белми,
Ятимнәрдән әнә сорагыз.
Сорамагыз... Әрнү, сагышларны
Кузгатып та тагын тормагыз.

Үзем әйтәм... Ярты гасыр инде
Шушы әрнү миндә, үксез мин —
Бабай икәнемне онытам да,
Малай булып һаман үксимен...

*Октябрь, 1987*

* * *

Әнкәй тавышына казларыбыз
Җавап бирә иде болыннан,
Сусыл үләннәргә борын төрткән
Сыеры да өйгә борылган.

Әнкәй өне җыйган бер ояга,
Ул әле дә өйгә чакыра —
Борчыладыр, чит җирләргә китеп
Без озаграк тордык чак кына...

*Октябрь, 1987*

* * *

Буран сарган тәрәзәдән карыйм
Сабый чакның җылы почмагына:
Тукай шигырьләрен укый әткәй,
Сыендырып мине кочагына.

Җылыйсылар килеп, әрнеп тыңлыйм —
Ятимнәрнең хәле кыендыр ла...
...Биш елдан соң сугыш. Әткәй киткәч
Мин ятимне Тукай сыендырган...

*Октябрь, 1987*

* * *

Ул адашкан бәбкә тавышлары! —
Сулык-сулык итә түшләре...
Күңелләрне айкап, шушы аваз
Юкка гына искә төшмәде;

Синең тавышың бу, бала чагым,
Сугыш адаштырган бәбкә син.
Килеп табар әле, ташламас дип,
Гомер буе мине көткәнсең...

*Октябрь, 1987*

* * *

Балан җыям көзге бакчада мин,
Әнкәемнән калган балан, дип,
Балан, балан дигән сүзләр миңа
Ишетелә балам, балам, дип...

Җылы сүзләр гомер өстәр иде,
Ишетелсә көткән чагында...
...Кыраудан соң
балан ширбәтләнгән,
Ачы үкенүләр җанымда...

*Октябрь, 1987*

* * *

Кара җиләк җыйдык икәүләшеп,
Җиләкләре зәңгәр-каралҗым.
Ничек инде, белмим,
җыйганмындыр,
Гел бит күзләреңә карадым.

Сөенечле ул җәйдән соң инде
Бик күп җиләк-еллар коелган;
Кара җиләк күрсәм, кара җирдән
Син карыйсың кебек тоела...

*Октябрь, 1987*

## Быелгы «Былтыр»

«Урманнарым бетә!» — диеп,
Кычкырыр чак, Шүрәле,
Балта тоткан адәмнәрне
Кыстырыр чак, Шүрәле!

Быелгы «Былтыр» узынды,
Белми башлады чама:
Утырган ботагын кисте,
Инде тамырга чаба!..

*Октябрь, 1987*

* * *

Йолдызларга горур баккан кеше
Ахыр чиктә җиргә баш орган;
Мизгел гомер кабына да сүнә,
Секунд сыман яшьни гасырлар...

Нинди генә уйлар кичермисең
Тын галәмгә карап алганда...
Тик офтанма, чикле сулышыңа
Чиксез мәңгелекләр ялгана!..

*Октябрь, 1987*

* * *

Бу дөньяга килгәч, бала чакта
Бөтен нәрсә гаҗәп, өр-яңа!
Балигъ булгач,
мәңге китмәс сыман
Гамьсез йөри кеше дөньяда.

Яшәү тәмен татып, кояшына
Гел сөенеп тә соң карыйсы!
...Безгә әле соңгы үкенечне
Соңгы әрнү белән аңлыйсы...

*Октябрь, 1987*

* * *

Бүдәнәнең хәле, ай-һай мөшкел,
Кача-поса, мескен, талчыга —
Үлән арасыннан эт өркетсә,
Тибеп ала күктән карчыга.

Юл буена әнә кеше баскан,
Сыеныпмы шунда төшәсе?
Анда да шул яман ният белән
Көтә — шом-күз мылтык көпшәсе.

*Октябрь, 1987*

* * *

Айлы төннәр, тулы айлы төннәр
Йокыларны һаман качыра,
Серле яктылыкта яшьлегемә
Күңел капусымы ачыла?

Айлы төннәр, тулы айлы төннәр
Моңлы, татлы уйлар уйлата,
Мәхәббәттән кайткан якты булып,
Тынган күңелләрне уята.

Хатирәләр нурлы йомгагын ай
Ник яшьлеккә таба сүтәдер?
...Якты төндә гомер уяу иде —
Яшьлектән соң йоклап үтәдер...

*Октябрь, 1987*

## Иман

*Рәис Даутовка*

Бер карасаң, бу дөньялар
Кызганыч, кызык кына,
Иман сүзе дә яшәде
Сүзлеккә посып кына.

Ахры, «имамнар калдыгы»
Булып күренгәндер ул,
Тере телдән заманында
Шуңа сөрелгәндер ул...

Җанны әрнетеп күп еллар
Вөҗданда иман сызлар —
Үрчеде буш йөрәклеләр,
Ишәйде имансызлар.

«Башын киссәң, тагы үсә...» — дип,
Өметләрен өзмәгән,
Тугры уллар тайпылмаган
Тарих салган эзләрдән.

Хаклык өскә калкасына
Инанганнар үзләре,
Саф күңелләрдә сау калган
Халыкның рух үзәге.

Гасыр чирләрен җиңәрлек
Савыктыргыч им анда —
Туфаннар гүзәл гамендә —
Гуманистик иманда!

Шәмаилдә яңа дога —
Җырлап торган «Туган тел»,

Яшәвебез, саулыгыбыз,
Иманыбыз булган тел.

Әйе җирдә халыкларның
Саны — миллионнарда,
Әмма сыйфат рәвешләре,
Җаны — милли улларда.

Мин ышанам могҗизага —
Халык булдыра килә —
Үзен мәңге яшәтерлек
Дәвам тудыра килә.

Мин ышанам — гасырларда
Бар безгә дә урыннар —
Вәкаләтле илче булыр
Оныклар һәм туруннар!

Әйләнер дөнья-куласа,
Киләчәккә күчәр гел,
Имин булсын да уң булсын —
Иман булсын күчәре!

*Март, 1988*

## Илгә кайта торналар...

Яз җиттеме, торналар
Ни көткәнне беләләр —
Безнең нарасыйларга
Тәпи алып киләләр.

Атлап киткән сабыйның
Тырышканын күрәбез,
Алга чыгып: — Кил, кил! — дип,
Сөенеп дәрт бирәбез.

— Кил, кил — әкият тыңла!
— Кил, кил — кушылып җырла!
— Кил, кил — безне дәвам ит
Киләчәк дигән чорда!

— Кил, кил,— дия Әлифба,—
Тел ачкычын ал миннән —
Сиңа хәтле югалмый
Мең еллардан ул килгән!

— Кил, кил,— диеп, тургайдай
Туган тел сайрап тора.
...Үсеп килә балалар,
Үзгә җыр сайлап кына...

Гел-гел ала каргалар
Әрле-бирле үттеләр,
Әллә уллар-кызларның
Телен алып киттеләр?!

Таныш моңнар өзелде,
Тел ачкычы югалды...
«И туган телем...» диеп,
Тукай борчылып калды...

Ә бит җирдә яз ласа,
Өметләр шытып килә,
Якты җилләре белән
Җанны җылытып килә.

Илгә кайта торналар —
Җуймаганнар моңнарын,
Торна тавышларын да
Бүтәнчәрәк тыңладым;

Әй торналар, торналар,
Сабыйларны күрегез —
Тәпи генә җитми лә,
Тел дә алып килегез!

*Апрель, 1988*

## *Ком сәгате*

Карт кешедән көлеп әйтәләр:
«Моның инде комы коела!..»
Яшьләр өчен кызык бу сүзләр,
Өлкәннәргә авыр тоела...

Үзебез дә шундый идек лә,
Кичерик бу яшьлек гадәтен.—
Вакыт ага безнең аркылы,
Һәркайсыбыз комлы сәгать ул.

*Сентябрь, 1988*

## Туган телем

Әнкәм сөеп-сөеп әйткән,
Әткәм чөеп-чөеп әйткән,
Апам биеп-биеп әйткән —
Матур сүзләр җанымдадыр!

Әбкәм сыйпап-сыйпап әйткән,
Бабам сыйлап-сыйлап әйткән, —
Абзам сынап-сынап әйткән —
Зирәк сүзләр аңымдадыр!

Бәет көйләп-көйләп әйткән,
Кыйсса сөйләп-сөйләп әйткән,
Такмак иләп-иләп әйткән —
Гыйбрәт сүзләр намымдадыр!

Язда уйнап-уйнап үскән,
Җәйдә буйлап-буйлап үскән,
Көздә уйлап-уйлап үскән —
Туган телем канымдадыр!

Телгә тимә — аңга тимә,
Телгә тимә — канга тимә,
Телгә тимә — намга тимә,
Тимә, тимә — җанга тимә!

*Сентябрь, 1988*

## *Балачак балладасы*

1

Дилбегәне кинәт тарттылар,
Атлар капылт кызу чаптылар...
Менә җитәм, җитәм дигәндә,
Арбага ук тотынам дигәндә,
Әткәй янына утырам дигәндә,
Өлгермәдем тик бер сулышка —
Китте алар, китте сугышка...

2

Шундый тойгы миндә гел генә —
Балачагым һаман йөгерә...
Тоям сулыш кабып чапканын,
Йөрәккәе ярсып какканын,
Кайнарланган, тәмам кызышкан —
Язмыш белән чаба узыштан...

3

Мин дә үсеп, киттем калага,
Озын юллар ике арада.
Үрдән-үргә менеп барганда
Офыкларга торам орынып.
Үрсәләнеп, карыйм борылып,
Моңсу балачагым кызганыч —
Юлларында ачы тузан ич...

Ах, юатып булса бу көннән —
Ташлап киткән сыман үкенәм,
Күпме сагыш йоткан, түзгән ул.
Миннән соң да мине эзләп ул,
Яланаяк үткән эздән ул
Гомеремне узып чабачак —
Сугыш бүлгән ятим балачак...

*Сентябрь, 1988*

## *1988 ел кояшына*

Әллә шулай көткәнгәме,
Яктырак күренәсең.
Бәхетең белән күтәрел
Бу елның түренә син.

Мәшәкатьле туса тусын,
Булса булсын кәбисә,
Бу ел безгә бик кадерле —
Җилләре уңай исә.

Яңа булып килми еллар,
Үзебез яңартасы —
Кулларда да, җаннарда да
Сөялләр канатасы...

Бар әле, бар ихласлыкка
Телләр дә ачыласы,
Югалтасы, арынасы,
Әрнисе, ачынасы...

...Җисемгә дә, исемгә дә
Табынганнан туйгансың...
Тик таплардан арынсачы,
Чын хакыйкать,
Кояшым!

*Сентябрь, 1988*

## *Җитеп барам...*

Тигез юллар
Ымсындыра
Киләчәккә —
Имеш, анда
Без гел рәхәт
Күрәчәк лә!

Ә күңелем
Үткәннәрдә
Гизә һаман,
Баткак юлда
Авыр балчык
Изә һаман...

Үткәнемдә
Киләчәктән
Көткәннәр күп.
Хәзер инде
Киләчәк аз,
Үткәннәр күп...

Җитеп барам
Офыгымның
Чигенә мин —
Артка карап,
Киләчәккә
Чигенәмен...

*Сентябрь, 1988*

## *Язмышлар*

Тын гына борыла да
Үткән еллар ягына,
Яшьлектәге гүзәлен
Ничә күңел сагына —
Әйтерсең лә ул һаман
Чәчәктәй кыз чагында...
...Әби инде ята шул
Күптән җир кочагында...

*1988*

## *Күзле төш*

Дөм сукыр ул...
Үзе төштә
Һаман күрә:
Сабый чактан
Төшкән якты
Күзгә керә...

*Сентябрь, 1988*

* * *

Дәвер арты дәвер алмашына,
Төп тәртибе аның бер һаман —
Онытылган уйлар сыман гына
Без дә югалырбыз берзаман...

*1988*

## *Хәтерсезлек*

Әйтәлми карт —
Кызы кайчан
Килде әле?
Улы кайчан
Кереп хәлне
Белде әле?
— Хәзер без бит —
Хәтерсез бик...

Хәтерсезлек —
Хәтәр үзлек...
Өндә микән,
Кергән иде
Онык та бит.
Кайсы елны?
Исендә юк,
Оныткан бит...

Бергә чакны
Шәп хәтерли
Ул шулай да!
...Күз — тәрәздә,
Уй — үткәндә,
Үзе кайда?

Картлар йорты...
Ялгыз йортта
Ялгыз картлар:
Тора анда
Ялгызаклар,
Онытылган
Ялгыз затлар,
Ялгыз ятлар...

Килерләр, ди,
Гаепләргә
Урын тапмый.
Үз дип яклый,
Үз дип аклый —
Хәтер саклый...

Әй бу картлык,
Әй артыклык —
Хәтәр сүзләр.
Исән көе
Югалган бу
Хәбәрсезләр...

Заманымы,
Балалармы
Хәтерсезләр?
Кая китә,
Кая илтә
Хәтәр эзләр?..

*Сентябрь, 1988*

## *Ялгызлык*

Үткәннәр — тынган,
Бүгене — дәшми...
Искергән өйдә
Ялгыз карт яши.

Барлык тавышлар
Тынган, тоныклар;
Йөрми уллары,
Көлми оныклар...

Мәчесе дә юк,
Адашты микән?
Әллә хуҗасын
Алмашты микән?..

Төнлектән инде
Җилләр дә өрми,
Ишектән инде
Кемнәр дә йөрми...

Әрле-бирле тик
Шыгырдый идән:
Иптәшкә ул бар —
Китмәгән өйдән...

*Сентябрь, 1988*

## Буыннар, буыннар

Өлкән кешегә
Сыкранса да,
Сукранса да урын бар:
Һава үзгәрешен дә
Сиздерә карт буыннар.

Утырып уынган,
Шыгырдап кузгала,
Сызлана картлар, сызлана...
Зарлана тагын —
Эч пошырган яшь буыннан.

Ә бит баксаң,
Үзең дә яшь, дуамал булынган,
Тик инде кан суынган...

Ә яшьләр ул үз дә, үзгә дә —
Усал сүзләр эзләмә.
Барыбер
Яшәрә-яшәрә заман үзгәрә —
Һаваң үзгәрә!

*Октябрь, 1988*

## *Бозлык дәвере*

Илдә — зәмһәрир салкыны,
Җан-бәгырьләр өшегән...
Урманда агач шартлыймы —
Карга ава кешеләр?!

Корыч кул, кылыч seberке
Илне кырып-себерде,
Бер селтәнү белән кушты
Кырым белән Себерне...

Сагаеп тынды табигать,
Алда ни көтә микән,
Күңелне баскан албасты —
Кара шом бетәр микән?

Тик тереклек бетми, аңа
Җайлашулар хас кына —
Үз тормышы белән яши
Күпме җан боз астында...

Яшиләр дә...
Сүзсезләр шул,
Дәшмиләр шул балыклар.
Балык телендә сөйләште
Ул чорларда халыклар...

Ил язмышын изеп-кисеп
Бозлык дәвере узды,
Инде тәмам эретәсе
Күңелгә поскан бозны...

*Октябрь, 1988*

## Соңгылар

Нигезләр үткән,
Авыл күчкән,
Офык җиргә төшкән...
Кадерле эзләргә,
Үткән гомергә
Кычыткан үскән...

Ата-баба гына
Калган соңгы рәттә
Зиратта
Ятып —
Гамьсезлеккә каршы
Соңгы окоп...

Ташлар чүгеп, түнеп,
Сеңеп беткәннәр.
Тик ташламас болар —
Җирдән китми
Җиргә киткәннәр...

*Октябрь, 1988*

## *Күңел түре*

Өй түренә элгән шәмаилнең
Сүзләре ак — көмеш хәрефле,
Гел иминлек кенә теләгән ул,
Бусагадан куган хәвефне.

Җанга тынычлыклар биреп торган
Гасырлардан килгән инану.
Язулары безгә бикле иде,
Соң төшендем бугай мин аны...

Гарасатлар кичеп безгә килгән
Иман сагындагы калкан ул,
Куәт, кодрәт биреп ахыргача,
Үзен саклый алмый калган ул...

Диварларга иңгән язуларын
Үзгәртүчән булды бу гасыр...
...Очраттым бер авыл өендә мин
Гомер бакый төшмәс догасын:

«Туган теле» иде ул Тукайның —
Яшәү таныклыгы халкымның,
Чәй көмеше белән бизәлсә дә
Һәрбер сүз тере алтынлы.

Бу нигезгә сыену эзләптер ул,
Җан җылысы тоеп кергәндер,
Урыс капкаларны шакый-шакый
Кунар күңел тапмый йөргәндер...

Яңа чорлар килә, берәм-берәм
Кыйбласына кайта киткәннәр...
Кан тартканнар, әнә җан тартканнар
Тукай җырын гимн иткәннәр.

Шәмаилдә — телем-иманым ул,
Бабайлардан килгән әманәт,
Ул иминдә нәслем-халкым исән,
Ул сау чакта рухым сәламәт.

Ил-йортка ул бәхет теләп тора...
Атын җуйган дага булмасын —
Канатлы ир-йөрәкләре белән
Дөлдөлләре җирне урасын.

...Күңел түрендәге атам-бабам,
Борчулы рух инде шат сыман...
Тыныч булырмынмы — бар өметне
Мин дә варисларга тапшырам...

*Октябрь, 1988*

## *Эчке «штатлар»*

Бабайлар инанган:
Ике иңдә ике фәрештә
Теркиләр икән
кылган гамәлеңне,
Күз-колак синең һәр эшкә...
Алар сөрелгәчтен,
Кешегә
Шактый эш арткан,
Бүселеп өелгән җилкәгә
Һәрбер чор өстәгән
яңа «штатлар».

Әйтик, «эчке редактор» утыра,
Кулында үтмәс кайчысы:
Кискәли, тигезли, хәл итә —
Кайсы үтәр,
Үтмәс кайсысы?

Бар тагын
Иминлек сакчысы:
«Бу сүзгә — иртәрәк...
Ә бусы хәвефсез —
Шул булыр тәңгәле, яхшысы!»

Чикли-чикли
Тәмам сагайтып
Телгә остарттылар —
Хак сүзне яшертеп,
Уйны кыскарттылар.

Чәчрәп чыкма,
Үзеңне сакла дип,
Тынычландыра алар, юата.

Саклана торгач,
Кала тик эчке «штат» —
Шәхес абзый үзен югалта.

Вакыты шул бүген —
Артык штаттан
Арынсын күңел!
Әмма мавыгып
Чама чиген дә узмамын,
Тигезлек бизмәнен
Бозмамын,
Ике иңемдә
Булыр ике канатым —
Намус һәм вөҗданым!

*Октябрь, 1988*

## *Йөгерергә яраттык без...*

*Мәсгуткә*

Әй сабый чак — бәбкә үлән,
Ялан тәпиле урам!
Уйнап калды безнең эздә
Җәй — тузан, кышын — буран...

Йөгерергә яраттык без,
Дөньясы да куды ла,
Кырыс еллар аяк чалды—
Төрле чаклар булды ла...

Бушка түгел, эшкә чаптык,
Беркемгә уздырмадык —
Мәгънәсез юллардан йөреп,
Чабата туздырмадык.

Мактанып әйтүләр түгел,
Аз кумадык нужаны —
Куып җиттек, узып киттек,
Кызык иттек без аны!

Тәгәри дөнья-куласа,
Дулый икән дуласа,
Тик үкчәгә басалмый әй —
Булмый икән булмаса!

Йөгерик лә, еллар санап
Тормыйк вакыт уздырып —
Егерменче гасыр калсын
Хәйран калып, сызгырып!

*Декабрь, 1988*

## Үлчәү

Бала чакта буй үлчисең,
Тизрәк үсәсе килә,
Шул олылар дөньясына
Тизрәк күчәсе килә.

Бер-береңә «мужик» диеп
Дәшәсең җитди генә!
Әй, әкрен үтә балачак,
Өлкәнлек җитми генә!

Табандай ялтырый башлар,
Үзгәрәк хәзер теләк.
Киләчәккә барган саен
Үткәннәр кадерлерәк.

Үселгән шул, бүселгән шул,
Күрсенеп: — А-алай! — дисең.
Кордашың күрсәң, сагынып:
— Исәнме, малай! — дисең.

Бала акылы кергән дип
Кызганмагыз картларны —
Әкренәйгәч, куып җитә
Җитез бала чаклары.

Ат итеп уйнаган таяк
Кайтуы да урынлы —
Ашыкмыйча, җайлап кына
Үлчи калган юлыңны...

*Октябрь, 1989*

## *Лоджиядә толып*

Җәен артык булып тора,
Кышын карлар кунып тора,
Лоджиядә толып тора,
Күңел күреп туңып тора.

Көяз, ыспай әйбер түрдә,
Бүтән дөнья, бу бит шәһәр.
Кадер булыр иде дә соң
Авыл җире булса әгәр.

Лоджиягә бабай чыккан,
Йортлар өсләп карап куя,
Бармаклары толып-атның
Ял-якасын тарап куя.

Күзләр дымлы, эчтән иңрәп
Иреннәрен тешләп куя.
Тышауланган йөрәк ярсып
Эчтән кешнәп, эчтән тына...

Көяз, ыспай әйбер түрдә —
Бүтән дөнья, бу бит шәһәр.
Кадер булыр иде дә соң
Авыл исән булса әгәр.

*Октябрь, 1989*

## Хәрәкәттә – һәлакәтме?

«...1989 елда юлларда 58.651 кеше үлде, 347.402 яраланды... » «Әфганстанда 9 елда 15 мең кеше һәлак булган...»

*Матбугат хәбәрләреннән*

«Ун меңнәрчә һәлак булды,
Йөз меңнәрчә имгәнде...»
Бу ни хәл бу, безнең илгә
Әллә сугыш килгәнме?

Радиолар сөйләп тора,
Газета да кичекми,
Нинди тыныч фаҗига бу,
Нигә беркем ишетми?

Имин еллар, туры юллар,
Уңга-сулга борылыш...
Кинәт — таран! Машиналар
Пыран-заран... кырылыш.

Тиз, уңай дип кәефләнеп
Руль борылган арада,
Мәҗүсиләр алласыдай,
Техника корбан ала.

Шәрабларына кушылып,
Арта заман тизлеге,
Чослыгыңны әкренәйтә,
Тизлекнең шул үзлеге.

Бәйдән ычкынган гамьсезлек
Юлларның киңлегендә —
Маңгайга маңгай бәрелә
Тәкәббер «мин!»легенә.

Тимер ташкыны ашкына...
Дулаган хәрәкәтме?
Тынычлыкмы, сугышмы бу?
Яшәүме, һәлакәтме?

*Октябрь, 1989*

## *Яшьлегем чәчәкләре*

### 1.Кыңгырау чәчәк

Әллә чәчәк, әллә кошлар
Болыннарда чың-чың итте,
Яшьлегемнең могҗизасы
Хыялларны чып-чын итте.

Нурлы июнь, нурлы болын,
Нурлы күктә нурлы тургай,
Нурлы сүзең, нурлы күзең,
Әллә яшьлек нурлы шулай?

Җырлы төннәр, җырлы таңнар,
Җырлы чишмә, җырлы тургай...
Җырлы йолдыз тирәсендә
Безнең бәхет җырлый бугай.

Тавышың әллә моңлы тургай,
Рәхәт иде яңгыравы,
Ерак инде, ерак яшьлек —
Ишетелми кыңгыравы.

### 2. Күк чәчәк

Күк чәчәгем, күк күзем син,
Чыктың арыш арасыннан:
Нинди матур өннәр килә
Рәшә-офык тарафыннан?

Күк чәчәгем, ихлас чәчәк,
Иртә чагың, иркә чагың,
Энҗе чыгың саен кояш,
Мәңге шундый булыр чагың!

Күк чәчәгем, саф чәчәгем,
Юл буенда калды елап.
Еллар тәгәрмәче дулап
Таптап үтте, дегет сылап.

Турайдың да, кагындың да
Өметләнеп көн дә көттең.
Үткән еллар кайтмыйлар ла,
Ул арбада мин дә киттем...

### 3. Ромашка

Яшьлек шашкын — кодрәт чиксез,
Хыялга җитәр чагың.
Мәхәббәттә бәхетле йә
Бәхетсез итәр чагың.

«Ярата», «яратмый» диеп,
Юрадык, кабатладык —
Рәнҗетеп җилгә очырдык
Ромашка канатларын.

Аклыгын, шатлыгын өздек,
Калган бары сарысы —
Кадерле елларның безгә
Юаныргa сагышы...

Инде күрәм, газабың да
Рәхәтең булган икән —
Бәхетсез мәхәббәтең дә
Бәхетең булган икән...

Югалтулы юллар үттек,
Өметләр юк башкага —
Яшьлегемнең ромашкасы,
Аклыгыңнан ташлама!

### 4. Роза-Гөлчәчәк

Үзебезнең чәчәкләргә
Әллә шунда күнегелгән —
«Кунак кызы» күзгә тансык,
Ул тирәдә күңелле лә!

Затлы чәчәк, көяз чәчәк,
Үз бәясен белеп кенә,
Өстен санап — өстән карап
Уза чак-чак көлеп кенә.

Чын түгелдер, сурәттер күк,
Җитәрлекме безнең буйлар —
Горур борып нәфис башын
Ефәк чәчен чөеп куяр.

Тәкәбберлек тә килешә,
Бигрәк чибәр шул кыланчык!
Төртмә сүзләр чәнечкеле —
Гүзәллекне саклый кылчык...

Матур һәрчак матур инде —
Кызыкканнар шактый булды.
Барсын какты, тиңен көтте.
Гомер үтте... Ялгыз сулды...

*Декабрь, 1989*

# 90 нчы еллар

## *Сеңелләр китә кияүгә*

Сенелләр китә кияүгә,
Бәхет ява ир-атка.
Бисмилла әйтеп тапшырдык
Дамираны Миратка.

Алып кал, кияү, кәләшне
Барыйм, дигән чагында.
Туры килсен фәрештәнең
«Амин» дигән чагына.

Яшәгез, бер-берегезгә
Гомерлек терәк булып,
Бергә типкән йөрәк булып,
Һәрвакыт кирәк булып.

Иншалла, дип сөенерлек
Гаилә булсын әле,
Сөбханалла, дип торырлык
Нәтиҗә тусын әле:

Балаларны елатмыйча,
Шат торсагыз иде гел,
Татарның санын-сыйфатын
Арттырсагыз иде гел.

Сеңелләр китә кияүгә,
Аш булсын да таш булсын,
Кайсыгыз «лидер» дигәндә,
Гел татулык баш булсын!

*Май, 1991*

## *Кайбычкаем-яшьлегем*

Хыялымда канатланып
Кайларга мин очмадым...
Тау ягым син, туган ягым,
Иң җылы бер почмагым.
Зәңгәр урман моңнарында
Кайбычкаем-яшьлегем,
Мәхәббәтле юлларыңа
Серләремне яшердем.

Китәм, дидем, киттем, дидем,
Барыбер киткәнем юк.
Сагынулы офыкларның
Чигенә җиткәнем юк.
Зәңгәр урман кайтавазы
Кайбычкаем-яшьлегем,
Мәхәббәтле юлларыңа
Серләремне яшердем...

Үткәннәрме, киләчәкме,
Сайлыйм соң кайсыларын?
Үкенгәннәр генә белә
Югалту ачыларын...
Зәңгәр урман рәшәсендә
Кайбычкаем-яшьлегем,
Мәхәббәтле юлларына
Серләремне яшердем.

*1993*

## Галиәсгар Камалның оныгы,
## әнәс Камалның кызы Диләрә ханымга

Нәселең затлы, атаклы,
Чамалаган — чамалар:
Камал I,Камал II нче...
Азмы мәшһүр Камаллар.

Лаеклы варис булулар
Җиңел түгел диләр дә,
Күп Камаллар арасында
Син беренче, Диләрә!

Артистлык синең каныңда,
Бер дә кимен куймыйсың —
Тормыш сәхнәсендә рольне
Сокландыргыч уйныйсың:

Сөйкемле хәләл җефет син,
Әни дә, дәү әни дә,
Хөрмәтле апа, кодагый,
Армас-талмас табибә!

Рәхмәт инде Камалларга,
Һәммә яклап булдырган,
Иң яраткан образ итеп
Диләрәсен тудырган:

Җырлап-биеп яши торган,
Йөгереп эшли торган,
Алны-ялны белми торган,
Сәхнәдән төшми торган!

Хатын-кызның ящь-яшьләре
Яшьләрен яшермиләр,
Котлыйбыз сине, юбиляр,
Алтын... мыш яшең белән!

Бүгенгедәй бенефиска
Безне дә дәшә-дәшә,
Рәисең* белән янәшә
Чүкердәшә-чүкердәшә,
Фикерләшә вә серләшә
Бәхетле булып яшә!

Болганыр да тынар дөнья,
Ә безнең иманнар нык:
Яшәсен туган-тумача
Һәм кода-кодагыйлык!

*Гыйнвар, 1994*

* * *

Сөенеп, сыенып
Озаттык яңгырны,
Кояшлы тамчылар —
Их ,тагын яугыры!

Тамчылы керфекләр
Бик ерак бит инде.
Кояшлы кар ява
Үртәгән шикелле.

*Апрель, 1994*

* Рәис Даутов — галим, тәрҗемәче, Г.Исхакый бүләге лауреаты.

## Якташларга әйтер сүзем

И Тау ягым, туган ягым,
Әрнегән, туңган ягым,
Гомерлеккә илһам булып
Күңелгә тулган ягым.
Нужа — мине, мин — нужаны
Ничә ел куган чагым,
Ачык басу капкасыннан
Шәһәргә шуган чагым...

И минем Олы Бакырчым,
Ата-бабам нигезе,
Сагынсак, чабудан тартып
Кайтарасың син безне.
Түздең эзләр өзелгәндә —
Колакларны бормадың,
Төшләремә кереп тордың,
Истән чыгып тормадың.

Рәхмәт сезгә, читкә китми
Төп йортта яшәүчеләр,
Без йоклаган таңнарда да
Җигелеп эшләүчеләр.
Рәхмәт сезгә, ил табынын
Кайгырткан игенчеләр,
Җир-Ана кадерен белеп,
Игелек игүчеләр!

И кардәшләр, авылдашлар,
Кай якка, кайчан очсак,
Җиде бабам шәҗәрәсен
Тәсбихтәй тартам һәрчак:
Һидият,
        Хәмит,
                Хантимер,
Хәбибулла,
        Ислам,
                Исхак,
Иң түрдәгесе —
                Чучак —
Сүнмәсен минем учак!

Болганадыр заманалар,
Тулгана заманалар,
Элек тә булган ла алар,
Элек тә узган алар —
Дөнья дигәнең куласа,
Әйләнә дә бер баса:
Таяныч та, ышаныч та
Үзебездә ләбаса!

Кемнәрдер әйтсә, әйтсеннәр,
Караңгы як дисеннәр...
Яктырта безнең тарихны
Нуры сүнмәс исемнәр;
Чор-дәверләр алмашынып,
Мәйданнарга килсеннәр —
Һәйкәлдәге шәһитләргә
Уйланып баш исеннәр.

Без килербез дә китәрбез,
Туган як мәңге булсын,
Каенсар түбәләрендә
Гел якты таңнар тусын.
Дымбылатым гөрләп аксын,
Кыйбладан борылмасын,
Чирмешәнем саекмасын,
Тамырым корымасын.

И Тау ягы, туган туфрак —
Иделнең уң канаты,
Илемнең уң канаты,—
Син минем дә канатым!
Шушы җирне сайлап тудым,
Шушы җирне яраттым,
Шушы җир салды күңелгә
Илһамын-мәхәббәтен.
Гомер буе язганнарым
Ул бит сиңа рәхмәтем,
Ул бит минем рәхмәтем!

*Гыйнвар, 1994*

## Шәвәлиев Барый

*Бөек Ватан сугышы*
*корбаны истәлегенә*

Татарымның батыр улы
Шәвәлиев Барый
Ярты гасыр араларны үтеп
Һәйкәленнән карый.

Унтугыз ла яшьтә калган
Шәвәлиев Барый,
Нинди икән яңа буын, диеп,
Яшьләр, сезне барлый.

Карый, барлый... Бергә киткән
Яшьтәшләр дип таный.
Безнең өчен дә сез яшәгез, ди
Шәвәлиев Барый.

*Март, 1994*

* * *

Баксана — яз икән!
Яп-якты бу дөнья?!
Кошларым килмәгән —
Кыш әле уемда.

Ул кышта син бар бит,
Ягымлы бураннар,
Ак мамык шәлеңә
Моңнарым уралган...

*Апрель, 1994*

* * *

Тулышты моң белән
Өннәрем, төшләрем,
Адрессыз мәхәббәт,
Исемсез хисләрем...

Килердән көтмимен,
Бүгеннән эзләмим.
Былтыргы карларда
Эридер эзләрем...

*Апрель, 1994*

## Соңгы мәхәббәтем

Күңел тәрәзәмне кактың син,
Онытмагансың бит, таптың син.
Көтмәгәндә шулай кил тагын
Соңгы мәхәббәтем — илһамым.

*Апрель, 1994*

* * *

Хушлашулар белән көз килде,
Чаганнарга кызыл ут инде.
Мәңгелеккә коела гомерләр,
Күпме якыннарым юк инде.

Кавышулар булып яз килде,
Каеннарга яшел чук элде.
Утта яна иске яфраклар,
Уртак сөенечләр юк инде.

*Май, 1994*

## *Хәтер иясе*

*Язучы вә галим*
*Миркасыйм Госмановка*

Татар барда — хәтәр бар, дип,
Кемнәрдер сүз тарата.
Татар барда — хәтер бар, дип,
Әйтәм сиңа карата.

Хәтер барда — татар булыр,
Хәтер саклар улы син,
Гасырларны урап чыккан
Каурый каләм-кулы син.

Татар барда — хәстәр бар, дим,
Бу сүз бик кулай икән —
Әүвәл генәме, хәзер дә
Бөекләр була икән.

Бу гасырның аръягында,
Яшең йөзләрне үтеп,
Укырсың бу мәдхияне
Борынгы язма итеп.

*Май, 1994*

## Баттал холкы

*Очучы-эдипкэ*

«Баттал икәнемне онытсам да,
Постта икәнемне онытмам!»

*Салих Баттал,* «Постта», 1928

Даулы дәверләрне син үзеңчә
Дуамалланып очып узгансың.
Канатларың күккә сыймагандыр,
Уставларны шактый бозгансың.
Ялгызлар да яклый хакыйкатьне,
Ялгыш юлга алар юлыкмас;
Постта утырганнар онытылыр,
Баттал холкын халкым онытмас.
Шигъриятнең биек гөмбәзенә
Култамгасын язган оста син.
Алмашына заманалар гына —
Үзсүзләнеп һаман постта син!

*Сентябрь, 1994*

## Иске рәсем

Петербурда төшкән иске рәсем:
Алтмыш биш ел узган ул көннән,
Гасыр азагына килеп җиттек,
Дәвам булып нәсел-төркемнән.
Казанны да алдык бергәләшеп —
Үрчемле ул Гали нәселе,
Киләчәккә карап торсын әле
Безнең туганнарның рәсеме.
Үлемсезлек гади нәрсә бит ул:
Буын арты буын яралып,
Яшәреп тә, һаман матурланып
Мәңге яшәрбез без яңарып!

*Гыйнвар, 1995*

## Мәңгелек бабай

*Шәйхи Маннур
истәлегенә*

Бала чагым хыялларын
Әйдәп үтте Айбакты,
Җилкендереп алып китте —
Аргамагы «Канатлы»!

Мин дә тынгысыз дәвердә
«Олаучы малай» булдым,
Шул шигърият илләрендә
Юлаучы малай булдым.

Офыкларымны киңәйтте
Гаҗәеп Гайҗан бабай.
Өндәп ияртте, өйрәтте
Мәзәккә бай җан бабай.

Тылсымына ымсындырып
Туган телгә каратты,
Киләчәккә алып килде —
Халкым рухы канатлы.

Мәңгелек бабай ул, дисез,
Бик ышанып бүген сез.
Бабаларын олылаган
Балалар да үлемсез!

*Гыйнвар, 1995*

## Туганнар табынга җыелдык

*Фарук, Фәрит, Рәшит*
*Гыйльметдиновларга*

Туганнар табынга җыелдык,
Җыелдык без төрле тарафтан.
Сынамак булыптыр, язмышлар
Бигрәкләр тырышып тараткан.

Туганнар табынга җыелдык,
Күңелләр күңелгә сыендык,
Иңнәрдән төште йөк-авырлык,
Онтылды мәшәкать, кыенлык.

Сөйләшеп сүзләр гел бетмәслек,
Яңара күп уртак истәлек.
Әткәйләр утырган түр, диеп,
Куябыз сагышлап-искәреп...

Табынга җыелдык туганнар,
Күзләргә сагыну тулышкан.
Иң якын, иң газиз кешеләр
Үз бит сез, безнеке тумыштан!

Заманнар киләсе-китәсе,
Бик-бик күп туганнар туасы.
Мин беләм, алар да сезнең күк
Сынатмас ир-егет буласы!

Җан тарткан, кан тарткан — очраткан,
Күңелләр сые бу табында.
Гасырлар чик түгел, өзелмик —
Туганнар җыелыйк тагын да!

*Гыйнвар, 1995*

## Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиевкә*

*Декларация игълан ителүгә*
*5 ел тулу уңаеннан*

Мөстәкыйльлек безнең байрагыбыз,
Ирекле ил туды дөньяга —
Нигезе нык-тирән тарихларда,
Татарстан булыр өр-яңа!
Иманыбыз камил, ышаныч нык,
Максатыбыз, алга дәшәсең:
Елдан-елга үсеп, күтәрелеп,
Республикам мәңге яшәсен!

*Август, 1995*

* Акрошигырь. Юлларда беренче хәрефләрдән исем укыла.

## Беренче мәхәббәтем син

*Фәридәмә*

Мәхәббәт нәрсә, дисәгез,
Илһамдыр, сәләттер ул,
Җаныңның илаһи хәлен
Ачарга сәбәптер ул.

Эзлисеңдер, күзлисеңдер,
Берәүне көтәсеңдер.
Хыялың җиткән кадәрле
Илаһи итәсеңдер.

Хәтерлим, күк капусыдай,
Ул хис кабынган чакны,
Үзеңә әйтмичә генә
Ун ел сагынган чакны.

Хәзер инде аңлый алмыйм
Ник шулай соңлаганны,
Мәхәббәтне сынадыммы,
Язмышым сынаганмы?

Соңрак очраганнар булды,
Вәгъдәләп юатмадым,
Югалтырдай чакларда да
Мин сине югалтмадым.

Тәүге язда бәбкәләрне
Саклый идең чирәмдә.
Көз дә җиткән. Оныкларың
Канат кага тирәндә.

Очрашу минутларыдай
Үтәр дип кем уйлаган —

Якынлашып киләбез ич
Инде алтын туйга да.

Көткән сүзләреңне әле
Әйткәнем юк та бугай?
Үтәсе гомерләр үтәр,
Бергә үтсәче шулай.

Яшь чактагыдай яктырып
Елмаеп торсаң иде,
Беренче мәхәббәтем син,
Соңгысы булсаң иде.

*Гыйнвар, 1995*

## Нәүрүз

Тамчы тамды — бозлар кузгалды,
Гел яктырып калды күз алды.
Гөрләвекләр чая, тереләр,
«Пи-пип» килә бәбкә-бөреләр.
Бәллүр карда чәчрәп нур яна,
Кыш яна да, Идел уяна,
Уяна җан, йоклап ятармы —
Яңа Елы килде татарның!

*Март, 1995*

## *Туган телнең туган көне*

Һәркемнең бар мәңгелектән
Дөньяга бар булган көне.
Кайсы чорда, кайчан микән
Халкыбызның туган көне —
Туган телнең туган көне?

Илнең теле ачылган көн,
Җанга моңнар тулган көне.
Илаһи вә илһамлыдыр
Туган телнең туган көне!

Өнсезлекне, уйсызлыкны
Гамәленнән куган көне.
Гамьле дә ул, шигъри дә ул
Туган телнең туган көне.

Котлы булсын, ил рухланып
Бәйрәм иткән Тукай көне;
Сакла, татар, язларда ул
Мәңгелеккә туган көнең —
Туган телнең туган көне!

*Март, 1995*

## Объектив хәл

*Татар әдипләренең*
*фотоелъязмачысы*
*Николай Седовка*

Син яшь чакта безнең сурәтләр дә,
Матур чыга иде, Николай.
Объективтан микән, чырайларга
Җыерчыклар төшә, ник алай?

Ә бит үзең бер дә үзгәрмисең,
Гел егетләр кебек, Николай.
Чәчләрең дә бөдрә, йөзең көләч,
Хикмәт нидә, әйтче, ник алай?

Безгә карап һаман туймагансың,
Рәхмәт инде, дустым Николай.
Объективтан без бер югалырбыз,
Рәсем генә калыр...Ник алай?!

Ә шулай да бүген елмаябыз,
Белмәгәннәр әйтер — ник алай?
Туган көннәрдә без һәммәбез яшь,
Объектив хәл шундый, Николай!

*Март, 1995*

## *Онытылу*

Кирәктер һәркемгә дә шул
Хакыйкатьне белү:
Үлү — онытылу түгел,
Онытылу — үлү...

*Апрель, 1995*

## *Тукай рәсеме*

Сынап тора сизгер күңел
Безне ерак көннәрдән,
Гүя шагыйрь беркайчан да
Елмаймаган, көлмәгән.

Күзләрендә бәгырьләрне
Үксетерлек моң тулы,
Милләт язмышын сагышлап
Сискәндергән шом тулы.

Елмаймый борчулы күзләр,
Мәэюс карый сызланып,
Үткәннәрдән карый Тукай
Киләчәкне кызганып.

Заманнарның хәвефләре,
Сынаулары азмы соң...
Тукай рухы борчылмаслык
Булсын милләт язмышы!

*Апрель, 1995*

## «Азнакайлар, әллә кайлар...»

Җырлый идек яшь чакларда:
«Китәм Азнакайларга;
Азнакайлар, әллә кайлар,
Китәм әллә кайларга!»

Ашкына иде йөрәкләр
Еракка, юл алырга.
Баш ташлап авыр еллардан
Китәргә, югалырга...

Тынгысыз татар, аптырап,
Гел урын алмаштырган,
Офыклар артында, имеш,
Нужасын адаштырган.

Кай тарафка омтылсаң да,
Дөнья бит ул түгәрәк.
Сагышлар белән әвәләп
Йөрткән язмыш-дүңгәләк.

«Китә казлар Донбасска...» дип,
Бу яктан да киткәннәр.
Читтән эзләгән бәхет ул
Туган җирдә икән лә!

Яшьлектәге җыр эзеннән
Килдек Азнакайларга.
Азнакайлар ерак түгел,
Яшьлек әллә кайларда.

Очрашулар, аңлашулар
Онытылмас гомергә,
Сагындырган көннәр белән
Бик якын сез күңелгә!

*Сентябрь, 1995*

## *Багышлау*

Бетховен язган
Аппассионата*.
Минем илһамны
Апас уята,
Апас уйлата,
Апас уйната.
Күңел түремдә
Апасым ята,
Иҗатымда ул —
Апас — сионата!

*Ноябрь, 1995*

## *Олы Бакырчыма*

Читтә гомер сөрдең, димә, инде —
Вакытлыча киттем,
Кайтыймчы...
Мәңгелектә җылы туфрагыңны
Ябынып лар гына
Ятыймчы...

*Ноябрь, 1995*

* Аппассионата — (итальянча) кайнар ярату.

## Карамасар

*Якташым Гали Хуҗига*

Урман кисүчеләр бригадиры итеп җибәргәннәр иде — шагыйрь авылына беренче килүем 1944 елның 19 ноябрендә булды. Иртәгәсен урманда 16 яшем тулган...

Сугыш җиле искән иде,
Монда урман кискән идек,
Ул юллар шул табылмас.
Ярты гасыр үткән инде,
Яңа урман үскән инде,
Безне беркем танымас.

Чамала, елларны сана:
Санасаң-санамасаң да,
Булды бит алтмыш җидем.
Карасаң-карамасаң да
Калды ла Карамасарда,
Бик еракта унҗидем.

Калды карлы урманнарда,
Адаштырган бураннарда
Сагалап салкын гына...
Интеккән, үзәккә үткән,
Әмма хыялыма илткән
Шул кышым сагындыра!

*Ноябрь, 1995*

## Кайтыйк әле

«Апас кешеләре... Фәхри Насретдинов, мин исән чакта, Сез, һәм Уфадан Бану Вәлиева җыелышып кайтыйк әле...»

*Сара апа Садыйкованың миңа Тукай клубында тапшырган язуыннан (30 июль, 1984 ел)*

Кайтыйк әле, кайтыйк туган якка,
Сөенешеп кошлар кайткан чакта.
Сагынудан җаннар канатланып,
Туган туфрагына тарткан чакта.

Кайтыйк әле, кайтыйк туган якка,
Моңсуланып кошлар киткән чакта,
Бушап калган кырлар сагышланып,
Күзге юллар безне көткән чакта.

Кайтыйк әле, кайтыйк, якташ җилләр
Күзне дымландырыпискән чакта.
Чакырганны көтмик. Гомер көтми —
Кайтыйк әле, кайтыйк, исән чакта!

*Ноябрь, 1995*

## Көзге белән хушлашу

(Монолог)

— Фәхри абый Насретдинов театрга репетициягә килгәч, көзге каршында: «Шушы алтын тавышымны үзем белән алып китәм бит!» — дип җырлый да, уфтанып куя. Ул үзенең терелмәслеген белә иде.

*Рафаэль Сәхәбиев сөйләде.*
*1985 ел, 18июнь*

Бик борынгы, озын гомерле син,
Күзәтәсең, көзге, тын гына.
Ишетмисең яшәү авазларын —
Дөнья бит ул тулы моң гына.

Якты йөзле булдың һәрчак миңа,
Бик күптәннән белгән дус идең.
Тормыш сәхнәсеннән төшеп барам,
Бүтән күрмәм сине, хуш инде.

Кешеләргә гел елмая идем,
Җыр юлдашы бит ул — елмаю.
Җыерылган кашларымны күрдең,
Сиңа гына булды моңаю.

Күрәсең дә син шул, ишетмисең,
Соңгы җырым шушы, тукталам.
Үзем белән алтын тавышымны
Алып китәм... Шуңа уфтанам...

Алмашыныр еллар, җырчыларның
Яңаларын инде күр, көзге.
Тик бер көнне, кайда Фәхриләр, дип,
Юксынырсың микән син безне?

*Ноябрь, 1995*

## *Якташларга теләк*

*Әгъләм Садретдиновка*

Шөкер әле, Тау ягында
Туган төбәк — Апас бар.
Таудай күтәрелергә дә
Сездә җегәр — запас бар.
    Безнекеләр шундый, диеп,
    Шатланасы килә бит.
    Тыйнакбыз да... туган як дип,
    Мактанасы килә бит.
Ирешелгән биеклектән
Берүк төшмәгез әле —
Без дә җиңне сызганырбыз...
Армый эшләгез әле!

*Ноябрь , 1995*

## *Хәтер аланы*

*«Хәтер аланы» әсәренең авторы Тәбриз Мөбарәков истәлегенә*

Үтә язмышлар
Хәтәр араны:
Күпме гомернең
Сүнеп калганы...
    Кайгы утының
    Өтеп алганы,
    Кәккүк ник шулай
    Бик аз санады?
Онытмагыз дип,
Сынап каравы —
Тын гына тора
Хәтер аланы...

*Март, 1996*

## Биштәр

Сугыш елларында безнең
Аркада биштәр иде.
Биштәрдә өмет булмаса,
Үсмерләр нишләр иде.

Җиңдек, җиңеләеп калдык,
Җилкәдә бала-чага.
Киләчәккә җилкендек без,
Җитәкләп чаба-чаба.

Шөкер әле, килеп җиттек,
Алда оныклар көткән,
Бала күтәрәсе түгел,
Оныклар җиңел икән.

Болары да тәпи китте,
Ә биштәр кала икән.
Ни баса дисәң, яшәлгән
Еллар аркада икән.

Алтмыш бишме, җитмеш бишме,
Ул безнең биштәр инде.
Биштәрдә өмет булмаса,
Картлар соң нишләр иде?

*Декабрь, 1995*

## *Гомер кояшы*

### I

Таңнан торып, кырга чыгып,
Без дә җир сөргән идек.
Көн әкрен үтә, диеп,
Зарыгып йөргән идек.

Сәгатебез — кояш иде,
Түзмибез,гел карыйбыз.
Ач күләгә озынлыгын
Чабаталап саныйбыз.

Ишәккә атланган кояш —
Хәрәкәте шул чама.
Төштән соң куянга күчә,
Куян ул яхшы чаба!

### II

Әкрен генә еллар үтте,
Тырышып гомер иттек.
Ишәктәй җигелеп без дә
Төшлеккә кояш илттек.

Уф, дидек! Җиңел булмады
Йөкләре замананың.
Хәвеф арты хәвефләре
Табыла һаман аның.

Безнең йөрешләр дә инде
Салмаграк шул, бер чама.
Ә менә гомер кояшы
Куянны узып чаба.
Чаба — шәфәкъка таба...

*Гыйнвар, 1996*

## Якташлар туганлыгы

Алмашына заманнарның
Сәясәт дигән фәне —
Гомер буе «иптәш» идек,
Хәзер инде «әфәнде».

Сүз белән уйнап, замана,
Кыландырып маташма.
Бергә — берәгәйле иткән
Иң якын сүз — «якташ» ла!

Сагынышкан күңелләрне
Шушы сүз бергә җыйган.
Шушы сүзнең кочагына
Бүген барыбыз сыйган.

Туган як дигән бишектә
Һәркемнең туган моңы.
Мәңге өзелмәс шәҗәрә —
Якташлар туганлыгы!

*Гыйнвар, 1996*

## *Халык артисты Айрат Арслановка*

(Мәдхия)

Татар улы, шигъриятнең чын үзе син:
Синдә моң да, горурлык та, синдә гайрәт.
Туган телнең даһилары исеменнән
Син лаеклы, вәкаләтле илче, Айрат.
Күрде илләр, ишеттеләр һәр тарафта,
Шигарендә Тукай — Гимн, Җәлил — Байрак.
Күтәрелдең һәм күтәрдең күңелләрне
Сәхнәбезнең уртасында күкрәп-кайнап.
Халкыбызда бу затлылык вә күркәмлек
Киләдер ул борынгыдан, алыслардан.
Юк, вакланмый, яши милләт, иманы сау,
Туа тора дөньябызга Арсланнар!

*Март, 1996*

## *Сара Садыйкова урамы*

Канатлы моң булып таныш исем
Күпме илләр, җирләр урады.
Район мәркәзендә урын алды —
САРА САДЫЙКОВА урамы.
Дөнья булгач инде бар да булыр,
Яңгыры да явар, бураны.
Җырларыңдай гел яктырып яшә —
САРА САДЫЙКОВА урамы.
Бәхетле бул туган ягыңда, дип,
Ул кояшлы язмыш юрады...
Килер көннәр синнән, җырлап узсын —
САРА САДЫЙКОВА урамы!

*Ноябрь, 1996*

## Тауларым, үзәннәрем

Тауларым, үзәннәрем,
Үзәкне өзгәннәрем,
Чит җирләрдә ничек кенә
Сагынып түзгәннәрем.

Далалар юатмады...
Яшьлегем ерак калды...
Язлар булып, күзләр булып
Мәхәббәт елап калды.

Таулардан төшкәннәрем,
Үзәннән үткәннәрем,
Агымсулар булып аккан
Юксынып көткәннәрем.

*Ноябрь, 1996*

* * *

Яшәдемме мин үз гомеремне,
Җырладыммы мин үз җырымны?
Халык арасыннан балык итеп,
Тотты мәллә заман җылымы?

Кылган гамәлләрне барладым да,
Шулай тиештер дип килештем:
Ирешердәенә ирешмәдем,
Ирешмәстәенә ирештем.

*Гыйнвар, 1997*

## *Туганнарны барлыйм Яңа елда*

Урманнарда чыршы мәңге яшел,
Ылысларын кайчан коядыр?
Югалтуның сары сагышларын
Сызланганнар гына тоядыр.

Туганнарны барлыйм Яңа елда,
Күңелемдә газиз исемнәр.
Аларның да шушы чыршылардай
Яшәүләре яшьли киселгән.

Чыршыларда шәмнәр генә янмый,
Үткән гомеркәйләр яна ул.
Йөзләренә карап сөенергә
Якыннарым юк бит, Яңа ел!

Түребездә балкып торган чыршы
Үткән шатлыкларны коясы...
Яңа елны каршылаган саен
Аерылуны күбрәк тоясың.

Ә бит еллар — гасыр оныклары —
Ерак офыкларны күрәчәк.
Нәсел чыршысының тирәсендә
Әйлән-бәйлән уйнар киләчәк.

*Декабрь, 1996*

## *Яшьлегемә кире кайтмас идем*

Үтсә иде, дигән көннәремне,
Ятим елларымны сагынмыйм.
Бер күргәне җиткән, язмышымны
Кабатламас идем тагын мин.

Котылганга шатмын ул дәвердән,
Киләчәккә колач ачтым мин:
Борынгылар кыз урлаган сыман
Мәхәббәтем алып качтым мин.

Югалтулар гына ул гомердә,
Соңрак булды минем табышым.
Гомер буе үзем белән бергә
Яшьлегем, син — татлы сагышым.

Югалтулар, мохтаҗлыклар белән
Җанымның гел әрнеп торганы.
Яшьлегемә кире кайтмас идем,
Безнең яшьлек — сугыш корбаны.

*Декабрь, 1996*

## Әле дә бар Яңа еллар!

Еллар бозлы, юллар тайгак,
Атлыйк әле ипләп кенә,
Яңа бәхет теләп кенә,
Булганнарын сипләп кенә.
    Яңа ел ул — өмет көне,
    Гомереңдә бер бусага.
    Ымсындырып килә бит ул,
    Яңа булыр, ни булса да.
Култыклап ал хатыныңны,
Урамнары бозлавык, дип.
Җил-җил итә, кызлар үтә,
Егылмаек... «кызлавык» бит!
    Яңа кәеф, иске кием,
    Шөкер итеп киик әле.
    Еллар елдан аерыла,
    Без гел бергә, диик әле.
Юкка хәзер дөньясы тук,
Яшик әле барлап барны.
Сер бирмик яшь аякларга,
Биетик карт бармакларны.
    Иңдә йөрттек тормыш йөген,
    Күтәрмәслек түгел әле.
    Читтән ярдәм көтми генә
    Күтәрик, әй, күңелләрне!
Табын тулы истәлекләр,
Без гомергә бергә инде.
Елаган да көлгән инде,
Күрәсене күргән инде.
    Үткән елгы кар өстенә
    Быел яңа карлар ява.
    Кар да яңа, бар да яңа,
    Чак кына, шәт, без дә яңа?!
Әле дә бар Яңа еллар,
Мин сөенеп торам шуңа.
Туганнарым, дуслар бергә,
Төннәр якты, юллар шома!

*Декабрь, 1996*

## *Тормыш-язмыш*

*Рәссам Фаил Зыязовка*

Тәүге мәхәббәтем — Рәсем иде.
Тик теләгем чынга ашмады:
Сугыш вакытында сагышымны
Шигырь итеп яза башладым.

Ымсындырып калган татлы хыял —
Мин аны бик озак сагындым.
Үкенечле аҗаганнар булып
Күңелемдә төсләр кабынды.

Кырыс җирдә тормыш шаярта шул,
Бирмәде ул күктән көткәнне.
Шигърияtем, диеп йөргән берәү,
Бәлкем, рәссам булып киткәндер.

Алмашканбыз, ахры, хыялларны,
Язмыш шулай кушкач, нишләсе?!
Бердәй булгач җанның сусаулары,
Очраштырды илһам чишмәсе.

Үпкәләмә, Рәсем-мәхәббәтем,
Шигырь юлларыннан үттем мин —
Насыйп булдың ныграк сөйгәннәргә,
Үз тиңеңә булдың, үкенмим.

*Гыйнвар, 1997*

## *Хәким чишмәсе*

*Күренекле җәмәгать эшлеклесе*
*Рафаэль Сибгат улы Хәкимгә —*
*50 яше белән котлап*

Язмышның ишарәседер,
Тамгалы булгансың бит —
«ФАЗЫЛ ЧИШМӘСЕ» белән син
Бер елда тугансың бит!

Сөенгән шагыйрь, бишектә
Сугыштан соңгы улы:
«ТИҢ БУЛЫП БЕЗНЕҢ ЕЛЛАРГА
БАЛКЫСЫН ГОМЕР ЮЛЫ»*.

Фал булып ачылган шигырь
Киләчәк көннән аңа:
«АЗАТЛЫК СҮЗЕ ШАУЛАДЫ,
ЯШЬЛӘРЕН СӨРТТЕ АНА».

Тукай урамында тудың —
Очраклы язмыш диген!
Сезнең ул нурлы нигезне
Шул елда күргән идем.

Карыйсың бүген дөньяга
Әткәң күзләре белән.
Котлыймын, рухы сөенеп
Әйткән сүзләре белән:

«СИН УЛ — БАРАСЫ ЮЛЫМА
ЯКТЫЛЫК СИПКӘН,
ӨЗЕЛМӘС ҖЕПЛӘРЕМ СИҢА
БӘЙЛӘНГӘН ИКӘН...»

* Сибгат Хәкимнең әлеге шигырьләре улы Рафаэль туган 1947 елда язылган.

Хаким* түгел,Хәким** булып,
Бик тә белеп тугансың,
Президент бәйрәме белән
Янәшә үк булгансың.

Сезгә әле бу заманның
Төеннәрен чишәсе;
Кыйблабызны югалтмас ул
Хәкимнәрнең чишмәсе!

*Февраль, 1997*

## Киләчәгең

Сагынырлык көннәр бардыр ла ул
Хәтер яшьнәп искә алырлык.
Елларында дәвер йөге иде,
Бәгырьләрне басты авырлык.

Безнең гомер шулай башланды шул:
Канлы — сугыш, мохтаҗ — тынычлык.
Алга карап көттек җиңеллекне,
Шушы өмет белән тырыштык.

Әйләнде дә куйды заманалар,
Тот капчыгың! — бирде көткәнне;
Киләчәгең бер көләчәк икән,
Ул кабатлау икән үткәнне.

*Март, 1997*

* Хаким — хөкем итүче, судья.
** Хәким — философ, галим.

## Яшьлек истәлеге

Туган якларымда
Урман актан гына —
Гел каеннар, ап-ак каеннәр.
Яшьлек сафлыклары,
Керсез аклыклары
Ак каеннар белән каелган.

Без хистәшләр идек,
Хистә яшьләр идек,
Яшьлек үтмәгән соң ул кемнән.
Тыныч бүген күңел,
Үкенерлек түгел,
Сагынырлык икән ул көннәр.

Яшьлек якларында
Өмет актан гына,
Акчарлактай ап-ак каеннар.
Әйләнәм дә карыйм,
Үткән юлны таныйм —
Ак канатлар белән каелган...

*Февраль, 1997*

## Әй гомерләр

Сикереп чаба көннәр,
Әй гомерләр тиз уза.
Бу нинди чибәр, дисәң,
Яшьлегең чәчәк суза.

Анда — аулакта көтеп
Серле таң дәшкән чаклар,
Сагышларга сабышып
Кызлар көнләшкән чаклар.

Яшьлек гомере кыска,
Ансын да югалттык ла...
Озын гомерләр телик
Мәхәббәтле картлыкка.

*Март, 1997*

## Ни чәчсәң...

Урысча укыды балаң,
Урысчалап булды һаман:
Үгиләнде ата-бабаң —
Чү, укындырды заман.

Токымың иман алмашты,
Инде аптырап торырсың...
Милләт әйтер туп-турысын:
«Ни чәчсәң, шуны урысың!»

*Апрель, 1997*

## *Яшәү төсе*

Тарих даласыннан тәгәрәргә
Без дүңгәләк түгел тамырсыз.
Безнең эзләр тирән тарихларда:
Һәйкәл-шәҗәрәдән танырсыз.

Таш каладан комнар ишә-ишә
Узып тора гасыр-давыллар.
Киң кырлары белән мәңгелеккә
Береккән дә яши авыллар!

Уңдырышлы туфрак — безнең хәтер,
Чәчеп-урып шуны яңартам —
Үлемсезлек дәрте сүнмәсен дип,
Язлар саен җанда янар таң.

Киләчәкләр килер-китәр алар,
Син сорама минем яшемне.
Гасырларны ялгар орлык бирә
Мәңгелек төс — яшәү яшеле.

Чәчелмәгән кырдан тәгәрәргә
Без дүңгәләк түгел тамырсыз —
Гел өзелмәс безнең кавемне сез
Үлмәс арышлардан танырсыз.

*Март, 1997*

## Без — Олы Бакырчылар!

Нинди дисәң, шундый инде
Без — Олы Бакырчылар:
Юаш күренгән малайдан
Мәйданда батыр чыгар,
Үзләре сирәк дәшсә дә,
Сүзләре тапкыр чыгар!
«Мин-мин» дия башласалар,
Мәгънәсе такыр чыгар...

Шуңа күрә мактанмыйбыз
Без — Олы Бакырчылар:
Эш терәлсә дә сер бирмәс
Игенчеләр-кырчылар,
Үз дигәненә ирешер,
Кыенлыкларга чыдар —
Бакырдан көмеш чыкмас дип,
Тынып калмас җырчылар!

Алтын куллы, көмеш телле
Авылда гармунчылар,
Туган яктан аерылгач
Һәммәбез дә моңчылар.
Читтә алтын таптым дисәң,
Чынында бакыр чыга,
Туган туфракның алтыны,
Ул — Олы Бакырчыда!

*Март, 1997*

## Сурәт эзләү

*Эрот Зариповка*

Сурәтеңне язам диде рәссам.
Ничек көйләним дим, төшендер?
Ак мыегын сыйпап елмайды да:
«Күрсәт, диде, якын кешеңне».

Балаларны күрде, туганнарны,
Бик канәгать булып утыра.
Сүзе — миндә, күзе гел аларда—
Сөйләшә дә сакал сыпыра.

Шәҗәрәмне алып карады да
Сораштырды җиде бабамны.
Тарих төпләренә төшеп менде,
Инде барысы да таманмы?

Сурәткә дә чират җитәр дисәм,
Ул хакта гел авыз ачмады:
«Күрик әле туган ягыңны,— ди,—
Белик синең авылдашларны!»

Яланаяк йөргән эзләремнән
Ялан җаным сагнып йөгерде...
Сиздем шунда, рәссам күзләрендә
Минем сурәтем дә өлгерде.

Хәйләкәр дус,
мыштым фәйләсүф шул,
Белеп чамалаган, күрәсең —
Туганнардан, туган яктан башка
Тумас иде минем сурәтем!

*Март, 1997*

## Мин Кайбычка кайттым

Кайбычымда калды минем яшьлек,
Яшьлегемдә калды Кайбычым.
Өзеп кенә әйтә алмас идем,
Күбрәк сагынамдыр кайсысын?!

Заманалар берчак үги итте,
Кайнап торган үзәк сүрелде,
Олы юллар аны читләп үтте,
Яшьлек йөргән эзләр күмелде...

Югалмаска тиеш идең, Кайбыч,
Чынга ашты бәхет юраулар —
Бәрле ярларына ташып үсә
Яңа язмыш булып урамнар.

Танымыйча хәйран калырлык шул,
Карасаң да аның кай очын.
Мин Кайбычка кайттым...
Минсез генә
Яшьлегенә кайткан Кайбычым.

*Март, 1997*

## *Озон катламы*

Канатлары сыман фәрештәнең
Җир өстендә озон катламы —
Әткәм-әнкәм әхлак-фатихасы
Күңелне дә шулай саклады.

Имансызлык белән сыный дөнья,
Миражлары юлдан яздыра—
Тәмнәр-тәннәр белән ымсындырып,
Рәхәт биреп алдап аздыра.

Хыялларны корбан итә-итә
Тормыш сиратларын кичәсең,
Гөнаһлардан хали түгелбез дип,
Нәфес агуларын эчәсең.

Үтә көннәр тәүбәләрдән качып,
Үзең белән үзең тартышып.
Дөмбер-дөмбер намусыңа кага —
Колакларда шайтан алкышы.

Гел югара бара кешелекнең
Вөҗдан дигән озон катламы.
Изге урыннарны били килә —
Бии килә азгын катламы.

*Май, 1997*

## *Язда калган күзләр*

Без еллар һәм урын алыштырып
Яшьлегеннән киткән качаклар;
Өзелгәннәр, дисәң, сагындырып,
Таныш кыллар зыңлый кайчакта.

Очып кайтам йөргән урамнарга,
Өнем итеп татлы төшемне.
Яшьлек күкләреннән, күңелкәем,
Юксынган бу җиргә төш инде.

Таныш йортлар, якын кешеләрне
Син ымсынып хәзер эзләмә.
Ярты гасыр күчкән, җиле кискән,
Син үзең дә инде үзгә лә.

Язын күзләр тышта кала иде,
Төштә калган бүген күзләрем:
Мәхәббәтнең иясен мин кайтып
Кызлар арасыннан эзләдем...

Өзелгәндер, дисәң, сагындырып,
Әрнеп кыллар зыңлый кайчакта:
Яшьлек үзе үткән,
Мәхәббәттән
Без ирекле киткән качаклар...

*Май, 1997*

## *Хәерле юл!*

*Дамирга*

Гасырга да, үзеңә дә
Әле егерме генә.
Килер дәвернең түренә
Туганым, йөгер генә!

Омтыл да син, күтәрел, оч,
Мәхәббәт канат булсын.
Гомереңдә һәр яңа көн
Бәхетле булып тусын.

Иманлы булып кал һаман
Заманнар үзгәргәндә.
Хәерле юл —
Киләчәккә
Сәлам әйт безләрдән дә!

*Июнь, 1997*

* * *

Кошлар китә, еллар китә,
Китмидер януларым,
Көзге яфраклар шикелле
Коелып калуларым.

Язлар килми калмас диеп,
Гел өмет иткәннәрем,
Киләчәктә язмаганны
Үткәннән көткәннәрем...

*Октябрь, 1997*

## Кырык яшь уйландыра

*Җәүдәт улыма*

Туган көннәр уен булган,
Бусы бит уйландыра.
Кай арада нәкъ кырык яшь
Тулган да куйган гына?!

Яшьлек кенә түгел, инде
Гомерләр үтеп бара...
Ниләр кылдың? Гамәлләрнең
Йомгагын сүтеп кара.

Моңа кадәр тормышның гел
Күбрәк татысаң тәмен,
Сизенә күңел, артачак
Борчуларың һәм гамең.

Елларны узып чабабыз,
Дөньясын куа-куа.
Бер сынауны үттем дисәң,
Яңасы тагын туа.

Кырык яшь диләр... Табында
Утырам эчтән тынып —
Берәм-берәм дүрт балама
Тулды лабаса кырык!

*Сентябрь, 1997*

## *Минем яшьлегемнең кызлары*

Шул мизгелдер — язгы сабантуйның
Дәрте ташып, тәмам кызганы:
Яшел чирәмнәрдә очып бии
Минем яшьлегемнең кызлары!

Сырма киеп, мамык шәл ябынып
Арба тартып көлеп узганы...
Сер бирмәде, сынын туры тотты
Минем яшьлегемнең кызлары!

Буыннары безнең буынның ул —
Сызланса да эчтән сызганы...
Нужа йөген иңнәрендә йөртте
Минем яшьлегемнең кызлары.

...Сабантуйга быел кайткан идем,
Толымнары җилдә тузмады;
Иң беренче рәттә гел әбиләр —
Минем яшьлегемнең кызлары...

*Сентябрь, 1997*

## Картлык — шатлыкмы?

*Җәмил улыма*

Картлык — шатлык түгел, диләр,
Өзеп куйган шарт юктыр —
Гомернең һәр фасылында
Үзенчәрәк шатлыктыр.

Арта бара нәсел-нәсәп,
Тармаклана-киңәя.
Шатлыклары да өстәлә,
Юк монда һич киная.

Һәр тумыш көндә — туган көн,
Берсен дә онытмыйсың —
Бәллүр касәләр чыңлатып,
Күккә чөеп котлыйсың.

Шөкер, зарыкмый-тарыкмый
Җитмешкә җиткән мәлем.
Яшьләр белән рәттән заман
Безне дә җиккән әле!

Картлыгымда да эшем бар,
Җан асрарлык төшем бар.
Кишер кимерерлек әле,
Күз тимәсен, тешем бар.

Улым белән икәү бергә
Проспекттан узганда,
Әллә аңа, әллә миңа
Елмаялар кызлар да.

Картлык — шатлык, рәхәтләнеп
Чибәрләрне күзлимен —
Кайсы оныгыма кайсы
Ошар, диеп эзлимен...

Уянып-уйланып ятам,
Йокым качкан таңнарда—
Өлкәнлекнең яшьлеген дә
Кирәк икән аңларга.

Болай булса, ярап тора,
Аерма картлыгымнан —
Исәнлекне, исәрлекне
Искәргән шатлыгымнан!

*Октябрь, 1997*

## Ындырчының ике чишмәсе

Туган якка кайткан чакта
Ындырчыдан узамын —
Колач җәеп каршы ала
Һәрчак олы урамың.

Һәйкәлле чишмәң белән син
Исләремә төшәсең.
Инде ачтың яңасын да —
Мәктәп — белем чишмәсен.

Үткәнең дә, бүгенгең дә —
Ике чишмә арасы,
Киләчәгең дә йөгереп
Үргә үрләп барасы.

Талларың яшь тамызмасын,
Бәхет кошын кундырчы —
Көләч тәрәзәләр белән
Куандырчы, Ындырчы!

*Ноябрь, 1997*

## Котбетдин котлавы

*Аяз Гыйләҗевнең 70 яшенә*

Халкыңда җорлык булмаса,
Холкыңда җорлык булмаса,
Шаян сүз каян чыгар?
Мин — Котбетдин,
                син — Сәйфетдин!
Без бит синең белән, Аяз,
Күптәнге Чаянчылар.

Инде сирәк елмаябыз,
Кайчак хәтта моңаябыз —
Йөрибез җитди генә.
Нәрсә җитми?
Яшьлек җитми:
Син — Сәйфетдин,
                мин — Котбетдин
Булган чак җитми безгә!

Ә бит нәкъ шулар хәлендә
Килеп ирештек бүгенгә —
Әмма да кызык иттек,
Үзебез дә көтмәгәндә
Син — Сәйфетдин,
                мин — Котбетдин
Яшьләрен узып киттек.

Уңышлардан баш әйләнмәс,
Инде кызлар да бәйләнмәс,
Эшләп яшә, Сәйфетдин:
Уй-фикерең һаман нык, дим,
Каләмеңне иплә тот, дим,
Чордаш, җордаш һәм дә кордаш,
Котлый сине — Котбетдин!

*Гыйнвар, 1998*

## *«Патша хатыны»*

Борын-борын заман түгел,
«Торгын-торгын заман»да,
Иҗат йортында идек без
Мәскәү яны — урманда.

Беркөнне Рәсул Гамзатов
Хәл белешергә кергән.
Әйдәгез, дидек, сезләргә
Һәрвакыт урын түрдән!

Тау халыклары кунакчыл,
Бездә дә шул чагылган —
Атаклы Апас җиреннән,
Без дә бит Тау ягыннан!

Колач җәеп безнең халык
Кунак каршына баса:
Кая гына утыртыйм дип,
Үрсәләнә ләбаса.

Ул көнне чын шулай иде,
Ике генә урындык,
Кунак белән мин утырсам,
Хатынга бит урын юк.

Иҗат йорты хәлен белә
Гамзатовча зур итеп,
Бик мөлаем елмайды да
Әйтеп куйды җор итеп:

— Царица каршында мин, ди,
Торамын аяк өсте!
(Гариф Ахунов тавышы
Кылт итеп искә төште...)

Күрче мәхәббәт җырчысын,
Вәт ничек маташтыра!
(Бездә шулай сайрый белер
Тик Рәдиф Гаташ кына...)

«Царица» дигәч, хатын да
Канәгать, бер дә харап.
Горур гына төшеп кунды
Өстәлгә затлы шәрап.

Кунакны тыңлап үзем дә
Рольгә керә башладым,
Патша хатынының ире —
Димәк, мин дә патшамын!

...Урман арасында ул йорт,
Гамзатов күршем иде,
Безнең очрашуларның бу
Ничәдән берсе иде.

Әй, серләшкән идек тә соң
Мәскәүләр тарафында.
Нинди сүзләр булмас, дисең,
Патшалар арасында!

Хәзер ничек хәл-әхвәл, дип,
Кызыксынасыз, беләм.
Тату гына яшәп ятыш
«Патша хатыны» белән!

Тау халыклары тыйнаклар,
Бездә дә шул чагылган —
Атаклы Апас җиреннән,
Без дә бит Тау ягыннан!

*Гыйнвар, 1998*

## *Элеккечә*

Балачагым чаба яланаяк,
Яшел чирәмнәрдә ак кырау.
Аяктагы «чеби»ләрне көзен
Бер санарбыз, туктап чак кына.

Еллар авыр дигән булалар да,
Җиңел була иде ач карын.
Кайсы якка борылсак та, күрдек
Юмарт нужа колач ачканын.

Сабантуйсыз үткән ул елларда
Сикереп мендек хыял-атларга.
Бар байлыгың — горурлыгың иде,
Тырыштык без аны сакларга.

Елан-еллар кабат килеп чага
Асфальт юллар буйлап сузылып.
Без һаман да элеккечә калдык,
Зарланмаслык булып «бозылып».

*Февраль, 1998*

## Сүрелмәс мәхәббәт

*Яраткан артистыбыз, дустыбыз Нәҗибә Ихсанига*

Еллар үтә, мәхәббәтнең
Балкышы сүреләдер —
Күзләрдән да сизеләдер,
Йөздә дә күренәдер.

Ә минем берәү, берәвем
Елдан-ел яраттыра.
Сөбханалла, күз тимәсен,
Дип кенә карап торам.

Хатын да белә, хуп күрә,
Бик урынлы дип саный,
Аның да бит яратканы
Син — Нәҗибә Ихсани!

Җиде миллион татар да
Шул фикердә, күрәсең.
Түзә Туфан* ничек барсын
Көнләшеп өлгерәсең!

Ихсани дим, Ихласи дим,
Елмай һаман, Нәҗибә,
Күңелләрне яктыртуда
Бик зур синең тәҗрибә.

Еллар үтә, мәхәббәтнең
Сүрелми икән чыны —
Алкышлары белән халкым
Раслап тора ич шуны.

*Февраль, 1998*

* Туфан Миңнуллин.

## *Яңа Кайбыч, саумы!*

*Азат Хәнифәтуллинга*

Яшьлегемдә Кайбыч утларының
Балкышыннан күзем чагылды.
Төшләремдә нурлы урамнарын
Элеккечә күреп сагындым.
Элеккечә сыман иде һаман
Якты йөзләр, сөйгән карашлар.
Бер без генә микән яшьлегеннән
Еракларга китеп адашкан?!
Юксынмадың, эзләмәдең син дә,
Омтылсам да мин дә кайтмадым.
Матур чагы калсын күңелдә дип,
Сагныр өчен, ахры, сакладым.
Яңа хәтер — яңа Кайбыч дәште,
Тәэсирләнеп кайттым, ашкынып.
Иске ягын күреп моңсуландым,
Яңасыннан тордым ятсынып.
«Мине танымаган урамнардан
Хисләремне тыеп атладым.
Елмаюлы колачларын ачкан
Яшьлек дусларымны тапмадым...
Бер күрүдә гашыйк булган чакны
Яңа Кайбыч янә яңартты —
Үткәннәрең, бүгеннәрең белән
Яңабаштан сине яраттым.
Бил алышып авыр еллар белән
Батырларча мәйдан тоткансың.
Төшләргә дә кермәс могҗизадай
Күз алдында балкып чыккансың.
Үсәр әле шулай безнең яклар,
Биеклекне яулап, киңлекне —
Яңа заман,
Яңа дуслар, саумы!
Яңа Кайбыч — син дә минеке!

*Апрель, 1998*

# Кем ул Роберт Миңнуллин?

*Татарстанның Тукай, Җәлил,*
*Алиш исемендәге һәм халыкара*
*Андерсен бүләкләре лауреатына*

Риндирәк кеше ул дисәм,
Сез әйтерсез, мөгаен:
Әкиятләре аның да
Алиш сыман мөлаем.

Таныйсызмы үзен дисәм,
Трибунада чагында —
Чамалыйбыз диярсез сез
Җәлилнең чалымын да.

Референдум үткәрсәң дә
Икеләнер хәл бармы:
Тукайны белгән һәр татар
Беләм диячәк аны!

Андерсен әкиятенең
Чынлыгын сизәдер ул,
Шул кадәрле мактауларга
Ничекләр түзәдер ул!

Хәтта Ш.Галиевкә дә
Охшаган ягын беләм:
Теңкәләргә тия инде
Шул тыйнаклыгы белән!

Әйтә алмыйм, киләчәктә
Гел яхшырак булмас, дип,
Яшь бит әле,
Арабызда
Ул бит иң яшь классик!

*Май, 1998*

## *Сабан туена ничә ел?*

Сабан туеның тарихы
Баксаң, хәйран итәрлек:
Халкымның бу йоласына
Ике мең ел икән бит!

Шуннан бирле зәңгәр күктә
Сабан туе әләме —
Колгаларга үрли-үрли
Без яулыйбыз галәмне.

Ике мең ел буе татар
Ил-мәйданда көрәшә,
Баш аркылы чөеп тора —
Хәрәмләшү кермәсә.

Агач аттан ауганда да
Чын иярдән төшмәгән.
Татарлыгын саклап-раслап
Җанында ат кешнәгән.

Ике мең ел — гамь-хәсрәтле
Капчык аның кулында.
Кайчак үзе селтәп бәргән,
Ялгышканда егылган.

Үз хәле хәл булганда да
Шаяртткан да көлдергән:
Налук бурычын илтәм дип,
Күкәй кабып йөгергән.

Ике мең ел мәйданнарда
Нужасыннан көлмәктә —
Әче катык эчә-эчә
Акча эзли чүлмәктән.

Җиң сызганып сыныйк әле,
Дәрт-дәрманнар артканмы,
Аяк терәп тартып карыйк
Мөстәкыйльлек арканын.

Усаллыкның күзен бәйлә,
Ашмасын исәпләре —
Буш чүлмәккә генә төшсен
Селтәнгән кусәкләре.

Тагын ике меңнән соң да
Татарча көрәшербез.
Туган тел батыр калырмы,
Кем булып сөйләшербез?

Батыраеп кер мәйданга,
Батыр булып чык әле,
Сабан туеның батырсыз
Калган чагы юк әле.

Җилфердәсен гасырларда
Безнең кодрәт билгесе,
Илдә әләм, билдә әләм —
Сабан туе сөлгесе!

*Июнь, 1998*

## *Мәдәният сараен ачканда*

Котлы булсын бу матур йорт,
Сөенеч тулып торсын.
Төзүчеләргә рәхмәтнең
Һәйкәле булып торсын.
Җиде яшьтән җитмешкәчә
Көттем күркәм бинаны.
Бүтәннәрдә күргән саен
Гел юксындым мин аны.
Асфальт юл салу — хыяллар,
Өметләр тулы иде.
Көне килде — Бакырчыбыз
Чыннан да Олы инде!
Мәдәният һәм дә мәчет
Жан таяныр ноктасы.
Әхлак, гамәлне тиешле
Биеклектә тотасы.
Күңелләргә шатлык өстәп
Балкыр тәрәзәләрең.
Дәрт өстәр ул — хезмәттә дә
Артыр дәрәҗәләрең.
Ишекләрең ачык булсын,
Буш тормасын урыннар.
Биеп-җырлап сәхнәләрдән
Узсын яңа буыннар.
Сагынып кайтсын түренә
Читкә юл алганнар да.
Уй-хәтердән җуелмасын
Яуда югалганнар да.
Киләчәккә барсын еллар
Бәхетләр юлы белән.
Әйтәмен шаһит әткәйнең
Яраткан сүзе белән:
«Таң атканны шуннан таныйм —
Күктәге аклык белән,—
Сез дусларны тәбрик итәм
Бүгенге шатлык белән!»

*Август, 1998*

## Дөнья

Салкын айда, салкын елда,
Тудык салкын гасырда,
Бозлы юллар, тозлы җилләр —
Бирде язмыш барсын да!
Әмма карамыйм гомерне
Гел әрнүләргә бәйләп —
Заманнар зарлы чакта да
Замандашларым әйбәт.
Безнең җаннарны киләчәк
Җырлардан таныр әле.
Салкын дөнья аз булса да
Җылынып калыр әле.

*Ноябрь, 1998*

## Сугыштан кайтмый калган 169 авылдаш истәлеге

*Фән Вәлиәхмәтовка*

Әле кайчан гына кебек сезнең
«Герман көе»н җырлап үткәннәр,
Үзләре дә җиргә китеп бара
Гомер буе сезне көткәннәр.
Күз алдымда һаман исәннәр сез,
Шул сагышлы моңны тыңласам.
Сез китәсез һаман, сез китәсез,
Җырларыгыз калды тынмаска.
Һәйкәлләргә карап, әчтән елап,
Җан сыкранып, әрнеп үтәбез.
Кайтулары насыйп булмады шул,
Күңелләрдән генә китмәгез...

*Май, 1999*

## *Шулай инде*

Без нинди яшь, без заманча диеп,
Күтәрелә җирдә шәһәрләр:
Биек йортлар өстән генә карый,
Масаючан инде, каһәрләр.

Уңдырышлы туфрак — иген кырын
Үз астына һаман тарта бара.
Эшләүчеләр кими, күшәүчеләр
Үрчи бара, һаман арта бара.

Уйлап баксаң, каян килгән димсең,
Авылдан бит туган кала да!
Шулай инде, җирдән аерылгач,
Анасын да онта балалар.

Башка чыккан шәһәр, үпкәләмә,
Каршы куймыйм әнкәң-авылга.
Җирне, илне күтәрергә аңа
Бик авырга килә, авырга.

*Декабрь, 1998*

## Иж-Бубыйда көз иде...

Ярты гомер элек килдем —
Иж-Бубыйда көз иде.
Ә кызларында яз иде —
Сөеп баккан күз иде.
Аһ, димичә түз инде!

Күңелләр ым алышты да,
Сүзләр тыелып калды.
Югалтулар, үкенүләр
Күздә җыелып калды.

Еллар үткәч, очраштык без,
Ачылдың көтмәгәндә.
Әйтерсең кыр казларыдай
Елларым үтмәгән дә.

Аңлашып та булыр иде,
Инде язмыш көнләшми.
Әмма үзең сөйлисең дә,
Күзләрең бит эндәшми.

Ярты гомер үткәч килдем,
Карлар күмгән эз иде.
Кызлар һаман язда икән,
Бездә китмәс көз инде.
Аһ, димичә түз инде!

*Гыйнвар, 1999*

## *Яңа Кайбычтан беренче хат*

*Фәридә Нигъмәтҗановага*

Яңа Кайбыч — иске адресым ул,
Яшьлектәге якты төбәгем.
...Елмаюлы назлы тавышыңны
Ишетергә күпме теләдем.

Син бит инде ул якларда түгел,
Мин бит синле чакны сагындым.
Үкенечкә үзең сәбәпче, дип,
Үртәр өчен мәллә табылдың? —

Үткәндәге көнем, кемем диеп,
Ымсыныплар йөргән чак иде.
Бик тә таныш уй-хисләре белән
Күңел кузгатырлык хат килде.

Синнән көткән, син язмыйсы хатны
Мин белмәгән сеңел җибәргән —
Чакырсаң да кайтып булмаслык шул,
Яшьлек дигән ерак җирләргә.

Таныш түгел нинди күңелдәш дип,
Укыйм хатны ничә кат инде:
Сагынуы, юксынуы белән
Кайбыч үзе язган хат иде —
Киләчәктән килгән зат иде.

Узган безнең яшьлек заманасы,
Бүтән йөрәкләргә кайта яз.
Кайтанурлар булып иркәли дә,
Ымсындырып китә кайтаваз...

*Гыйнвар, 1999*

## Канатларым

*Җәүдәт Гаффаровка*

Китkәнемә шактый еллар булды,
Шатлыгы да узган, кайгысы.
Гел кояшлы, мәхәббәтле итеп
Күңелемдә йөрттем Кайбычны.

Кызларыңдай, ахры, үзеңнең дә
Бар сөйкемле, серле сөягең —
Җырларымның туган җире итеп
Юксынып гел сине сөйләдем.

Бакырчымны Кайбычыма ялгап,
Яшьлегемдә сардым киләпне.
Биштәр буш та, күңелләр хуш иде —
Уртак урман җырга өйрәтте.

Шул ук илһам аерды да бугай —
Моң мәркәзе үзенә каратты;
Читкә очасымны белсәгез дә,
Сез бирдегез ике канатны.

Ә җырларым һаман онытмаган
Кайтыр тарафларга юл барын;
Озатканнар көтеп алалмаса,
Каршылады гаярь улларың.

Киләчәген күрдем мин Кайбычның,
Күзләрендә таныш якты нур —
Шушы булыр минем сагынган җир,
Канатланып кайткан як булыр!

*Февраль, 1999*

## Омтылыш

*Гарәф Шәрәфетдиновка*

Кырыс булды безгә бу тормыш.
Канат бирде хыял-омтылыш.
Күк капусын ачар дип алда
Без ышанып килдек Казанга.

Шуңа хәтле булган табышың —
Сугыш елларының сагышы,
Моң-әрнүләр, күңел — биштәрдә,
Биштәр авыр иде, нишләргә...

Кырлар киңлегенә күнеккән,
Офыкларда үскән егетләр
Алыштырды тормыш рәвешен,
Һәр максатлы тапты дәү эшен.

Рәхмәт, Казан, күтеп алгансың,
Ярты гасыр үтте аннан соң.
Очраштырдың — таптык дусларны,
Үтәдек без намус кушканны.

Күк капусын ачтык үзебез,
Ихлас яктысында — йөзебез.
Куәт бирә һаман омтылыш,
Син дә шундый булчы, и тормыш!

*Февраль, 1999*

## Егерменче гасыр азагы

*Рәссам Абрек Абзгилдинга — «Язгы моң» картинасы уңаеннан*

Яз аенда туган рәссамның
Язсыз булырмыни язганы,—
Кайсы яз бу, кайсы ел дисәң,
Егерменче гасыр азагы.

Безнең гомер соңрак фасылда —
Нихәл көзләр, саумы-тазамы?
Таңмы соң син, әллә шәфәкъмы,
Егерменче гасыр азагы?

Уй-карашлар төрле тарафта,
Иҗат кына түгел газабың;
Намусыңның сират күпере
Егерменче гасыр азагы.

Дәверләрне санар кәккүкләр,
Исән кичсә бәла-казаны.
Яңа алдашулар башлама,
Егерменче гасыр азагы.

Күп шауладык, тынып калыйк та,
Тыңлыйк әле иман азанын.
Киләчәккә карап күр безне,
Егерменче гасыр азагы!

*Февраль, 1999*

## *Дөньялар бөтен иде*

Ярты бәхет синдә иде,
Яртысы миндә иде.
Кушылып бөтен булырга
Мәхәббәт килгән иде.

Иреннәр ирендә иде,
Кочаклар ачык иде,
Куеннарда учак иде,
Илергән бер чак иде.

Әллә күзне дә йоммадык —
Ел — якты бер көн иде.
Тормышлар түгәрәк иде,
Дөньялар бөтен иде!

Без бергә, бәхетле идек
Ул яшьлек дигән илдә.
Ярты шатлык калды синдә,
Яртысы калды миндә.

*Март, 1999*

## Вәгаләйкем әссәлам!

Әй кардәшләр,
миллəттәшләр,
Әссәламә галәйкем!

*Госман Садә*

Таң ата да ил уяна,
Яңа көнгә күз салам.
Милләт сиңа җавап бирә:
— Вәгаләйкем әссәлам!

Иллене тутырдым дисең,
Безгә ул бик аз сыман.
Җитмештәгеләр котлыйлар:
— Вәгаләйкем әссәлам!

Шигърияттә егет чаклар
Үтә-китә, вәссәлам.
Өлгергән чорың каршылый:
— Вәгаләйкем әссәлам!

Илһамлы азаның илдә
Киләчәккә эз салган.
Яңа гасыр танып әйтер:
— Вәгаләйкем әссәлам!

*Май, 1999*

## *Июнь ае*

Безнең яклар таулы, үзәнле,
Карурманлы, бөдрә чатлары...
Июнь ае. Таныш кырларның
Җете яшел бәрхет чаклары.

Шушы аулак, шушы иркенлек
Уйларымны тарта офыкка.
Кисәтә күк: анда калганнар
Бу июньне күрми, онытма!

Күк капусы, шәһит җаннарга
Күрсәтче бер генә ачылып.
Туймады, дип, күреп күзләрем,
Үкенгәннәр алар ачынып.

Сезнең күзләр белән карыйм мин —
Мәңгелеккә күзен йомганнар.
Бу июньгә минем күз белән
Сез баксагыз иде, туганнар!

Безнең яклар — таулы, үзәнле,
Карурманлы, бөдрә чатлары...
Июнь ае. Күңлем нечкәреп,
Үксеп өзелгән бер чаклары.

*Июнь, 1999*

## Тыйма, Вилдан

Табигать бит биргән тигезләп:
Ике малай — ике игезәк.
Икесе дә үсеп җиттеләр,
Армиягә бергә киттеләр.

Без сабыйлар тордык кызыгып,
Биеделәр табан кыздырып,
Бер-берсеннән әллә уздырып,
Яңа ботинканы туздырып.

Биюдә дә алар тиң иде,
Бигрәк истә Вилдан биюе.
Бәбкә үлән үскән урамда
Очып-очып кунды ул анда!

Дәртләндерә мәйдан-түгәрәк,
Аяк очы белән тәгәрәп,
Ике канат — ике кул изәп
Бөтерелә ике игезәк!

Шаянлыкта алар тиң иде,
Күз алдында — Вилдан биюе.
Әллә үкенечкә булганга...
Зур сугышка керде туганнар.

Шунда сынды парлы тигезлек,
Шунда бүленде ул игезлек...
Горур яклап нәсел, ил данын
Яу кырында ауды Вилданы.

Булган икән соңгы биюе,
Кайтыр көнгә калсын дию...
Мендәр чигеп калды сөйгәне,
Туйга бирнә булыр дигәне.

Тол рәтендә калды кәләше,
Егетне бит әҗәл ярәште...
Тумый калды яңа игезәк,
Әй, биерләр иде ил бизәп!

Оныклар да иярер иде,
Вилдан бабай диярләр иде.
Сугыш атты ничә буынны,
Туар кызың, туар улыңны.

Сугыш кисте, кисте өметне,
Көнләште ул Вилдан-егетне.
Яраланып кайтты Гыйльманы,
Игелекләр булды кыйлганы.

Игезәклек булды яшәве —
Авыл сәхнәсеннән төшмәде.
Дәрте ташып торган җор кеше
Әллә Вилдан биргән өлеше.

Күргән саен хәзер Гыйльманны
Юксынам мин һаман Вилданны.
Биеп җитте Гыйльман сиксәнгә,
Табигать тә көнче икән лә —

Тыпыр-тыпыр биеп китәргә
Баласы юк — ни хәл итәргә;
Бәбкә үлән үсми урамда,
Берьялгызы йөри ул анда.

Горур яклап нәсел, ил данын
Яу кырында ауды Вилданы.
Тумый калды яңа игезәк,
Әй, биерләр иде ил бизәп!

*Июнь, 1999*

## Үлем элмәге

(Сабан туенда очрашу)

*Француз легионеры, якташым*
*Зыятдин Камаловка*

Ул — Багыш, мин — Бакырчыдан,
Зыятдин абый — күрше,
Бүген Апас бәйрәмендә
Миңа иң якын кеше.

Сабан туе түбәтәен
Килгәч үк киерттеләр.
Йөрдек, якташ, борыннарны
Югары чөеп кенә.

Чибәр-чибәр чия кызлар
Туры китереп кенә,
Каршыбызга төшеп кунды
Күктән сикереп кенә.

Очучылар да осталар,
Гел дә курку белмәде,
Батырлык билгесе иде —
Күктә «үлем элмәге».

Үлем элмәген бу җирдә
Минем иң якын күрше,
Үз язмышы тирәсендә
Ничә кат күргән кеше.

Канлы сугыш һәм әсирлек,
Француз партизаннары.
Түшендә алтын орденнар!
Һәм Колыма аннары...

Уттан калдың, боз итәрләр
Бу зәмһәрир тәмугта.
Тамырларда каның ката,
Тән — котыпта, җан — утта...

* * *

Бүген сабан туебызда
Агач атка атланып,
Егетләр капчык сугыша,
Берсе төшә капланып.

Ә дошман үтереп суга,
Тормаслык итеп суга.
Намусыңа илең сукса,
Түзүе читен шуңа.

Чыдый бит адәм баласы
Нинди хәлгә төшеп тә.
Колымага чыдап була —
Нахак бәла өшетә.

Зыятдин Камалов сөйли
Тәмам ачылып китеп,
Кайберсен пышылдап кына,
Үз итеп, якын итеп...

Зур мәйданга кыңгыраулы
Атлар керә тезелеп.
Яшьлегеңне сагындырып
Тальян үтә өздереп.

Агроном булып эшләгән,
Елгыр ат җиккән икән.
Тыныч тормыш тугарылгач,
Кайбычтан киткән икән.

Мин ул елда анда идем,
Йөгерәм яланаяк,
Ул — офицер, канлы сугыш
Тормаган бер дә аяп.

* * *

Сабантуй үзәге — көрәш,
Нәкъ тормыштагы сыман

Ир-егетнең рух ныклыгын,
Намус сафлыгын сынау.

Камалов канлы көрәшнең
Уртасында булган ул:
Франция орден биргән,
Үз иле — «егерме ел»...

Сорау алу, җәзалауның
Рәхим-шәфкать белмәве,
Кая барма, баш өстендә
Көтә үлем элмәге...

Ничек исән калгандыр ул
Колыма төрмәсендә.
Ә бүген Апас хакиме
Чакырды тирмәсенә.

Генерал һәм министрлар
Уртасында камалып,
Почетлы легионер да
Бүген кунак — Камалов.

Килер елда, сиксәнең, дип,
Киная белән азрак,
Быелдан ук дәшеп куя
Хәнифәтуллин Азат.

Сездәйләргә урын түрдән,
Саклаштың, дип, Ватанны,
Французлар да көтә икән
Бу түгәрәк датаны.

Колыма сырхавыннан да
Парижда дәвалыйлар,
Вакытында күрмәгәннәр
Бездәге «дәү абыйлар».

Каторгадан да бит аны
Французлар коткарган,
Милли батырлары итеп
Чакырганнар котларга.

Җиде еллап газаплагач,
Эшне бик тиздән тотып,
Озатканнар төрмәчеләр
Самолетка утыртып.

Кәгазь биргәннәр, имеш, ул
Ялланган эштә булган.
Күр нинди даирәләрдә
Ялганлау өстә булган!

И син, адәмнең язмышы,
Төшеп җиткәчтен гүргә,
Нинди гыйбрәтләр өчендер
Күтәргән данлы түргә?

Бик рия бер җәзачысы
Бигрәк азынган-азган,
Бу хәл башына сыймыйча,
Ул акылыннан язган.

Алар күпме генә җанны
Җәзалап өлгермәде.
Тарта торгач, үзләренә
Төште «үлем элмәге».

Кире кайтты шул елларда
Ерактан каторжаннар,
Рухы таза батыр җаннар,
Күңеле матур җаннар.

Дәртле-җегәрле Камалов!
Сокланып-сынап карыйм:
Туфаннарның сынмаслыгын,
Җор Мин Шабайны таныйм.

Сабыр Ибраһим Салахов,
Мәхмүт Бөдәйли-шаян...
Мондый уртак оптимизм
Аларга килгән каян?

Чыныктырган чын татарны
Гасырларның басымы.
Сыналып-сайланып килгән
Сыйфатларның асылы!

Ә майданда көрәш бара,
Батыр бүләген ала!
...Кайбер француз орденнары
Колымада «югала»...

«Бетте, кайтмас!» — дип алтынны
Эретеп койдырганнар.
Сөяркәсенә, үзенә
Затлы теш куйдырганнар.

Теш кысып түзгән дә җиңгән
Рухи бай безнең күрше.
Сугыш уты үзе койган,
Ул — Алтын һәйкәл кеше.

Фотохәбәрче, елмаеп,
«Месье» дип дәшкән иде,
Ветеран «маки»* бик теләп
Французча җавап бирде.

...Түбәтәйне кыңгыр салып
Әйләник сабан туен,
Якты көннәргә сөенеп
Күзәтик Зөя буен.

Рәхмәт яусын туган якка,
Сабантуйга чакырды.
Зыятдин абый Камалов
Көрәштә иң батыры!

*Июнь, 1999*

* Маки — француз партизаны.

## *Шом*

Шом калган җанда:
Козгын — хәтәр, дип,
Китерә һәрчак —
Яман хәбәр, дип.

Әткәй сугышта —
Хаты юк күптән.
Козгын, коңгылдап,
Очрама бүтән.

Ялгышты козгын,
Көткән хат килде.
Тик бу сөенеч
Соңгысы иде.

Козгын, син, бәлкем,
Гөнаһсыз коштыр,
Борынгы юрау
Яла, ялгыштыр.

Шулай да, козгын,
Син безне кызган,
Кычкырып үтмә
Өй турыбыздан.

Арттырып һаман
Яманатыңны,
Болгана илләр,
Замана тынмый.

Шом яши җанда,
Дөнья бозылды.
Көн саен күпме
Хәбәр — козгынлы.

*Июнь, 1999*

## *Илһам капусы*

Күк капусы ачылганда
Әгәр өлгерсәң,
Теләкләрең кабул була,
Күккә белдерсәң.

Күз ачып йомган арада
Нәрсә теләрмен?
«Сугыш бетсен! Әткәй кайтсын!
Тизрәк!» — диярмен.

Йолдызлы зәңгәр төннәрдә
Сагалап көттем,
Серлелеген, матурлыгын
Күрдем мин күкнең.

Кай арада балкып алды
Нурлы капусы,
Сокландым, сүз әйтәлмәдем,
Ихлас, хак бусы.

Булмады, сугыш бетмәде,
Әткәй кайтмады,
Ятим күңел ул елларның
Моңын ятлады.

Ә шулай да могҗиза бар,
Шулай дип саныйм,
Әле һаман да ышана
Күптәнге сабый:

Ачылды илһам капусы
Якты төннәрдә,
Өлгердем сезгә, үземә
Бәхет теләргә.

*Июнь, 1999*

## Олы Бакырчыда очраштык

*А.С.Пушкинның тууына*
*200 ел тулу уңаеннан*

Болдинода — синең мәшһүр көзең,
Миндә менә Бакырчы җәе.
Пушкин елы быел — шигърияткә
Килеп кенә тора бит җае.

Бик исемдә утыз җиденче ел...
Үлгәннәргә «почет» булганмы —
Бәйрәм итеп шаулаганнар иде
Вафатыңа йөз ел тулганны.

Урман арасында ерак авыл,
Без икенче генә сыйныфта.
Ул чак әле синең даһилыгың
Аңыбызга бетмәс сыеп та...

Күңел тарткан, үз иткәнбез икән,
Саф татарча иде язганың:
Тукай теле якынайткан сине...
Икегезне бергә кызгану...

...Шигырьләрең һаман телгә килә,
Татарча һәм русча ятладым.
Тукайны да, шигъриятне дә син
Яңа Дантеслардан сакладың.

Ике йөз ел тулды бу көннәрдә —
Бусы инде туу бәйрәмең.
Яратуыбызны яңарттың син —
Бөтен татар җирен әйләндең.

Күргән идем Олы Бакырчымда,
Үзгәрмәгән, шул ук сурәтең.
Уртак дога итеп кабатлыйбыз
Син зурлаган Коръән сүрәсен.

*Июнь, 1999*

## Ник тынгысыз һаман бу җаным?

Шаян, көләч булып күренәмдер,
Сер бирмичә шулай узамын.
Бәйрәмдә дә вәйран минем халәт —
Ник тынгысыз һаман бу җаным?

Төшенкелек упкынынннан йолып
Тыеп кына тора үз аңым.
Ирешкәнем шөкер итәрлектер,
Ник тынгысыз һаман бу җаным?

Кешеләргә гел ышаныч өстәп,
Дәртләндереп кулым сузамын.
Карап торсаң, мин оптимист инде,
Ник тынгысыз һаман бу җаным?

Ятим еллар, төшләремә кереп,
Эзәрлекләп канны бозамы,
Без белмәгән авырлыклар булмас,
Ник тынгысыз һаман бу җаным?

Тыштан балкып йөргән чакларда да
Эчтән янып, ахры, тузамын.
Уйсыз-гамьсез яшәгәнем юк бит —
Тынгы белми һаман бу җаным,
Ник тынгысыз икән бу җаным?

*Июнь, 1999*

## *Ниләр бар икән күңелдә?*

Ниләр бар икән күңелдә,
Күңелнең иң-иң-иң түрендә,
Түренең иң-иң-иң төбендә,
Уй җитмәс урында — тегендә?
Тоясың, белмисең үзең дә.

Ничек дим, төшеним серенә
Каләмем эзләнеп үреләә —
Илаһи балкышлар күренә...
Хис белән, төс белән, ис белән,
Укмашкан уй белән, көч белән.

Ниләр бар икән күңелдә,
Кайчакта хикмәте күгендә:
Үткәнне-килерне тойганы,
Гомергә бөртекләп җыйганы,
Бер нокта эченә сыйганы!

Ниләр бар икән соң күңелдә?
Гел генә белмәслек түгел лә,
Илһамым, чәчелмә, түгелмә,
Җан тыныч, рух уяу булсын да,
Намусың чирүдә торсын ла —
Мин җавап табармын барсына!

*Июнь, 1999*

## Ниндидер көч

Биек тауда тойганыгыз бардыр:
Иксез-чиксез киңлекләрне күреп,
Ниндидер көч сине күккә тарта—
Кинәттән очып китәрсең кебек!

Чак тыелып торам, тик бер адым —
Очам диеп, сикереп аласы...
Канатларың синең — күңелеңдә,
Оча беләсең, адәм баласы!

...Ак кәгазьгә карыйм, охшаш тойгы
Минем күңелемне гел сихерли:
«Иксез-чиксез монда мөмкинлекләр,
Икеләнеп торма, сикер!» — ди.

Түзә алмадым тарту көченә,
Дәште упкын — шунда мин атладым...
Нинди хозур мизгел кичердем бит —
Ачылды да китте канатларым!

Күңелемнең бәргәләнгән чагы
Хыял чоңгылына гел китерә —
Бу юлы да канат булыр микән? —
Белмим әле, әмма мин сикерәм!

*Июнь, 1999*

## Таң

Табигатьнең оеп торган мәле,
Әкрен генә офык яктыра.
Күз карашым белән тартып, дәшеп
Бүген Җиргә мин таң аттырам!

Күкләр уянуы — бер могҗиза,
Күргәнем юк икән күптәннән.
Гомеренең серле бу сәгатен
Йокы-мәрттә кеше үткәрә.

Җиргә Кояш туган мизгел ләса,
Аерып Җир-Күкләр арасын;
Тере ялкын, кайнар алтын чагы —
Туры төбәп карый аласың.

Җан чистарып, шушы садәлектән
Хозурланып кылам тамаша.
Таң калып гел таңнан күзем алмыйм,
Җиргә карыйм мин саф таң аша.

*Июнь, 1999*

## Горурлык

Каләмдәшләр безнең якка кайткан чакта
Хәйран калды тау-үзәнле манзарага:
— Кавказлардан ким түгел бит бу як,— диләр,
Сокланып вә хозурланып бара-бара.

Төрттерде нәкъ шул чагында бер юлдашым:
— Тау ягы да... тик әллә ни түгел биек.
Горурлыкка кагылгандыр, әйттем:
— Болар —
Ослан тавы өстендәге Таулар! — диеп.

*Июнь, 1999*

## Бер көн

Кайда бүген илһам-уйнак —
Хис битараф, булмый уйлап.
Онытылыр, бу көнем — буш,
Үз ишләре янына куш.
Кемнең гомер үтә оеп,
Менә шундый халәт тоеп?

Мәңгелеккә көнем тамды,
Санаулысы кимеп калды.
Югалтуың эзсез үтмәс —
Бик кирәктә шул көн җитмәс...

*Июнь, 1999*

## *Кайттым*

Суырып-суырып,
Кизләвебез суын үптем,
Елгабызны колач-колач
Кочагыма алып үттем!

Үрелеп-үрелеп,
Үрләремә үрелдем мин,
Тауларымның түрләрендә
Үкси-үкси терелдем мин.

Сыенып-сыенып,
Талларыма сарылганмын.
Ярсу идем — сабырландым,
Шулкадәрле сагынганмын...

*Июнь, 1999*

## *Бар...*

Сагышларым
Тулып агар
Тугайлар бар,
Шатлыкларым
Уртаклашыр
Туганнар бар.

Буш кырларда
Мөлдерәмә
Моңнарым бар,
Күз тутырып
Карыйм әле,
Соңлавым бар.

*Июнь, 1999*

## Талларым-танышларым

Офыкны күрим, дип мендем,
Тирбәлдем, егылмадым —
Зифа иде ыспай таллар,
Бөгелеп-сыгылмалы.

...Биек йортлардан карадым —
Авылым күренмәде.
Гомергә җитте хисләрнең
Күңелгә күмелгәне.

Сизми дә калганмын ласа
Гомернең авышканын,
Кайттым: «Исән тордыгызмы,
Талларым-танышларым?!»

Картайгансыз икән, дидем,
Сагышланып, офтанып.
Вакыт инеше — агымсу,
Тормый шул ул тукталып.

Талларым миңа әйтәдер,
Талларым мине таный:
«Син үзең дә безнең яшькә
Җитеп барасың, наный.»

Еллар йөген күтәргәндәй
Бөкрәеп тора алар.
Монда мине кемнәр аңлар? —
Кордаш талларым аңлар.

*Июнь, 1999*

## *Чишмәм минем*

Беренче шигырьгә кадәр
Беренче чишмәм туган,
Рәхмәтле булып учыма
Йөгерек суы кунган.

Сабый чакта тау астыннан
Саркыган тамчыларын
Үзем күреп, үзем табып,
Үзем казып чыгардым!

Җан кергәч, кабыгын төрткән
Ул иде бәбкә сыман,
Кысылып-сыгылып килгән
Тау-ташлар арасыннан.

«Пип-пип» дигән кебек ул да
Челтерәп тавыш бирде.
Кояшлы, нурлы сөенү
Безгә бик таныш инде!

Чишмәм диеп мактанмадым,
Ул минем серем иде,
Яшерен илһам-өметем,
Ачышның бере иде.

Карап туймый идем аның
Үтәли аклыгына,
Күпме катламда пакьләнгән
Яп-якты сафлыгына.

Чишмәм минем, чишмәкәем,
Еладың минем белән,
Мин кайгырганда суларың
Тозлы икәнен беләм.

Улак яңа, суларың да
Ага, яңарып тора;
Сине ачкан малай хәлен
Шушы бабайдан сора...

*Июнь, 1999*

## Аңлашу

Читен иде чит-ят җиргә барып,
Ят кешеләр белән аңлашу.
Язмыштыр шул — якын авылыңны
Ерак шәһәрләргә алмашу.

Эчәр сулар, жыяр тәгам шулай
Адәм балаларын йөртәдер.
Кала шавын басып, туган якны
Тын сагыну анда көтәдер.

Төшләремдә очып-очып кайткан
Урамнардан өндә атлыймын.
Авыл шул да, авылдашлар бүтән,
Бик күп танышларны тапмыйм мин.

Урамнарда мин белмәгән яшьләр,
Уңда-сулда яңа яшь өйләр,
Туган якны сагыну ни икәнне
Белми генә монда яшиләр.

Авыл өчен бик гадәти булып,
Буын арты буын яңара.
Кайтсак — кунак, китсәк — ерак булып
Без йөрибез ике арада...

Шәҗәрәбез — чишмә башым монда,
Нигез ташымны мин алмашмам.
Авыл-әнкәм, без бер туганнар дип,
Киләчәгең белән аңлашам.

*Июнь, 1999*

## *Мазлумә апа*

Күлмәгең ак, үзең гел шат,
Чибәр идең, чая идең,
Мине күргәч, кочып алып,
Үчти-үчти чөя идең,
«Үсә! Үсә!» — дия идең.

Сүзгә оста, шаян идең,
Шундый матур көлә идең,
Качкан булып кылансам да,
Йөгереп үк килә идем —
Яратканны белә идем.

«Чырык-чырык» килеп очтым,
Эчләрем «жу!» итә иде.
Бүтән очмам диеп очтым,
Үзеңнән дә өскә чөйдең —
Шундый-шундый биек очтым!

Ихлас иде көлүләрең,
Матур иде ак тешләрең.
Син күтәргән биеклектән,
Күрше апам, хак — төшмәдем.
Һәм кемгә дә тап төшмәде!

*Июнь, 1999*

## Авыл хатыны

Һава да саф,
Су да чиста,
Сөт тә тәмле!
Йокы кыска...

Мең мәшәкать
Синең өстә:
Бәрәңгесе
Бөгелдерә,
Чөгендере
Чүгелдерә,
Көянтәсе
Сыгылдыра.
Кичкә таба
Абындыра —
Апын-тәпен
Егыл гына...

Еллар тайгак,
Кесә такыр,
Чыда факыр —
Илең бахыр.

Ирең махмыр —
«Зәмзәм» сорый,
Балаң елый —
Мәммәм сорый.

Йортны кара,
Маллар үстер,
Бар шөгыльне
Кулдан күчер...

Тешең кысып
Еллар үтте,
Тешең бетте,
Эшең бетми.
Таңнан төнгә —
Шулай көн дә.
Аума-түнмә,
Ялны белмә...
Көзне белмә,
Язны белмә,
Кадер-хөрмәт,
Назны белмә...

Һава да саф,
Су да чиста,
Ник соң әле
Гомер кыска?

*Июнь, 1999*

## *Авыл*

Авыл... Күпме мохтаҗлыклар
Аны камаламаган —
Казанны алган Явыз да
Авылны алалмаган!

Күп булды, ипиен чәйнәп
Аңа тел тидергәннәр.
Кәперәйде дә очты бит —
Тынды тел-тегермәннәр.

Җир хисабына төзәлә
Илдә һәрбер ялгышкан.
Яши авыл, мәңгелек ул —
Тамыр тирән ябышкан.

Шәһәр эш тә ташлый ала
Ахыр чиккә җиткәчтен.
Тик авыл — Аллам сакласын —
Ачлык игълан итмәсен!

*Июнь, 1999*

## Ярап тора

Югалтулар өчен кеше
Бу җиргә яратылган,
Кешене юатыр өчен —
Кайгылар яңартыла.

Кешене сынар өчен ул
Тормыш каршылыклары,
Сайла, сиңа — яманлыкмы,
Әллә яхшылыклармы?

Бу дөньяда яшәп була,
Лаеш шулпасын эчсәң,
Юлларың да шома булыр
Сират күперен кичсәң.

Тормышың да ярап тора
Әгәр дә эшле булсаң,
Булмаганны булдырырлык
Булдыклы кеше булсаң.

Дөньяда тик дуслар гына —
Дошман ясый белмәсәң,
Үзең дә бер урынсызга
Әгәр ярсый белмәсәң.

Яратудан яратылган —
Кеше ул сайлап кына.
Дөньясы да ярап тора
Яшәсәң җайлап кына.

*Июнь, 1999*

## Ымсыну

Тау астында урман чишмәсе,
Ник һаман да искә төшәсең?
Челтер-челтер суы улакта,
Авылдан ул шактый еракта,
Урманчының йорты янында...
Җәйге матур һәм тын чак монда.

Тау астында урман чишмәсе,
Ник һаман да искә төшәсең?
Салкын суы басты сусынны,
Безнең күңел шунда ымсынды —
Көянтәсен аскан кыз бала,
Безгә күз дә салмый су ала...

Тау астында урман чишәсе,
Ник һаман да искә төшәсең?
Без киткәчтен генә килде ул,
Ак күлмәкле...чибәр иде шул.
Әллә инде кире барасы,
Кем икәнен белеп каласы?

Тау астында урман чишмәсе,
Ник һаман да искә төшәсең?
Юлдаш дус та карый кызыгып:
— Шушы урманчының кызыдыр...
...Ник бармадым, ник сүз кушмадым,
Кыймас үсмергә мин охшадым.

Тау астында урман чишмәсе,
Ник һаман да искә төшәсең?
Искә төшерде бит бер ханым,
Ул яшьлеге булган бит аның!
Сүз кушканны, бәлкем, көткәндер,
Ялгыз көннәр моңсу үткәндер...
Тау астында урман чишмәсе,
Әле һаман искә төшәсең.

*Июнь, 1999*

## *Онытылган төш*

Елмаеп уяндым — айлы төн,
Күңелгә мөлаем — җайлы төн.
Ак төннәр таныш шул күптәннән,
Яктысы төшә күк үткәннән.

Елмаеп уяндым — сөендем,
Ник әле рәхәткә тиендем?
Ай гына микән соң сәбәбе,
Тиктомал ник кәеф шәп әле?

Елмаеп уяндым — төшендем,
Хикмәте, ахрысы,— төшемдер...
Сүттем мин ак тойгы йомгагын,
Бик озак күземне йоммадым.

Елмаеп уяндым, татлы да,
Тулы ай сыман ул якты да,
Рәхәте җанымны иркәли —
Күргәнмен илаһи иркәне...

Елмаеп уяндым, сурәтен
Киләдә ачыклап беләсем,
Сагынган, үкенгән бер икән,
Кешегә, үземә сер икән.

Елмаеп уяндым — юрыйсы,
Юк аны кемнән дә сорыйсы:
Ахры, Ай, яшьлектән урыйсың —
Уяткан мәхәббәт тойгысы...

*Июнь, 1999*

## Арча кызына

Матур иде
Толымнарың,
Мин аларга
Орынмадым.

Сыйпадым тик
Күзем белән,
«Шигырь бу» дип,
Сүзем белән.

Әйткән беткән,
Очкан киткән,
Ә бит күңлең
Көткән икән!

Еллар үткәч,
Син очрадың,
«Яздыңмы?» дип
Ник сорадың —

Юк бит инде
Толымнарың,
Мин аларга
Орынмадым.

Хисләр шулай
Киселгәндер,
Киселгәнгә
Исеңдәдер?

Шигырьне ул
Язып булыр.
Соң шул инде...
Язык булыр.

*Июнь, 1999*

## Җилләр

Чәчләреңне җилләр тарый —
Мин түгел лә,
Керфегеңә кунып карый —
Мин түгел лә.

Изүеңне җилләр ача —
Мин түгел лә,
Куеныңа җилләр кача —
Мин түгел лә.

Җилләр кочаклап та кайта —
Мин түгел лә,
Итәгеңне җилләр тарта —
Мин түгел лә...

*Июнь, 1999*

## Сынау-сынатмау

Тормыш дигәнең әллә бик
Рөхсәтләр сорап тора.
Төрле хәлләргә куеп, ул
Гел сине сынап тора.

Үзең дә кеше сыныйсың,
Таләбең зурдан була.
Барыбызны да сыныйлар,
Үлчәве — вөҗдан була.

Узган чагың да буладыр
«Ярый», «ярамый» чиген.
Бүтәннәрне сынау җиңел,
Үзең сынатмау читен.

*Июнь, 1999*

## Серләрем бар

Серләрең бар ул синең дә,
Серләрем бар ул минем дә,
Кагылма ул хәзинәмә,
Синекенә мин тимим лә.

Сер сандыгым әгәр баксаң,
Йә күзләрең камашыр, дим,
Язын «тышта калган» сыман
Карашларың адашыр, дим.

Ымсынулар, үкенүләр
Салдым анда сайлап кына;
Сөюләрем якты гына,
Гөнаһларым — савап кына.

Серләрең бар ул синең дә,
Серләрем бар ул минем дә,
Үземнекен җырда ачам,
Синекенә гел тимим лә...

*Июнь, 1999*

## *Әгәр дә мәгәр*

Мин сине бик-бик
Сагынып идем.
Сагына торгач,
Сарылып идем.
Сарыла торгач,
Тагылып идем.
Тагыла торгач,
Табынып идем.
Табынган диеп
Танылып идем!

Билләһи әгәр,
Әгәр дә мәгәр —
Үкенеч булып
Калсаң гомергә...
Ә бит илле ел
Яшибез бергә —
Сагынасы юк,
Табынасы юк.

*Июнь, 1999*

## Пароход

Пароходның борынында,
Күренекле урынында
Алга карап егет бара,
Канатланган кебек бара.
Киләчәккә узып бара.
Омтылыш, дәрт тоеп бара.
Бөтен гомер алда, алда —
Хыялыңнан артка калма!

*

Койрыгында пароходның
Бабайның да эшләр хутлы —
Җилләр бәрми, монда ышык,
Ерагая киткән офык...
Су өсләре күбек кенә,
Үткән гомер кебек кенә.
Кала, кала, еллар кала,
Еллар берлән гомер кала...

*Июнь, 1999*

## «Шыбыр-шыбыр яңгыр ява...»

### I

Ызбалар салам түбәле,
Мохтаҗ заман. Шулай да:
«Шыбыр-шыбыр яңгыр ява
Мәчет башы калайга».

Айлы манарасы йөзә
Болытларга тиеп тә, —
Авыл үзе чүмәшкән дә,
Рухы аның биектә!

### II

Ахырзаман җитте мәллә,
Әзьюз-мәзьюз токымы
Тәһарәтсез кулы белән
Манарага тотынды.

Күктәге ай җиргә чумды,
Үкседе Афзал хәзрәт.
Кырга чыгып өзгәләнде
Җанына тынгы эзләп.

Мөгаллим иде, мөлаем,
Милләтнең изге җаны —
Совет подвалга төшерде,
Халык — зурлады аны.

«Әссәламәгаләйкем!» дип,
Пышылдап үтә идек,
Соңгы карашы, өмете
Буш калган күктә иде...

### III

Ахырзаман булмаган ла,
Дәнсез заман ахыры —
Күтәрелде манарабыз,
Көмеш ае балкыды.

Ни могҗиза, Афзал хәзрәт
Мөнбәрдә тора дисәм —
Әсгате икән — газизе,
Иман варисы икән!

Болытлар сарылып үтә
Биектә көмеш айга,
«Шыбыр-шыбыр яңгыр ява
Мәчет башы калайга...»

*Июнь, 1999*

## *Сагыну турында*

Үкенеч — үткәннәрем,
Өзелеп киткәннәрем,
Сарылып үпкәннәрем,
Зарыгып көткәннәрем...

Сөенү, яратулар,
Әрнүләр, югалтулар,
Юксыну, юатулар —
Күңелдә һаман шулар.

Мәгънә биреп тормышка,
Безнең җанга тумыштан
Сагынулар тулышкан,
Мәхәббәткә булышкан.

*Июль, 2000*

## *Тизлек – җитезлек*

*Рөстәм Нургали улы*
*Миңнехановка*

Татар ул — тизлек ярата!
Тарихка карасак та:
Чорларны артта калдырып
Очкан гел аргамакта.

Канында аның омтылыш,
Җанында аның тизлек.
Кояшка карап ашкына
Тынгысызлык, җитезлек.

Һәр заманда ул һаман да
Сабантуйдагы сабый.
Машина җегәрлеген дә
Ат көче белән саный.

Егет җанында дәрт булса,
Канында канат була.
Илдәшләрен ияртkәннәр
Иң гаярь ир-зат була.

Киләчәккә омтылабыз
Сынаулы еллар белән.
Ил кодрәтен саный дөнья
Тәвәккәл уллар белән!

*Ноябрь, 1999*

## *Ак кәгазем*

Ак кәгазьдән хикмәт көтә идем;
Киләчәккә баккан шикелле,
Гел ымсына идем, кышкы кырда
Үз юлымны тапкан шикелле.

Омтылуым — ул язмышым икән,
Канат булган миңа хыялым.
Ничек кенә дөнья каралмасын,
Ак кәгазьдә сафлык тоямын.

Илаһидыр илһам, пакь таңнарда
Дәрте йокыларны качыра.
Ак кәгазем, иң әүвәле синдә
Күңелемнең теле ачыла.

Син белмәгән уй-серләр дә кала,
Ачыл, дисең дә бит, сагайма...
Уртак еллар саргайтканы җитәр,
Безнең сагышлардан саргайма!

*Гыйнвар, 2000*

## Егетлек

*Венера сеңелебезгә*

«Безнең нәсел, күзе яшел,
Ярамый дип тормыйбыз!»
Мәҗлесләрдә гайрәтләнсәк
Шушы безнең җырыбыз.

Форсат барда тыйнак кына
Һаман җаен табабыз:
Сынатмаган, гаярь булган
Безнең җиде бабабыз.

Тиңнәрен сайлый белгәннәр,
Мәхәббәт тә исәпле:
Ипли-сипли килгәннәр бит
Шулай нәсел-нәсәпне.

Ил күзендә күреклеләр,
Һәр эштә булдырганнар.
Ә бит, ә бит үзләрен дә
Аналар тудырганнар!

Иңгә-иң торган хәләлләр
Дошман-афәт килгәндә —
Горур җанлы сылукайлар
Көбә күлмәк кигәннәр.

Сугыш — мәңгелек аждаһа
Корбанын ала торган.
Толларның пар толымнары
Ялгыз чалара торган...

И бу дөнья, сагышларын
Ул соң аз китергәнме —
Ир-атлар күтәрә алмас
Аналар кичергәнне.

Изге затлар туган телне
Иман итеп саклаган —
«Әлпи, ти, си...» —
дип сабыйлар
Дога итеп ятлаган.

Саналса да шәҗәрәләр
Ир кавем исеменнән,
Җирнең таяну ноктасы
Әниләр җисемендә.

Безнең бабайлар бертуган;
Кушылып та яңарып,
Яшибез әле, үсәбез
Өзелеп тә ялганып.

Хәвефле, хәтәр чорда без,
Нәселең өметлеме?
Коткарса, коткарыр илне
Аналар егетлеге!

*Гыйнвар, 2000.*

## Балкып яшә, Апасым!

*Районыбызга — 70 ел.*
*Хакимият башлыгы Азат*
*Хәнифәтуллинга багышлыйм*

Уңыш җыйганда тугансың,
Уңыш — синең юл башың,
Халкым тырышлыгы белән
Уңыш һаман юлдашың.

Яшең җитмешкә җитсә дә,
Син Апас бабай түгел,
Пенсионер да димәс идем,
Юк әле, алай түгел!

Дәртең ташып торган чагың:
Иртә таңнан кузгалып,
Егетләрчә кайнарланып,
Эшлисең җиң сызганып.

Туган ояң Тау ягында,
Гасырларда тарихың,
Кояш белән бергә торып
Киләчәккә карыйсың.

Төрле җилләр исәр әле —
Җылысы да салкыны,
Өметеңне суытмыйча
Үт син еллар аркылы.

Кыю атла, ышанып ач
Яңа дәвер капкасын,
Таулардан да биек булып,
Балкып яшә, Апасым!

*Май, 2000*

## Мәчет манарасында

Айлы манарабыздан
Авылыма карадым,
Урам-урам тезелгән
Матур йортлар һарады.

Истә, сабый чагымда
Кызыгып менгәннәрем,
Салам түбә ызбалар —
Электә күргәннәрем.

Кошлар биеклегеннән,
Догалы манарадан,
Бабамнар үткәнгә дә,
Көткәнгә дә караган.

Күктән өмет иткәнбез,
Җирдә сабыр иткәнбез,
Ничек булыр моннан соң,
Шушы көнгә җиткәнбез.

Биектә рух канатлы,
Шулай да сизде күңел —
Лаф орырга иртәрәк,
Заманы изге түгел.

Югары алып менде
Мине монда һәр адым,
Мәчет манарасыннан
Вөҗданыма карадым.

*Июль, 2000*

## Юбилей догалары

*Роберт Миңнуллинның әнисе Гөлҗәүһәр ханымга*

Гомергә йөгереп эшләп,
Ирештең бәхетеңә,
Утырып бер ял итеп ал
Юбилей тәхетендә.

Син илләрдә күренекле,
Горурлана аласың —
Ана Данына биш тапкыр
Лаек булыр Ана Син!

Һәр балаң — Синең даның ул,
Ил таныды аларны,
Үзеңә дә кабул булды
Әнкәңнең догалары.

Балаларда Синең сәләт,
Тырышлык һәм сабырлык,
Ихласлык һәм дә зирәклек,
Иң затлысы — шагыйрьлек.

Күкрәгеңдә балкый алар
Дүрт улың һәм бер кызың.
Алар яратуы хәтле
Гомерең булсын озын.

Котлыйм Сезне, кадерлебез,
Борынгыча — «Син», диям,
Үз әнкәмдәй газиз күреп,
Хөрмәт белән баш иям!

*Июль, 2000*

## Гасыр яшьтәше

Ярылмас түмәрләр ята...
Яшьләр чамалаганнар,
Бигрәк ботаклы-чатаклы —
Булдыра алмаганнар.

Әзрәк бөкерәя төшеп,
Бабай килгән дә, карый:
— Мине көткән. Тәнне бераз
Язып алырга ярый!

Тураеп китте бабаең,
Җиңел йөртә балтаны,
Туксан яшен баш аркылы
Әллә чөеп атамы?

Каешланган түбәтәен
Бер сала да бер кия:
— Мондый түмәрләр булганда
Үлмибез әле! — дия.

Егет сүзе бер булыр ди,
Тәки сүзендә торды:
Яшьтәше, эштәше булып
Тәмамлый ул гасырны!

*Июль, 2000*

## *Сагыну сабаклары*

Туган авыл — күңелдә,
Онытырлык түгел лә,
Еракларга чакырган
Йолдызлары күгемдә.

Үзеңдә туган җырым
Үзеңнән алып китте,
Чит җирләрне үз итте —
Юксына торган итте.

Сагынулар тулышып,
Кайтам да, тагын китәм,
Китмичә яшәгәннәр
Бу хисне белә микән?

Ярату иркендә мин,
Берни дә эшли алмыйм:
Китеп сагыну кирәк —
Сагынмый яши алмыйм...

*Июль, 2000*

## Тере суның күзендә

Кайтып килә-килешкә,
Борылам мин инешкә.
«Исән тордыңмы, җаный!» —
Суларым мине таный,
Ярларым мине таный,
Талларым мине таный.
Җанга якын урыннар,
Тирәнәйгән ерымнар,
Өянкеләр картайган,
Билен бөгеп янтайган.

Инешем тыйнак кына,
Чишмәләр җыйнап кына,
Үз юлы белән ага.
Язларын ташып ала,
Ашкынып, шашып ала,
Бер дулап, ярсып ала,
Яз киткәч тынып кала.

Таныш тавыш чылтырый,
Күзгә төшеп елтырый,
Тере суның күзендә
Мин бит әле үзем дә...

*Июль, 2000*

## *Сулар ага, уйлар ага*

Җил — җилбәзәк,
Су — моңсу,
Күзем алмыйм сулардан.
Сулар ага, уйлар ага,
Үзе салган юллардан.

Тынгысыз җаннарны көйли,
Сулар уйдаш микәнни,
Күзләренә карап аңлый
Туган илдән киткәнне.

Тыныч елгам, сабыр суым,
Еракка барасың ла,
Югалыр көмеш тәңкәләр
Дулкыннар арасында.

Иксез-чиксез киңлекләрдә
Диңгез канат кагыныр.
Уйчанланып бер тынар да,
Кемнәрнедер сагыныр.

Җил — җилбәзәк,
Су — моңсу,
Күзем алмыйм сулардан.
Күңелем чайкалып бара
Уйлар салган юллардан...

*Июль, 2000*

## Балчык хәтере

Балчык — бик файдалы диләр,
Балчык — хәтерле диләр,
Тирән казыйлар галимнәр,
Ниләр генә димиләр.

Кызыл балчыкның роле зур
Минем тормышларда да,
Табигать аны күп иткән
Безнең тарафларда да.

«Нужа балчык ашата» ди,
Без дә балчык «ашадык»:
Иң әүвәле — әвәләдек,
Кызыл кирпеч ясадык.

Аннары «уфалла» белән
Ялчеккә илтә идек,
Алучылар булмаганда
Кире дә китә идек;

Барганда өмет тизләтә,
Кайтасың акрын-акрын,
Өмет ягы унбиш чакрым,
Юл уңмау — утыз чакрым.

Мондый чаклар булмаганмы,
Булган инде, түзәсең,
Ач карынга җиңел була —
Биеп балчык изәсең.

Безнең ялан аякларга
Сеңгәндер шул файдасы.
Ачлыктан коткарып калды —
Зуррак файда кайда соң?

«Балчык хәтере» дигәне
Чын микән, ялган микән,
Кирпечләрдә янган микән,
Тауларда калган микән...

*Июль, 2000*

## *Ак болын*

Гомеремдә бу беренче
Ромашкалар туе иде,
Яшел болын күренми дә,
Аклык шундый куе иде!

Сөенечле аклык иде,
Аклык иде бертоташтан,
Биеп торган сафлык иде —
Офыклардан ташып аккан.

Ак болында ак күбәләк,
Мәхәббәтем, син идең ул,
Саф яшьлегем кабатланган —
Канатланган мин идем ул.

Иреннәргә ирен килеп:
«Ак чәчәкләр көне» дидек,
Искә алыйк һәр ел саен,
Икебезнең сере дидек.

Бер көн түгел, ул бер гомер —
Гомергә дә сыймас булды,
Үткәнемә, килеремә,
Шул гөнаһсыз аклык тулды.

Бер иде дә безнең күңел,
Төрле икән күрәчәкләр,
Күзләремә яшь китерә
Һәр ел саен ак чәчәкләр.

*Июль, 2000*

## Ул аланнар

Кыңгырау чәчәкләренә
Җирҗиләк төргән идек,
Иреннәрнең тәмен кушып
Шукланып көлгән идек.

Ялгыз нарат тирәсендә
Икәүләп йөргән идек,
Еллар үткәч табарбыз дип,
Вак көмеш күмгән идек.

Күңелем белән җәйләрдә
Шул аланнарга китәм,
Яшьлегемнең алтыннары
Кемнәргә калган икән?..

*Июль, 2000*

## Йөрәк эше

Мәхәббәт турында язу
Яшьләр эше бит, диләр,
Әмма йөрәк хезмәтеннән
Пенсиягә китмиләр.

Карт йөрәкле яшьләр була,
Яшь йөрәкле карт була.
Илаһи илһам сүнмәсен —
Тик шул гына шарт була.

Кемгә күңел канатлары,
Кемгәдер азгынлыгы,
Мәхәббәт белән санала
Гомернең озынлыгы.

*Июль, 2000*

## *Улыңа куштың минем исемне*

Яшьлектә без хат алышкан идек,
Туганнарча, хәбәр — сүз итеп.
Сурәтеңне алып карый идем,
Якын күреп кенә үз итеп.

Мин кызыма куштым исемеңне,
Улың йөртә минем исемне.
Сәлам булып калды тойгыларың,
Туганнарча тыйдым хисемне.

Үз итеп, бер күрим генә диеп,
Барып чыктым сезнең авылга,
Якын итеп, кардәш итеп кенә
Үткәннәрне искә алырга.

«Мин ул белгән матур түгел инде,
Күренмәмен аңа...» — дигәнсең.
Тойгыларың чыннан булды микән?
Моңлы башың түбән игәнсең.

Аһ, бу язмыш, диеп сыкрандым мин,
Бу хәбәргә, сездән киткәндә —
Минем исемдәге чик сакчысы
Улың һәлак булган икән лә...

*Июль, 2000*

## Яңа мәктәп нигезенә

*Олы Бакырчы мәктәбенә
150 ел*

Бәпкә үлән үскән матур җирдә
Әсгат хәзрәт Коръән укыды.
Белем йорты, синең нигезеңә
Какшамаслык иман утырды.

Теләк, фатихалар дога булды,
Изге җомга көнне, саф таңда.
Милләт рухын, туган тел кодрәтен
Насыйп булсын иде сакларга.

Шәҗәрәңнең башы — мәдрәсәдә,
Йөз илле ел, мәктәп, тарихың —
Яңа гасырларның кояшына
Бик күп, бик күп булыр карыйсың.

Киләчәкнең дәртле балаларын
Авылымнан ел да дәшәрсең.
Бәхетле бул, мәктәп, мин ышанам,
Кыйблабызга карап яшәрсең!

*Июль, 2000*

## «Гали» диеп аны йөрттеләр...

Алмачуар иде атыбыз,
Муенынннан камыт төшмәде,
Ипле иде, озын торыклы,
Мине күрсә танып кешнәде.

Әткәй белән керде колхозга,
«Гали» диеп аны йөрттеләр,
Тарткан атка күбрәк салалар,
Авыр йөккә һаман җиктеләр.

Бүтән бригадага күчереп,
Суыттылар безнең араны.
Сызгырсам да әллә үпкәләп,
Борылып та инде карамый.

Авыр иде сугыш еллары,
Атлар белән бергә ачыктык,
Җирдән чүпләп һәрбер башакны,
Фронт өчен илттек ашлыкны.

Тылны тартты алмачуарлар,
Атлар күрде ирләр күргәнне.
Әйтте миңа күрше малае
Юлда безнең «Гали» үлгәнне.

Яман фалдай... әткәй сугышта,
Соңгы корбан микән атыбыз?
«Адресат юк» дигән сүз белән
Кире кайтты язган хатыбыз...

*Июль, 2000*

## Тоташ агым

Шәһәр урамнары тулы,
Шыгыр-шыгыр-шыгырым,
Машиналар ташкынында
Юк җәяүгә буш урын.

Каладан ташып чыгалар,
Агып-агып-агылып,
Саранча кавеме сыман
Бер-бер артлы тагылып.

Иномаркалар һавалы,
Тизлекләре дуамал,
Мондый байлык каян килә,
Ничек мулдан туа мал?

Кырда ялгыз бер трактор —
Аның хәлен кем аңлар,
Юаш кына йөреп ята —
Акчасызны кем санлар.

Меңәрләгән машинаның
Хәрәкәтләре җилле —
Шушы мескен трактор бит
Ашата инде илне!

Авылкай, сиңа ярдәм юк,
Сәмән йөнтәс кулларда,
Синең басулар аркылы
Акча йөри шуларда.

Җирдән ераклар ят сиңа,
Аларга тоташмадың.
Аксөяктәй өстен мин ди,
Тәкәббер тоташ агым.

*Июль, 2000*

## *Фәрманның дәрманы*

Әй алланың фәрманы,
Тавык түккән ярманы,
Боткага дип тора идем,
Өйрәгә дә калмады.

*Халык җыры*

### I

Көчле егет, дәртле егет:
— Исемем Таһир,— диде.
Таныштырып дусты әйтте:
—Һәр эшкә маһир! — диде.

Тәвәккәл икән, колачлы,
Галәмәт ирешкәне,
Күрдем мондый тырышларга
Замана килешкәнне.

Кыенлыклар аңа уен,
Вакытны ашыктыра —
Алдан күргән һәр гамәле
Тормышка ашып тора.

Төрле тармакта эшләде,
Аннары җиргә төште.
Фермер булды, җанга якын
Ата-бабалар эше.

Уңышлары ничек диеп,
Дустыннан сорый килдем.
Ул дәртләнеп сөйләмәде:
— Үзең белгәнчә...— диде,—
Тырыша-тырмаша инде,
Техника да бар инде,
Әмма дәүләт булышмаса,
Барыр юлы тар,— диде.

Бу илләрдә күпне күрдек,
Күрдек төрле фәрманны.
Эшкә җигеп булса икән,
Булса икән дәрманы.

### II

Таныйсыңмы дип бер агай
Килеп кочаклап алды,
— Арыдым,— дип кенә әйтте,
Иңемә башын салды.

Мин аңлыйм, аңлыйм игенче
Чарасызлыктан арган,
Жиргә — якын, илгә — ерак,
Үги хәлендә калган.

Тугарылган аты тора,
Малае арбасында,
Буш дилбегәне тарта да,
— Әйдә! — ди атасына.

Чак танып алдым Таһирны,
Инде бүтән зат сыман.
Әллә безнең ышаныч та
Туктап калган ат сыман?

*Июль, 2000*

## *Бу яз...*

Бу язны да күрдек әле —
Мөлдерәмә кояшы.
Кемнәр бар да, кемнәр юк дип,
Офтанып та куясың...

Әйтерсең лә синнән соң да
Ак чәчәкләр сибелмәс,
Сөенечләр арасында
Юклыгың да сизелмәс?

*Июль, 2000*

## *Татар акылы*

Үткәннәрдә ни булган,
Низаг белән ил тулган,
Каршы — олан-оланга,
Үчле туган-туганга.
Надан булганнар бик тә,
Татулыкка ни җитә!
Гауга — сугышка илтә,
Күпме каннар коелган,
Күпме җаннар кыелган...

Болар булган күптәннән,
Тик күп еллар үткәннәр,
Без бит инде бүтәннәр!
Ике туган серләшә,
Уй-фикерләр берләшә —
Каферләрне теткәннәр,
Ханнарны да сүккәннәр,
Бар тармакны сүткәннәр...

Бүгенгегә җиткәннәр —
Бәхәсләшеп киткәннәр,
Һәркем МИН дә МИН дигән,
Якага-яка килгән...
Тату иделәр алар
Үткәннәрне теткәндә,
Гыйбрәт алу читен шул
Үзең дөнья көткәндә.

«Татар акылы төштән соң»,
Әле һаман эштән соң...

*Июль, 2000*

# Ник?

Иртән тордың моңланып,
Кичен яттың шомланып —
Замана тавышыннан
Сагаеп та тыңланып.

Ишегеңдә ничә бик,
Күңелеңдә нигә шик,
Нигә имин түгел җан —
Син туган җиреңдә бит?

Әйләнеш тә тулганыш,
Әрле-бирле болганыш,
Дүңгәләктәй тамырсыз,
Ник тотрыксыз булган эш?

Безнең гасыр тырышкан,
Вәхшәт белән тулышкан,
Ни китерер яңасы
Ни көтәргә тормыштан?

Яшенләп яшьнәр кебек,
Шаулап боз төшәр кебек,
Хәвефләнәсең, алда
Бер дәвер яшәр кебек...

*Июль, 2000*

## *Яшәү...*

Омтыласың,
Талпынасың,
Талкынасың...
Калкынасың!

Шулай дөнья
Куасың,
Куар өчен
Тугансың.
Ә ул сиңа
Тоттырмый,
Үртәп чаба,
Тик тормый.
Кайчак телен
Күрсәтә,
Кайчак тешен
Күрсәтә,
Төрле төшен
Күрсәтә.

Дөньяга үч
Саклама,
Бу яшәү дип
Атала!

*Июль, 2000*

## *Күк белән күңел арасы*

Пегас — шигъри канатлы ат —
Иңеп Кояш тарафыннан,
Җир белән Күк арасыннан
Очып кына бара сыман.

Яланаяк чабып килеп,
Ябышкан идем ялына:
Мин әйттем — җирдән аерма,
Ул әйтте — юкка ялынма!

Башын чөеп, җир кешесе
Күк йөзенә бер карасын,
Гомер-бакый барлый торсын,
Күңел белән Күк арасын!

...Оча-оча дәвер кичә
Безнең күңел канатлары.
Кояшлы нур сыйпап тора
Җир бәрелеп канатканны.

*Август, 2000*

## *Кемгә бәйрәм...*

Яшел чирәмнәрдә сары бәпкә —
Балачагым шулай хәтердә.
«Пи-пи» килеп, туктап сөйләшәләр,
Мине таныгандай хәзер дә.

Канат ярдык бугай без бергәләп,
Илһам иде минем канатым.
Җылы сукмаклардан аерды да
Киек каз юлларына каратты.

Күзләрендә таныш акканатлар
Күтәрелеп дәртен сынады,
Туган тугайларын калдырырга,
Алар, ахры, яхшысынмады.

...«Каз өмәсе»н җырлап үткәрделәр,
Канатларның соңгы кагышы.
Сискәндерде тере матурлыкның
Үз пычагы сызган язмышы.

Көчсезләрне корбан итүләр ул
Бик борынгы йола-йоласын,
Корал дәверендә бу гадәттән
Шигъриятне киле йоласым.

Күңел йөкләмәде, бәйрәм итеп,
Һич тамаша кыла алмадым...
Яшел чирәмнәрдә сары бәпкә —
Мин нарасый булып калганмын..

*Август, 2000*

## Шөкер

Була көннәрең:
Күңел болытлы,
Әллә бар дөнья
Сине онытты.
Күзгә күренми
Берни, беркем дә...
Әй! —
Сөеним әле
Кояшлы көнгә!

Зәңгәр күкләрне
Ак болыт чиккән,
Табигать җете
Ямь-яшел икән.
Күңел тутырып,
Кинәнеп карыйм.
Әй! —
Яшь чагымдагы
Мохитне таныйм!

Кай ара җылы
Моң җиле искән,
Көйсез күңелне
Иркәләп үткән.
Иелер ул баш,
Уйланмый исәң...
Әй! —
Шатлан, яшим дип,
Шөкер, без исән!

*Август, 2000*

## Хатлар яна...

Яшьлек — разведка, пар эзләп
Күп сукмаклар үтелгән.
Туй алдыннан хатлар яна —
Үткәннәргә күперләр...

Син генә белгән серләрне
Укый ялкын телләре.
Соңгы тапкыр яктыртадыр
Бергә йөргән төннәрне.

Хатлар яна, уттан кала
Алтын балдак иясе,
«Йөзек салышта» ул откан —
Туй көлмәген киясе.

Яшьлек — разведка, егетем,
«Тел» алып кайттың шулай.
Һәм үзең дә әсир булдың,
Икегезгә дә уңай.

Беләм, минем хатларны да
Үпкәләп яндырганнар,
Сүндерәм дигән хисләрне
Кабызып калдырганнар...

*Август, 2000*

## *Көзге яңгыр*

Көзге яңгыр нигә моңсу,
Аерылу микәнни?
Сабырланып калган күңел
Үткәннәргә киткәнме?

Бер карасаң — күптән түгел,
Бер карасаң — күптәнге,
Озын юлда, озак еллар
Үзәкләргә үткәне.

Биштәр асып, гомеремне
Җәяүләп үттем бугай,
Үтә-сүтә уй-хисләрдә
Кайтып йөрим гел шулай.

Яшьлегеңдә кызыктырып
Киләчәк кабындыра,
Инде хәзер ирешкәчтен
Үткән юл сагындыра.

Салават күперен кичеп,
Күрдем килеп җиткәндә,
Үткәннәрдә кала икән,
Киләчәктән көткәннәр...

*Сентябрь, 2000*

## *Мәхәббәт һәйкәле*

*Апаста Фәһим Фәсхетдинов*
*иҗат иткән Сын*

Хатын-кызга тормыш итүләре
Беркайчан да җиңел булмады.
Сызганулы һаман сезнең җиңнәр,
Сызланулы гомер юллары.

Кырыс сүзләр күбрәк эләккәндер,
Назлыларын заман әйтмәде.
Ир-атларның олуг рәхмәте бу —
Мәхәббәткә куйган һәйкәле.

Сез барында гына ямьле дөнья,
Гөлчәчәкләр, иртә сулмагыз,
Бәхетегез тулы була күрсен,
Сөенешеп җиңел сулагыз.

Бер һәйкәлгә үсте Тау ягыбыз,
Мәһабәт Сын мәйдан түрендә —
Эшчән сылукайлар даны бүген
Шул биектән илгә күренә.

Елмаюдан йөзләр балкысыннар,
Мәхәббәттән дөнья яшәрсен,
Суынмасын җирдә һәйкәлләр дә —
Җан җылысын тоеп яшәсен.
Мәхәббәттән дөнья яшәрсен!

*Сентябрь, 2000*

## *Нинди*

Бу нинди халык,
Бу нинди холык,
Яши дөньяга
Яманлык кылып,
Үтереп-кырып...

Бу нинди дөнья,
Буялган канга,
Гасыр мөһере —
Каһәрле тамга?!

*Сентябрь, 2000*

## *Сизем*

Җаның тынычсыз,
Күңелең «уйный»,
Үзеңнән узып
Ул нәрсә уйлый?

Нинди дулкынны
Сизенә, тоя,
Гафил булма дип,
Искәртеп куя?

Күңел-мохиттә
Үзгәрә һава,
Яңгыр көткәндә
Салкын боз ява.

*Октябрь, 2000*

## Каратунның ак бәхете

Паровозлар моң кычкырта,
Әллә дуслар, китикме?
Киткән кошлар кире кайта,
Әллә сабыр итикме...

*Халык җыры*

Базарлы авыл идең син,
Илгә мәгълүм, Каратун —
Атна саен якташларны
Җыйдың да син тараттың.
Без күргәндә чуен юлың
Әле өр-яңа иде,
Нужалардан коткарасы
Өметкә бара иде.
Без дә киттек, паровозлар
Аерылды моңланып,
Бәхет эзләп киттек ерак,
Уйланып та шомланып.
Шөкер, алып барган поезд
Алып та кайта икән,
Сагынганнар, юксынганнар
Баксана, байтак икән.
Терәк булыр улларыңны
Туган якка караттың,
Куәт алган чагың синең,
Эшләр хутта, Каратун.
Матур ап-ак йортлар белән
Бизәлә һәр тарафың,
Әллә инде мыштым гына
Шәһәр булып барасың?!
Тырышлыгың күз алдында,
Син маһир, син сәләтле,
Ярап тора шул сәбәпле
Базар мөнәсәбәте.
Булды чорлар, мәҗбүридән
Бәхет эзләп киткәнбез —
Каратунның ак бәхете
Без үзебез икәнбез!

*Октябрь, 2000*

## Син калдырган еллар

*Гариф Ахуновның*
*75 еллыгына*

Идел өсләрендә көзге томан,
Безнең офтанулар түгелме?
Кояшы да сирәк күренә шул,
Елмаюлар, Гариф, сүрелде.

Яңа гасыр, яңа өметләр дип,
Киләчәкне яшьләр көтәләр.
Яңа дуслар безнең булмас инде,
Иске дуслар, Гариф, китәләр...

Безнең гасыр — безнең язмыш иде,
Нәкъ без кирәк идек аңарга —
Сүрән күңелләрне җылытыйк, дип,
Бергә-бергә, Гариф, янарга.

Егерменче гасыр даһиларын
Тудырды да, китте алып та.
Без аларга фикердәшләр идек,
Безнең чордаш иде Алыплар.

Йөрәкләрдә китте яралары,
Рәнҗеткәннәр соңлап үкенә —
Ишеталсаң әле яшәр идең,
Кемдер, Гариф, гафу үтенә.

Гамәлдә гел сине юксынабыз,
Бәйрәм түрендә дә син кирәк,
Моңсу чакларны да күңеллегә
Куяр идең, Гариф, син көйләп.

Идел өсләрендә язгы томан
Күтәрелер, уйнар дулкыннар,
Якты булсын син калдырган еллар,
Синдәй, Гариф, көләч булсыннар!

*Октябрь, 2000*

## *Күз офыкта...*

Сугыш булгән бала чагым,
Моңайган сыңар канат.
Юандым мин Каенсардан
Гел киләчәккә карап.

Бәхетем сыман ымсынып
Кояшны күтеп алам,
Салкын чыклар — асылташлар
Аякны өтеп ала.

Күз офыкта, анда хыял!
Җылыныйм дип йөгердем,
Сагышлар өчен әҗердер,
Илһам алып өлгердем,

Еллар төрле, кайсы аның
Кояш сыман тотыла.
Мондый хәлдән бала чакка
Кире кайтып котылам.

Пакь, инсафлы, имин дөньям,
Ихласлык та сау анда.
Киләчәкне чистартасы
Саф чишмәле тау анда.

...Инде алдымда яктырган
Таң тугелдер, шәфәкътыр,
Ашыкма хыял кояшым,
Бул соңгы кат шәфкатьле.

*Декабрь, 2000*

# 2001 ел

## *Ак юллар*

*Очучы энемә*

Зәңгәр күктә ак буразна сызып
Тавыш-тынсыз очкыч атыла.
Син нарасый яланаяк үткән
Чирәмлек тә иде ак кына.

Кырау салкынын да сизмиенчә
Гел офыкка карап ашкындың.
«Үсте, үсте!» — диеп, күккә чөеп,
Киләчәккә сине тапшырдым.

«Ак юл, энем!» — дидем, күтәрелдең,
Якты биеклектән төшмәдең,
Очар канатларың — тәвәккәллек,
Гел биектә булды эшләрең.

Иртән чыгамын да зәңгәр күккә,
Көмеш уклы юлга төбәләм,
Ничә буын ашкынуы безне
Күккә чөйгән шулай түбәннән.

Очкычлар да җиргә кунаклыйлар,
Җылы Җирдә очар оясы,
Этеш-төртеш монда, кысынкылык,
Шундый җәяүлеләр дөньясы.

Очучы да дөлделеннән төшәр,
Яшьлек күкләренә карап ал,
Җирдә дә бит төрле биеклек бар,
Күктә калмасыннар канатлар!

*Гыйнвар, 2001*

## *Каныңда ул, җаныңда*

Тән хәтерли — гомер буе туплап,
Җыеп бара каккан-сукканны,
Яшьлек-дуамаллык картлыгында
Сызландыра әллә юккамы?

Тән хәтерли. Күңел онытамы?
Кагыл гына нечкә кылына —
Тибрәндереп көйләп куя сине
Ничә гасырларның моңына.

Каныңда ул, җанда газиз аһәң,
Ник кадерле дисәң шулкадәр —
Ерак бабайлардан килә сиңа
Ядкарь-васыятьле моң-хәбәр.

Галәм хәтереннән милли моңнар
Мәңге шулай кайтып торсыннар,
Күңелләргә сүзсез аңлашыла
Зиһен төшенмәслек тылсымнар.

*Гыйнвар, 2001*

* * *

Сибелә чәчем, сибелә кылганнар,
Сер пышылдый сыман курганнар.
Җил-җайдаклар моннан узганнар,
Кылыч айкап язмыш урганнар.

Бу ни хикмәт икән, далалар да
Ерак барган саен мәгънәле —
Сүзсез генә җаны-тәне тойган
Бер өлеше микән әллә мин?

*Июль, 2001*

## Мәктәп белән хушлашканда

Саф таң сыман Таңсылу,
Бүген бераз моңсумы?
Сагыныр көннәрең шул,
Онытмас кемнәрең шул...
Бәхетнең татлы чагы,
Балкыган якты чагы.
Мәхәббәт дигән тылсым
Гомерлек канат булсын.
Йа Ходам, күз тимәсен,
Саксыз җил-сүз тимәсен.
Бездән ерак елларны
Күреп торам мин аны:
Киләчәк матур да соң! —
Анда бит син буласың,
Саф таң сыман Таңсылу!

*Май, 2001*

## Ак тәүбә

Мәхәббәттән саклыйм күңелемне —
Яңасыннан,
Саклыйм аның котылгысыз татлы
Ярасыннан.

Күтәралмас дәртле ашкынуны
Хәзер йөрәк.
Күрмәмешкә салынуың инде
Хәерлерәк.

Йөрәк тыныч, күңел сабырланды —
Гел тышаулы.
...Йә, әйтегез, шушы әкияткә
Кем ышанды?

*Июль, 2001*

## *Яшьлек дигән урамнар*

Тәрәзәсе, гөлләре,
Балкып торган көннәре.
Гөлләренә күмелеп,
Калды микән кемнәре?
Әллә елмайган иде,
Әллә күз кыскан иде,
Ашыгыплар йөгердем,
Гомерләр кыска иде.
Көтә бүтән тәрәзә,
Көтә мине Моңсылу.
Күңелгә чиртеп калды
Үкенечле ымсыну.
Сагындырган көннәрем,
Чәчәк койган гөлләрем.
Яшьлек дигән урамнар
Озатмаган кемнәрне...

*Июль, 2001*

## *Тирән таулар*

Ерак тауда кеше күренмидер,
Биектәге күрә ерактан.
Шушы таудай көчең үзеңдә дип,
Ходай тауны горур яраткан.

Түбәсенә менеп, әләм элеп:
«Жиңдем!» — диеп мөмкин шауларга.
Кузгатмагыз аның хәтәр көчен —
Вулканнар бар тирән тауларда.

*Июль, 2001*

## Албасты

Була шулай, кайчак йөрисең,
Авыр уең көчкә күтәреп —
Кайчан килер, дигән көнеңне
Кайчан китәр, диеп үткәреп.

Сыкрый җаның, сызлый бәгырең,
Өмет юлың әллә уптымы?
Синең алда якты йотучы
Каракошлы кара упкынмы...

Кем өчендер кояш сүнгәндә
Бу соңгы уй булып калмасмы?
Төш күңелдән, шайтан коткысы —
Төшенкелек дигән албасты!

*Июль, 2001*

## Безнең хәлләр, безнең горурлык

Элек тел яшергән килен
Каената алдында.
Урыс янында, татарым,
Шундый хәлдә калдың ла.

Тавышыңны эчкә йотып,
Эндәшми аварсыңмы,
Тылмачсыз да төшенерләр,
Ишеттер авазыңны.

Пышылдауга күчкәннәрне
Ташлап китә горурлык.
Соңарма, бүгенге хәлләр
Каравыл кычкырырлык!

*Июль, 2001*

## Үпкә

Чагыштыру бик урынлы,
Урман — Җирнең үпкәсе.
Кискән саен арта бара
Балталыга үпкәсе.

Каенсарда каен беткән,
Усаклыкта усак юк.
Имәнле имәнсез калган —
Урман эзе — учаклык...

Табигать биргән байлыкны
Бетерсәңме корытып —
Калырсың син төп башында
Балта сабыңны тотып...

*Июль, 2001*

## Һәйкәлдәге дуска

Сиңа әйтер җылы сүзләребез
Әйтелделәр микән барсы да,
Эчтән йоткан үкенүләр булып
Яңгыр ява кабер ташына.

Матәм җире — фани дөнья чиге,
Һәркем үз вөҗданы каршында.
Кара кайгыларны күмә-күмә
Карлар төшәр бәгырь ташына.

Салкын җиргә җылы язлар килер,
Яшәү киләчәккә ашыга.
Яңа гөлләр тагын күтәрелеп,
Башын ияр хәтер ташына.

*Ноябрь, 2001*

## Кеше озак яшәмәкче

Бик озак яшәмәкче дә,
Үзе... яшәүдән кача,
Тырышканы — гомерләрне
Гел кыскарту лабаса!

Ярый, йоклап төш күрсен ди,
Ә бит кояшны күрми:
Туйдым ла дөньясыннан дип,
Ниләр эчеп бетерми!

Адәм озак яшәмәкче
Берсен-берсе үтереп,
Үткәненә, бүгененә,
Киләчәккә төкереп.

Ачтан үлмәс өчен ясый
Үтерү кораллары,
Җирдә инде бомба куяр
Урыны да калмады.

Кеше озак яшәмәкче,
Кайсы дөньяда микән —
Көтү ягыннан борылган,
Бетү ягына киткән.

Бетерүгә көйләгән дә
Бар осталык, бар көчен,
Кеше озак яшәмәкче...
Гомер кыскартыр өчен!

*Июль, 2001*

## *Кирәк безгә...*

Ошый иде өндәү-үгетләр,
Бик ышана идек, егетләр,
Бүгенгесе авыр булса да,
Киләчәктә иде өметләр.

Көннәр-еллар анда яктыдыр,
Тормыш-көнкүрешләр яхшыдыр.
Пыран-заран килеп дошманнар,
Бөтен дөнья безнең яклыдыр.

Сугышларны шулай кичтек без,
Үлән шулпалары эчтек без,
Төзеп еллар, чыдап юлларны
Киләчәккә таба күчтек без.

Күчеш авырлыгы бар икән...
Алга!
Ялга вакыт тар икән.
Рәхәт яшәр килер буыннар,
Артка карамыйча бар икән.

Байракларны биек сузганбыз,
Бара торгач шактый кызганбыз,
Ник караңгы дөнья дисәгез —
Якты киләчәкне узганбыз...

Бүген тагын өндәү-үгетләр,
Бабай булды инде егетләр.
Адашкандыр, ахры, ышаныч,
Үткәннәрдә калган өметләр.

Хакыйкатьне кирәк танырга:
Киләчәккә нигә барырга?
Үзе килер!
Каршы алырга —
Кирәк безгә исән калырга!

*Июль, 2001*

## Иман йортыбызга

Көмеш Айны күрде
Бүген Апас таңы —
Сафландырды аңны,
Шатландырды җанны.

Ничек кенә заман
Сынап карамасын,
Кыйбласына тугры
Иман манарасы.

Ихлас бу инану
Илаһымнан иңгән,
Какшамаслык булып
Борынгыдан килгән.

Безнең кодрәт монда,
Безнең әхлак монда,
Безнең күңел монда —
Азан әйткән монда.

Зур тарихи көннәр
Хатирәсе булдың,
Колшәрифкә яшьтәш
Гасыр башлап тудың.

Имин булсын дөнья,
Исән булсын илем,
Иман йортыбызга
Бакый гомер телим.

Ничек кенә заман
Сынап карамасын,
Кыйблабызны бирмә,
Иман манарасы!

*Август, 2001*

# 2002 ел

* * *

Безнең якның илчеләре булып
Елгалары чыга Иделгә;
Дәрьяларга барып кушылса да,
Чыганагың туган җирендә.

Агышлары кайчак күңелледер,
Тавышлары кайчак моңсудыр,
Сагынулар булып кагылганы
Туган яктан килгән Моң-Судыр.

Илләр-җирләр кичеп ага сулар —
Туктау белми торган чыдам ат,
Туган туфрак сулен имә-имә
Диңгез булып үсә чыганак.

Балаларны юлга озаткан да,
Аналардай изге теләктә —
Офыкларга карап, гел юксынып,
Таулар яши туган төбәктә.

*Февраль, 2002*

* * *

Башың куйдың иңемә,
Каян килеп, яшьлегем?
Синдә янган утларны
Мин бит тирән яшердем.

«Иркәләнәм генә бит,
Үпкәләмә»... диден син.
Үткәннәрдән түгел шул,
Киләчәктән килдең син.

Үкенечле мәхәббәт
Әрнеп-сызлап яңарды,
Елмаюың кузгатты
Җанда татлы яраны.

Ах, бу таныш янулар,
Элек ничек түзелгән?
Иркәләнәм генә бит,
Үпкәләмә үзең дә...

*Февраль, 2002*

## *Күлле-Киме*

Уйчан-сабыр өянкеләр,
Җанга якын Күлле-Киме —
Сибгат абый, сине эзләп
Еллар тулып көннәр килде.

Бездә синең сагынулар,
Һаман тарта Күлле-Киме,
Илһам туган нигезеңә
Варисларың башын иде.

Кадерле як, газиз туфрак,
Җырлы чишмәләрнең иле,
Мөлдерәмә моңнар тулы
Күлле-Киме, Күлле-Киме...

*Февраль, 2002*

## *Нинди хикмәт*

Мәхәббәтле, нурлы күзләр
Шундый якын, шундый тере...
Көне буе мин бәхетле —
Исән булып төшкә кердең.

Нинди хикмәт, могҗиза бу
Заманнарны алыштыра:
Үткәндәге теге дөнья
Яшьлек белән кавыштыра.

Сагынышып, сүзсез генә
Күз карашып алдык төштә.
Сөюеңнән бу дөньяга —
Күңелемә якты төшә...

*Март, 2002*

## Төнге уй

Таң атар алдыннан
Караңгы куера.
Якты көн күз йомган,
Мин дә шул куенда.

Кизүдә шәм-өмет,
Гел сүнми уеңда.
Яктыра ышаныч
Офыклар буенда.

*Июль, 2002*

## Җәбер

Үткәннәрем күләгәсе
Гел бүгенгегә төшә,
Онытырга һич тә бирми —
Газаплап керә төшкә.

Еллар еракта калса да,
Борчулар адашмаган,
Әйтерсең лә ул чактагы
Төннәрем алмашмаган.

Гомер үтә, бәгыреңә
Уелган эзләр бетми,
Җиңелгән куркулар һаман
Жаныңны эзәрлекли.

Дәһшәтләр дә, фаҗигалар
Гасырда узмыйдыр шул —
Һәлак әткәйләр ярасы
Улларда сызлыйдыр ул...

*Июль, 2002*

## *Елама, тал*

Таллар тамырсыз микән;
Сандугач булып сайрасак,
Безне танырсыз микән?

*Халык җырыннан*

Ерактан ук күреп аласыз сез,
Инеш буендагы талларым,
Еллар үткән саен, сизәсездер,
Танышларның кими барганын.

Күпме ир-егетләр бәхилләшеп,
Эчтән генә йотты күз яшен,
Белә иде алар, белә иде,
Исән кайтып сезне күрмәсен.

Таллар, таллар, сабыр талларым сез,
Яфрак ярып, күзен коясыз,
Һәр яфракта сары сагыну бар,
Шәһитләрнең җанын тоямсыз?

Аяз көнне биткә тамчы тамды,
Тагын тамды... аңла аңласаң,
Безнең әнкәйләрдәй тып-тын гына
Таныш талым елый лабаса.

Уйлый идем, әллә үзем генә
Шул сагышлар белән яшимме?
Мин кушылдым синең әрнүеңә,
Син юасың минем яшемне.

Елама тал, җаным, еламсар тал,
Сез дә, без дә түгел тамырсыз.
Сандугачлар булып кайта алсак,
Шәт безне дә әле танырсыз...

*Июль, 2002*

## Шифалы җир

Җәйләрендә авылыма кайткач,
Уянам мин һәрчак иртәрәк,
Кырларыма карыйм, үзәннәргә
Күз карашым белән иркәләп.

Һәр тарафы сәнгать әсәредәй,
Әмма җанлы, тере манзара.
Йончыган җан монда тынгы таба,
Бәргәләнгән рухың тазара.

Кырлар киңлегендә тынычланам,
Иркенлеген җыям күзләргә.
Офыклары колач ачып көтә —
Кысанлыклар булса, түз, бәндә.

Игеннәрем дә бит юксынганнар,
Япан кырда ялгыз түгел мин.
Бүтән беркайда да күңелләрем
Мондагыдай ташып түгелми.

Шушы иркен биеклектә тудым,
Бүтән якка әйтмим ким дип тә —
Сагынулар, чиксез яратулар
Сыяр бары шушы киңлеккә!

*Июль, 2002*

## *Сусау*

— Чишмә дустым, нихәл сез,
Илгә хезмәт итәмсез?
Еракларга китәмсез,
Безнең кебек икәнсез...

— Чыганакта яшим мин,
Туган җирдән өзелмим.
Шуңа күрә түзәм мин,
Сезләрне көтеп алам,
Юксынып эзләп барам.
Сусап кайттыңмы, балам?
Тәмам кайттыңмы, балам?
Мин бит сезгә сусадым...

*Июль, 2002*

## *Синең кодрәт*

Ходай кошка канат биргән:
Оч күккә таянып, дигән,
Тоеп киңлеген-зурлыгын,
Таты очу хозурлыгын.
Очарсың пар канат барда,
Синең кодрәт — канатларда!

Пар канат бирдең, Илаһым,
Мәхәббәтем ул, Илһамым.
Минекеләр җирем-күгем!
Уйга калдым әле бүген:
Канатсыз мин беркем түгел...

*Июль, 2002*

## Кыйбла

*Кизләү сабантуе үткәргән
авылдашларга*

Кыйблага караган кизләү
Тәсбих тартып ага, диләр.
Суын эчеп үскән затлар
Дөрес юлны таба, диләр.

Дымбылатым, зәм-зәм суың
Даның булып ерак киткән.
Бабамнарны әсир иткән —
Олы Бакырчылы иткән.

Әнкәм сөте белән сине
Мин дә имеп үскән улың,
Синең эздән тайпылмады
Киләчәккә үткән юлым.

Кыйблага караган кизләү
Тәсбих тартып ага бит ул.
Рәхмәтенә лаек булган
Бәхеткә юл таба бит ул.

*Июль, 2002*

## *Өсте һәм асты*

Йә чәчү өсте,
Йә печән өсте,
Йә урак өсте...
Өсте-өстенә
Эш тә эш кенә!

Берсе-берсенә
Һаман ялгана,
Авыл халкына
Кайчан ял аңа?

Әһә, кыш килер,
Кышын ял туар —
Аюдай йоклап
Чыкса мал-туар?

Иген дә үстер,
Иген ик, Авыл,
Бөтен ил көтә —
Кирәк бит, Авыл!

Эшләгән өчен
Түләү дисеңме?
Нәрсә булганын
Күрдең ич инде.

Тырышу ахры
Катырак булды,
Икмәк ахрысы
Артыграк уңды.

Кая куярга,
Күп булгач — арзан,
Хәзер дөньяга
Хуҗа бит базар.

Техника кыйммәт,
Тишек шул кесә,
Ах, комбайн да
Шул кырда үссә...

Карама инде
Хезмәт хакына,
Эшли генә күр
Алла хакына.

Чәчү өсте дә,
Печән өсте дә,
Килеп тора бит
Өсте-өстенә.

Нинди ял сиңа,
Нинди аш өсте?
Һәрвакыт әзер,
Син бит — баш өсте!

Сынатмый иде
Безнең татарлар.
Әзергә хәзер
Алыпсатарлар.

Менә кемнәргә
Гел сөтнең өсте!
Өсте дә өсте,
Үсте дә үсте...

Өсте әйбәт тә,
Нишләр соң асты?
Шул сорау өскә
Чыкты да басты!

*Июль, 2002*

## *Бабай: мәхәббәт турында*

— Яшьләр йөри, әйтерсең лә
Гел үзләре иҗат иткән —
Мәхәббәт ул, адәм белән
Аҗагандай иңгән күктән.

Тик шуннан соң, сәгать сыман
Йөрәкләр дә йөреп киткән —
«Сөю» дигән серле тылсым
Дөньяга җан өреп киткән.

Мәңгелек двигатель шул —
Ходай биргән кодрәт шунда.
Тикмәгәме яшь-җилкенчәк
Әтәчләнеп йөри монда?

Яшьлек үтәр, ә мәхәббәт
Мәңгегә ул үзең белән.
Сорыйсы юк, сыныйсы юк —
Анысын мин үзем беләм!

*Июль, 2002*

## Тәрәзәдән гөлләр карый...

Тәрәзәдән гөлләр карый,
Гөлләр микән?
Әллә чибәр кызлар микән?
Кемнәр икән?

Тәрәзәмә үрелгәннәр
Гүзәл икән,
Гел дәшмичә ничек алар
Түзә икән?

Күзлегемне киеп баксам —
Гөлләр икән,
Яшьлегемдә чәчәк аткан
Көннәр икән...

Касәләрдә иртәнге чык —
Таммый икән.
Мин таныдым, гөлләр мине
Таный микән?

*Июль, 2002*

## *Бәхет кайда?*

Син карыйсың
Үткәннәрдән,
Күптәннәрдән,
Киләчәкне
Көткәннәрдән.

Син торасың
Сөенешкән,
Сыенышкан,
Сөеп дәшкән
Ак чәчәкләр
Арасында.
Син сыныйсың
Айлы төннәр,
Нурлы көннәр,
Моңлы өннәр
Тарафыннан.

Син сорыйсың:
— Ничек эшең?
Мин әйтәмен:
— Үзең төшен —
Яңа юллар
Түшәп яшим;
Бик шәп яшим —
Үткәннәрне
Күшәп яшим...

Бәхетле без
Бәхет өмет
Иткән чакта,
Шунда ул, дип,
Киләчәктән
Көткән чакта.

*Июль, 2002*

## Балачагым сукмагы

Инеш буйлап, бакча артларыннан
Борма-борма сукмак йөгерә.
Түбәночны югарыочка ялгап
Көнгә ничә урап өлгерәм!

Яланаяк чап-чап басып җиргә
Канатланып үттем шушыннан.
Хыялларым ымсындыра торгач,
Олы юлга барып кушылган.

Еллар-юллар йомгакларын сүтеп
Кайтам балачагым эзеннән.
Язгы сулар ярны ашаган шул,
Таныш сукмакларым өзелгән.

Кордашларым киткән хушлашмыйча,
Гомерләрнең кырыс исәбе.
Исән бары, бакый йортыбызга
Барып җиткән сукмак кисәге...

*Июль, 2002*

## *Киләчәкне төзүчеләр*

*Олы Бакырчымда яңа мәктәп
ачылу уңаеннан*

Таралган һәм тузган заман,
Азмы өмет өзүчеләр.
Әмма бар бит, җиң сызганып
Бу тормышны төзүчеләр.

Шактый булса, тешне кысып,
Түбән карап түзүчеләр,
Күккә таба үсә-үсә
Кирпеч тезә төзүчеләр.

Сыный еллар, бәлкем, кемдер
Кулын селтәп, тезен чүгәр.
Йөз елларга исәп тотып
Мәктәп сала төзүчеләр.

Берөзлексез килсен монда
Фәндә тирән йөзүчеләр —
Кирпеч-кирпеч китап алып
Киләчәкне төзүчеләр.

Җимерүне аклар өчен
Күп ул сәбәп төзүчеләр.
Какшамаслык ышанычка
Нигез сала төзүчеләр.

Яңа мәктәп бик килешә —
Авылымның йөзе чибәр.
Үз эшегез һәйкәл булсын —
Рәхмәт сезгә, төзүчеләр!

*Июль, 2002*

## Син дә бер, мин дә бер

*2002 елның октябрь аенда*
*халык санын алуга карата*

Сентябрьдә син дә бер, дип,
Сентябрьдә мин дә бер, дип,
Тигезлекне саклап килдек,
Бер алманы бишкә бүлдек.

Төрле тараф, төрле җирдә
Яшәсәк тә, милләт бер лә —
Безнең шушы бергәлекне
Өзмәкчеләр октябрьдә.

Арабызга кермәкчеләр,
Таркатмакчы, бүлмәкчеләр,
Сан алганда санга сукмый
Түбәнсетеп көлмәкчеләр.

Хәтәр булыр, юлны борсак,
Гел битараф булып торсак,
Бу хәл безнең бергәлекне
Исбатларга булсын форсат.

Син дә бер, дип, мин дә бер, дип,
Бердәмлекне саклап килдек,
Сыната һәм сына күрмик —
Бер татарны бишкә бүлмик!

*Июль, 2002*

# «Кайбыч дәфтәре»ннән
## (1945 – 1950)

Моңсу елларның башында
Үкенечләр бар сыман —
Беренче шигырьләр калды
Яшьли сөйгән яр сыман...

*Беренче шигырьләр... Бу хакта «Минем беренче гомерем» исемле истәлекләр китабымда язган идем. Укучылар белән очрашулар вакытында миннән еш кына: «Беренче шигырегезне хәтерлисезме?» — дип сорыйлар... Мин аны таптым. Ул — «Моң» дип исемләнгән. 1945 елның 8 гыйнварында туган авылым Олы Бакырчыда язылган. 1944 — 1945 елның кышында Карамасар, Сатмыш тирәсендә урман кисүчеләр бригадиры булып эшләгәндә, берничә генә көнгә ялга кайткан идем. Шунда язылган ул шигырь. Сугыш елларының ачлыгын, ялангачлыгын, сугышта әтисен югалтуны кичергән моңлы баланың, 16 яшьлек егетнең хәле-халәте бу.*

*«Кайбыч дәфтәре»ннән, дидем. Туган авылым хәзер Апас районында булса, ул елларда Кайбычта иде. 1945 елның языннан район үзәгендә эшләдем. Сугышка хәтле һәм сугыштан соң ун ел гомерем шунда узды. Беренче шигырьләрем Олы Бакырчыда язылса, мавыгып иҗат иткән елларым Олы Кайбычта калды. Казанга мин шуннан киттем.*

## 1945

### Моң

Язам әле җырларымны,
Укырсыз, калсын монда,
Әйтерсез, булган баланың
Башы кайгы һәм моңда.

Сагынырсыз кайчак мине
Һәм укырсыз җырларны.
Күреп җырдагы сагышны,
Каһәрләрсез елларны.

Гаепләмәгез елларны,
Еллар гаепле түгел.
Нәрсә әйтергә белмәгәч,
Әйтә моны тик күңел.

Искә алып әгәр мине
Укысагыз җырларны,
Җырларым аша күрерсез
Мин яшәгән елларны.

*8 гыйнвар, Олы Бакырчы*

### Үткән яшьлек

Их, яшьлегем, ерак калдың,
Инде кире кайтмассың.
Үткәндәге таңың кебек,
Бөдрәләнгән чагың кебек,
Икенче кат син бит күкрәп
Чәчәк атмассың.

*3 август, Кайбыч*

## *Кичке уйлар*

Җәйге көннең матур киче иде,
Минем күңел никтер җилкенә,
Тәрәзәмне ике якка ачып
Таянамын китап читенә...

Табигатьнең күреп ямьле чагын,
Яфрак ярган талын-тирәген,
Бергә булган язлар искә төште,
Шуңа минем яна йөрәгем.

Үтә еллар, истәлекләр сыман
Тупыл мамыклары коела.
Үткән гомер, ничек үтсә дә ул,
Күңелле үткән кебек тоела.

*15 май, Кайбыч*

* * *

Уйна, дускай, сузып-сузып
Тальян гармуннарыңны!
Җырлыйм әле, онытмаммы,
Кайгы, зар-моңнарымны?!

*3 август, Кайбыч*

* * *

Чара эзләп ярсу йөрәккә
Шигырь язам... шулай юанам.
Аның аша җылыйм хәсрәттә,
Шатлыгымда чиксез куанам.

*9 август, Кайбыч*

## Туган илне сагыну

Бармы икән? Юктыр минем кебек
Болай өзелепләр сагынган!
Йөрәгемә рәхәт булып китә —
Җилләр иссә туган ягымнан.

Кайнар битем сыйпап юаталар,
Әрнү-сагышларны басалар,
Узган еллар күңел дәфтәреннән
Хатирәләр битен ачалар.

Таныш җилләр, тансык җилкәйләрем
Бәгыремә үтеп керәләр,
Сагындырып, ныграк кабындырып,
Йөрәк-учагыма өрәләр.

*3 август, Кайбыч*

## Тыңла, йөрәк

Шашкын йөрәк, гомрең үтте инде
Синең шулай һаман ярсынып.—
Очалмыйча тыпырчынган коштай
Күкрәк читлегемне тарсынып...

*15 сентябрь, Кайбыч*

* * *

Сикреп-сикреп ага кар сулары
Ермаклардан алга ташынып,
Шул сулардай үткән гомеремне
Искә алам хәзер ачынып.

*29 октябрь, Кайбыч*

## *Мәхәббәтнең кайбер серләре*

Борын-борын әүвәл заманнарда
Яшәгән, ди, Сөләйман патша.
Күпне белгән, бик тә зирәк булган,
Һәм болайрак дигән бу хакта:

— Тау астыннан чыккан чишмә суы
Беләм ник саф-салкын булуын,
Йолдызларның нигә атылуын,
Айдан күккә нурлар тулуын.

Беләмен мин нигә җан иясе
Тау-мәгарә сайлап яшәвен,
Явым-төшем нидән булганлыгын,
Күк күкрәвен, яшен яшьнәвен.

Әйтә алмыйм әмма мәхәббәтнең
Кайдан килеп, кайчан китәсен...
...Йөрәгеңнең шаһинәсе әйтер —
Патшалардан җавап көтмә син!

*12 август, Олы Бакырчы*

## 1946

* * *

Әллә нинди шатлык булыр сыман —
Канатлана күңел, җилкенә!
Кайгы болытын куып җылы җилләр
Исә мәллә шатлык иркенә?

*6 гыйнвар, Кайбыч*

* * *

Соңгы чиген белмим, көзенме,
Буранлаган салкын кышынмы,
Йөрәк тынар, туктап тибүдән —
Кисеп юлын синең дустыңның.

Ә язлар ул килер бакчаларга,
Чәчәк атар гөлләр нурланып.
Үзем үлсәм, яшьләр телендә
Җырым яшәр әле җырланып.

*4 апрель*

* * *

Сипче, кояш, шәфкать нурыңны,
Йөрәгемә җылың үткәнче,
Кайгы аралаш түккән яшьләрем
Уйчан йөздән очып киткәнче...

*6 апрель, Кайбыч – Олы Бакырчы*

## *Яз кайта*

Карны челтәрләп
Вак яңгыр ява,
Өй түбәсеннән
Энҗеләр тама.

Һавалар дымлы,
Бураннар тынды,
Бозлар-сөңгеләр
Коелды-сынды.

Кояш сөенеп
Шаян елмая,
Юрганын ачып
Елга уяна.

Бии каңгылдап
Өйдә ата каз:
«Биби-бәбкәләр
Алып кайта яз!»

*24 февраль, Кайбыч*

* * *

Кемгә сөйлим икән зарларымны,
Яшь йөрәгем авыр яралы.
Белмим нигә дөнья һаман безгә
Мәрхәмәтсез усал карады.

Мәсхәрәләп көлмә әле, тормыш,
Мин җир улы, синнән көлдермәм —
Сызлансам да, сиңа сер бирмәм,
Эчем — ялкын, әмма сиздермәм!

*4 апрель, Кайбыч*

* * *

Йөрәгемнең бар тибешен,
Сүнмәс рухын, хисләрен,
Халкымның бәхете өчен,
Мәңге азатлыгы өчен
Багышлармын, дусларым.

*7 апрель, Олы Бакырчы*

* * *

Көн артыннан көннәр ялганалар,
Яшьлек гомеркәем үтәсең.
Белмим нидән син канәгать түгел,
Белмим нәрсә өмет итәсең?
Шушы елларыңны сагыныр өчен
Киләчәкне, ахры, көтәсең?!

*10 апрель, Кайбыч*

## *Яз көнендә*

«Яз күңелле, эх!» — диясе килә,
Күкрәк киереп, иркен бер сулап.
Күңелләргә шигъри дәрт агыла,
Йөрим әле ялгыз бер җырлап.

Кар эрегән җирләр, чирәмнәрне,
Иркен кырлар, инеш буйларын,
Барсын күреп күңел шатлана —
Бәйрәм итә хисем, уйларым.

*21 апрель, Олы Бакырчы*

* * *

Нурга манып иркен табигатьне
Алсуланып ал таң аткандыр,
Шундый туар якты көнне күрми
Канлы гәүдәң җирдә яткандыр...

Мин онытмам сине, газиз әткәй,
Соңгы тапкыр йөрәк типкәнче,
Соңгы чиккә кадәр, соңгы чиккә! —
Тамырларда каным кипкәнче.

*7 сентябрь, Кайбыч*

## *Кышкы хыяллар*

Мавыгучан, дисә дисеннәр,
Бүген тагын чыгып текәлдем,
Уйларымны каләм очында
Галәм тарафына күтәрдем.

Тулган айга карап сокланам,
Бу бит үзе гүзәл бер рәсем,
Читкә кагып болыт пәрдәсен
Киләә тапсыз, ачык күрәсем.

Үч иткәндәй соры болытлар
Яшермәкче булып каплыйлар,
Серле әкият: уяу пәриләр
«Нур патша»ның
кызын саклыйлар!

Җил-җилкенчәк тынгы белми ул,
Исәбе юк аның туктарга,
Ник өрфия болыт ябынып
Үле тынлык белән йокларга!

Сәйяр җилкәй уза сызгырып,
Һавадагы эзсез юлыннан.
Белештерми уйнап барганда
Кыяларга саксыз орынган.

Күккә ашкан чакма тауларда
Әрнүеннән үкси искән җил,
Ә түбәндә, дала иркендә
Зыңлый чана эзе төшкән юл.

*9 декабрь, Олы Бакырчы*

## Иртән

Алсу күк чикләрен бизәкли таң,
Төн утырып чиккән кыз кебек.
Кышкы көннең тыныч һавасында
Күтәрелә төтен гел биек.

Таулар буендагы үзәнлектә,
Сабыр, салмак тынлык эчендә,
Уяна авыл тәрәзәгә карап,
Йокыдан соң килеп исенә.

*10 декабрь, Олы Бакырчы*

## Урман тынган

Урман тынган, калган сабырланып,
Ап-ак бәсләр белән чорналып,
Агачлар да башын иеп тора —
Кыш тынлыгы белән моңланып.

Тып-тын әле. Ап-ак бәсләр коеп
Кошлар гына очып киткәли.
Куркуыннан ялт-йолт каранғалап,
Ялгыз куян сикереп үткәли.

Урман тынган. Әмма яз килүен
Бөреләре белән тоя ул,
Иркен сулап тиздән шаулар өчен
Әле тынып куәт җыя ул.

*22 декабрь, Олы Бакырчы*

## 1947

### Сагыну билгесе

Иртән кинәт көн бозылып китте,
Аяз күкне болыт каплады.
Салкын һава шулчак дымсуланды,
Карлы яңгыр ява башлады.

Кырку февраль язга охшап калды,
Уйсу җиргә сулар җыелды,
Агач башларына кунаклаган
Кар шыбырдап җиргә коелды.

Болытлар да, түбән генә йөзеп,
Эшне бердәм, юмарт йөрттеләр,
Кыш түренә язның матурлыгын,
Үзенә хас ямен керттеләр.

Матурлыкны, тик югалткач кына,
Нечкәлеге белән тоясың.
Үкенүләр арта, һәм гадәттә,
Кадрен белми шулай җуясың.

*25 февраль*

## *Җырлар дәшә*

Йокысыз үткән төннәрем,
Иртәләр-кичләрем бар,
Язам әле, телгә килеп,
Атлыккан хисләрем бар.

Күпме уйлар-кичерешләр,
Каршылыклар үтмәдем,
Күпме киртәләр сүтмәдем,
Күпме көчләр түкмәдем.

Яңа юллар сыза калэм,
Юл ерак, авыр димим,—
Рәшә түгел, йолдыз дәшә,
Дәшә моңнарым минем!

*4 март, Олы Бакырчы*

## *Тукай клубы*

Тыштан уйлыйм, эче тулы шагыйрьләрдер,
Шигырь уку белән алар «шагыйльләр»дер.
Уйларымда, шунда җиткәч, туктап калам.—
Туры килер дим керергә — килер заман.

*27 май, Казан*

## *Унтугыз яшь*

Чынлап каршыларга өлгермәдем,
Унтугыз яшь, инде тулдың да.
Саубуллашып башым иямен мин
Гаепледәй синең алдыңда.

*Ноябрь, Олы Бакырчы*

## Кайбыч

Кайбыч, Кайбыч, ничек итеп сине
Сагынмассың, искә алмассың,
Истәлегең, еллар таңы аша,
Онытмыйча саклап бармассың?

Матур яздай яшьлек гомеремнең
Синдә уздым алтын елларын,
Синең аша үтте башлангычы
Киләчәккә барыр юлларның.

Ашкын йөрәк тапты эзләгәнен,
Синдә үсте шигъри хисләрем,
Яшь каләмнең синдә сынадым мин
Сәләтен һәм иҗат көчләрен.

*26 июнь*

* * *

Йөрәк нигәдер ашкына,
Ярсый ул, канатлана,
Кая бармыйм, кайда йөрмим
Шул ук хәл кабатлана.

Каләм алам, җырлар язам,
Әллә фикерем тәмам? —
Моңа кадәргедән күбрәк
Хисләр эчендә калам...

Кичерәсе тойгыларым
Дулкынландыра икән,
Киләчәк туар таңнарның
Нурларын тоям икән!

*4 июль, Кайбыч*

* * *

Соңы иде кинәндергән җәйнең,
Иркен кырлар моңсу төс алган,
Яр читендә җикән-камышлары
Шауламыйлар, арып тын калган.

Уйчанланып тора зәңгәр күл дә,
Дулкыннарын кагып уйнамый,
Бөдрә башлы көяз каеннар да
Суда күрә зифа буйларын.

Балыкчы карт җәтмә челтәрләрен
Күтәргән дә көймә борнына,
Салмак кына тарта ишкәкләрен
Үзе белгән аулак урнына.

Сызылып китте шунда таныш аһәң,
Күл ярында кемдер җыр суза.
Туган яктан аерыла кошлар,
Моңланырлык чак шул моңсыз да...

*18 сентябрь*

## Буш вагонда

Ноябрьнең кара төннәрендә,
Каршы искән салкын җилләрендә
Синең белән, яшьлек юлдашым,
Кайткан идек икәү без бергә.

Кайткан идек икәү без бергә
Көзге көннең салкын төнендә,
Берләштереп йөрәк ялкынын,
Икәү җиңеп көзнең салкынын.

Сагындыра салкын көз төне,
Бүтән очратмадым көткәнне.
Поездлар гел килә әйләнеп,
Тик кайтарып булмый үткәнне.

*6 ноябрь, Олы Бакырчы*

## 1948

### *Айлы тынлык*

Көмеш нурларын сибеп ай
Иркәли җирне,
Әкрен генә сыйпап уза
Сизгер таң җиле.

Якты тынлыктан оептыр,
Этләр дә өрми,
Бүре-бимаза, ахрысы,
Бу якта йөрми.

Яңа туган мамык кардан
Егет-кыз бара:
Бер-беренә сыенышкан
Эзләре кала...

*28 гыйнвар, Олы Бакырчы*

### *Саумы, Казан!*

Саумы, Казан,
Иҗат башкалабыз,
Чакыруың белән киләмен,
Киләчәгем үренә күтәрелгән
Юлларымны синдә күрәм мин!

*26 ноябрь*

## Якты манзара

Инеш ярына сыенып
Таллар үскәннәр,
Тал арасыннан чаңгыда
Шуып үткәннәр.

Ландыш тәлгәшләре булып
Кар кунган талга,
Бизәкле сурәтләр төшкән
Каршы як ярга.

Асылташ булып ялтырый
Куакта карлар,
Әллә кояш җиленнән дә
Сискәнә алар?

Түбәндә, серле тынлыкта
Чишмә тавышы:
«Мин исән, мин туңмадым!» — дип
Көйләп агышы.

*30 гыйнвар, Олы Бакырчы*

## Кышкы төн

Ай нурлары, әйтерсең лә
Туңып тетрәнеп төште,
Күләгәләр дә салкыннан
Өшеп калганнар төсле.
Тын.
Морҗадан
Күк төтеннәр
Күкне бораулагандай,
Бөтерелеп менәләр дә
Шым гына таралалар...

*18 декабрь*

* * *

Гаҗәпләнсә гаҗәпләнер дус-ишләрем,
Үз-үземнән гел канәгать булалмадым:
Аз күренде миңа һәрчак үз эшләрем,
Чөнки вөҗдан кушканны мин биралмадым.

Йөрәк әрнеп җәфалана шуның өчен.
Олы уйлар күкрәгемдә тупланса да —
Әйталмадым туган илем, халкым өчен,
Очкын чыкты, йөрәгемдә ут янса да...

Әй, шагыйрьнең тынмас җаны, кайнар җаны,
Иҗатыңда җырлар таңы атар тиздән,
Вөҗдан, вөҗдан, гражданлык саф вөҗданы —
Бу җырларның тезмәсендә аны сизәм.

*25 апрель, Кайбыч*

## *Юлда*

Колангыга илткән олы юлдан
Туры атта җилеп барабыз,
Пыяладай тигез, такыр юлдан
Сайрап кына бара чанабыз.

Елгыр атның үткен дагасыннан
Бозлы карлар чәчрәп китәләр,
Әрсез җилләр салкын очкыннарны
Сибеп-сибеп ала битләргә.

Тигез юлдан бару сизелми дә —
Канатлымы әллә чанабыз?
Буран уйнаттырып оча-оча
Киләчәккә киттек — карагыз!

*26 ноябрь*

## 1949

### Тамчы тама иде

Тамчы тама иде, гөрләвекләр
Елтыр-чылтыр килеп агалар,
Ачык зәңгәр һавасыннан язның
Кыр казлары очып баралар.

Чагылдыра күзне якты кояш —
Каш өстенә куеп кулымны
Мин күзәтәм челтәр карлар эреп,
Чирәм шытып яткан болынны.

Син йөгереп килдең, кулларыңда
Бөреләрен ачкан тал иде.
Очкынланган дәртле күзләреңдә
Мәхәббәтле ымнар бар иде.

Шул көенчә калдың күңелемдә,
Языбызның якты таңында:
Ак күлмәктә шомырт-кара толым,
Тал песие иде кулында.

Язлар саен сагынып искә алып
Кабатлыйм да синең исемне,
Тойган төсле булам назлы җилләр
Битләремне сыйпап исүен.

Тамчы тама иде, гөрләвекләр
Урамнардан шаулап агалар.
Яшьлегемнең зәңгәр гөмбәзеннән
Хыялларым очып баралар...

*6 февраль, Олы Бакырчы*

* * *

Менә мин кем, карагыз, дип,
Шапырынып йөрмәдем.
Үстем мин гади һәм тыныч —
Дуамал ярсу белмәдем.

Ник шауларга?! Ышанычым,
Зур, изге теләгем бар,
Күкрәгемдә шигъриятнең
Тынгысыз йөрәге бар!

*27 февраль*

## *Сагындым мин*

Һаваларда очынып тургай сайрый,
Җилпеп-җилпеп кенә канатын,
Сагындым мин синең керфекләрең
Сирпеп-сирпеп алган карашың.

Сагынудан ярсып йөрәккәем
Тургай кебек канат кагына,
Тургай язны җырлап көткән сыман
Юксына ул, сине сагына...

*13 июнь, Мушки-Бортас*

* * *

Яле кайгы, үкчәң күтәр,
Юк монда сиңа урын!
Мин бу җиргә мәңге көләч,
Шат йөрәк белән тудым!

*28 февраль*

## Көзге урманда

Яратам мин көзге вак яңгырның
Күлдәвектә биеп туймавын,
Салкынчарак, дымлы саф һаваның
Зәңгәрләнеп, тетрәп уйнавын.

Моң йөгерә яфрак йөзләренә,
Соңгы чәчәкләр дә сибелә.
Җилләрендә кырыс көз сулышы,
Тынгысызлык инде сизелә.

Яфраклардан күчеп яфракларга
Аерылу яше тамчылый.
Карт имәннәр сабыр башын иеп
Алтын көзне тыныч каршылый.

*28 август*

## *Узармы давыллар*

Чәчләрен, чәчләрен
Талгын җил тарата,
Күзләрен, күзләрен
Төбәгән еракка.

Ерактан, шул яктан
Көтәсең син нәрсә?
Уянып, сискәнеп
Китәсең, җил бәрсә!

Җилкәнен киергән
Көймәне эзлимсең,
Сагынып, ашкынып
Иркәңне күзлимсең?

Узармы давыллар,
Тынармы дулкыннар,
Маяктай йөрәкләр
Сагынып сулкылдар.

*22 июль, Олы Бакырчы*

## Яшьнәсен язгы яшеннәр

Язгы яшен күктә уйный,
Яшьлектәй җитез, кайнар.
Яшәргә теләгән кеше
Юлын шундыйны сайлар.

Яшьнәгәч яшьнәп яшәргә,
Яшеннәр уйнатырга,
Күңелгә тулган яшенне
Җырда яңгыратырга.

Яшен үзе безнең дәрттән
Чәчрәгән очкын гына,
Яшендәй үтсен яшьлегең,
Форсатны ычкындырма.

Яшьнәсен язгы яшеннәр,
Яшеннәрдән көнләшмим —
Тормышта мин яшеннәрдән
Көчлерәк яшьнәп яшим!

*23 июль*

## Гаҗәпләнмәгез

Иҗат итәр идем мин ашкынып,
Ялкынланыр идем, сүрелмәс!
Гаҗәпләнмәгез сез, бәлки, инде
Минем исем кабат күренмәс.

Бу яшәвем миңа хәтта әле
Үзе дә бик авыр бирелә;
Яшь күңелнең чигәсендә инде
Буран аклыклары күренә.

*11 сентябрь*

## Бер кодрәт бар

Караңгысы төннең иңеп килә,
Шомлы шаулый, убыла упкыннар.
Ташланалар баркас күкрәгенә
Акуладай усал дулкыннар.

Йөзә баркас, йөзә бер ялгызы,
Батыр йөрәкләрне кем тыяр?!
Упкыннарга бирмәс бер кодрәт бар,
Ул — җиңүгә булган ихтыяр!

*Декабрь*

* * *

Мин тормышка горур карап үстем,
Канат җәйдем кыю лачындай.
Канатларың булып,—
Очалмасаң,
Йөрәк түзәр микән, очынмый?!

*13 сентябрь*

* * *

Күкрәгемне ачам
Давылларга,
Чәчләремне җилләр тарасын,
Мин кыяда горур басып торам,
Офыкларга төбәп карашым.

Мондый чакта
Шулай була хәтта,
Иңнәреңдә канат тоясың,
Һәм сизәсең, гүя син ул шулай
Кыя булып басып торасың.

Табигатьнең
Иркен кочагында
Көйгә салып җырын давылның,
Йөзләремне куеп искән җилгә
Язмышымны каршы алырмын.

*13 сентябрь*

## *Сөенәм!*

Җем-җем итеп торган ап-ак карлар
Кайнар комдай кала уалып,
Айлы төннең зәңгәр гөмбәзенә
Күк төтеннәр менә уралып.

Шундый матур дөнья, кышларында
Өтеп алган чаклар булса да,
Яшәү — бәйрәм, яңа көннәр белән
Яңа авырлыклар туса да!

Мин яшь әле,
Чын кадерен белеп
Яр сөям һәм үзем сөеләм.
Бар дөньясын яктыртабыз диеп,
Тулган айга карап сөенәм!
Сө-е-нә-әм!

*29 декабрь*

## 1950

### *Бәхилләшү*

Бөек Ватан сугышында һәлак
булган Кайбыч егетенең уйлары.
*Әнисе теләге буенча язылды*

Соңгы тапкыр урам әйләнгәндә
Моң сарылып, күңел тулышты.
Насыйп булыр микән күрешүләр,
Бик аяусыз, диләр сугышны.

Әткәй, әнкәй,
Якын туганнарым,
Ник өзелеп шулай багасыз?
Еламагыз, сез дә ут йотмагыз,
Ут эченә китә балагыз!

Уйнап йөргән урам, туган авыл,
Авылдашлар, сез дә хушыгыз,
Бәхилләшә бүген сезнең белән
Яланаяк йөргән дусыгыз.

Их, Кайбычым,
Бүген соңгы тапкыр
Караганда сиңа сулыгып,
Йөрәкләргә чыңлап үтәсең син
Үзәкләрне өзгән җыр булып.

Әнә минем
Сөзәк ярлы Бәрлем,
Ярларында зифа талларым,
Айлы төндә, чыклы иртәләрдә
Бу җәйдә мин йөри алмамын.

Урманнарың шулай шаулар һаман,
Аланнарда пешәр җиләкләр.
Чәчәк җыя-җыя шатланышып
Ашкынырлар бүтән йөрәкләр.

Җиңүдән соң кичке уеннарда
Тугайларда таган асылыр —
Йолдызларга карап, канатланып,
Парлы егет-кызлар атынып.

И туган җир!
Ничек итеп сине
Калдырып соң китим мәңгегә.
Юаталар. Аннан ни файда соң,
Сугыш сугыш инде, кем белә...

Исән булсак, бер кайтырбыз дигән
Өмет тә юк түгел күңелдә.
Ә хәзергә
Кайтыр еллар түгел,
Китәр юллар гына күренә...

*6 гыйнвар*

* * *

Илаһи көч сизәм йөрәгемдә,
Мәхәббәтем мәңге үлмәс ул.
Кояш кебек балкып торачак ул,
Давылларны кичеп сүнмәс ул!

*31 гыйнвар, Кайбыч*

* * *

Күбәләктәй карлар оча бүген,
Һавасы да рәхәт, җиңелчә.
Әмма күңел, һава торышына
Һәрчак бәйле түгел, минемчә.

Җиңел булса әгәр йөрәгеңдә,
Бөтен нәрсә җиңел күренә.
Борчуларың булса, якты көн дә
Болытларын тарта күңелгә.

*2 февраль*

* * *

Моңсу булса, сызып җырлап җибәр,
Җыр тарата моңны, сагышны.
Җыр җиңә ул, йөрәк тыңлый аны,
Җыр көченә ул да карышмый.

Җыр ул — бәхет,
Җыр ул — шатлык,
Җыр ул — яшәү дәрте, кайнары.
Җыр ул — тормыш,
Җыр ул — яшьлек,
Җыр ул балкып атар таңнарым.

Мин шуңарга җырлыйм, иҗат итәм,
Тик җыр белән ачам сулышым;
Юк яшәвем минем аннан башка,
Юк кояшым, якты тормышым.

*2 февраль, Кайбыч*

* * *

Киләсе таң, белмим, ничек туар,
Мин булмамын, бәлки, таң аткач.
Тик кешене үлем җиңә аламы,
Янып яшәп, өзелеп яраткач?

Шаян буран уйнап үткән җирдә
Өелеп кар ятып калыр.
Берчак мине буран һәм тормыштан
Мәңге упкыны тартып алыр...

*12 февраль*

* * *

Газаплы һәм авыр, үкенечле булыр,
Әгәр язмыш безне аерса,
Өмет-теләкләрнең канатларын
Кызганмыйча кинәт каерса.

Өзелеп яратканнар кавышмый, ди,
Нинди булыр тәкъдир агышы...
Мин ышанам уртак киләчәккә —
Икәү языйк яңа язмышны!

*18 февраль*

* * *

Йолдыз сүнде, диңгез кипте,
Таулар иңде, дисәләр —
Ышанырмын. Әмма миңа
Бер хәбәр китерсәләр:

— Бетте сезнең дуслыгыгыз,
Ташлады сөйгән ярың...
Ышанмам мин, ышаналмам:
— Ялган! — диярмен бары!

Йолдызлар да сүнә ала,
Диңгезләр кибә ала,
Тик безнең мәхәббәт кенә
Үлемсез булып кала!

*15 март*

## Ялгыз язым

Көлгән булам кояш белән бергә
Нурларына куеп йөземне,
Тик барыбер күңел күләгәле,
Бик сагышлы сизәм үземне.

Якты яз да, иркә җилләре дә
Алыштырмый сөйгән ярыңны.
Синең белән бер очрашыр өчен
Бирер идем шушы язымны.

*21 март*

* * *

Өмет белән өзелеп карама син,
Күрсәң әгәр сөеп бакканым.
Йөрәгемдә барыбер синең өчен
Шуннан ары урын тапмамын.

Күңелемне тыңлап елмаям да,
Икеләнүем чынлап таратам.—
Мин бит сине Аны хәтерләткән
Өчен генә бераз яратам...

*Март*

* * *

Кичке Казан каршыласын безне,
Күкләрендә утлар балкытып,
Торсын әле килер көнебезгә
Бергә үтәр юлны яктыртып.

Менә шулай, йөрик икәү бергә,
Гаепләмә сүзсез калуым,
Йөрәк үзе тели, һаман шулай
Үз ягыннан синең баруың.

*3 октябрь, Казан*

## *Апрель башы*

Назланып кына
Бөреләр бүртә,
Яшел яралгы
Борынын төртә.

Өй түбәсеннән
Тамчы коела,
Нурга төренеп
Чәп-чәп коена.

Карала юллар,
Кызара урман,
Уйсулыкларга
Кар суы тулган.

Ашыга бозлар,
Сулар йөгерә,
Көньяктан кошлар
Кайтып өлгерә.

Игенче кырга
Ашкынып карый,
Чәчү башланыр
Көннәрне саный...

Мөлдерәмә җир —
Кояш сулышы.
Җылы. Нур. Рәхәт —
Яз инде шушы!

*27 март*

* * *

Гаҗәпләнмә,
Шигырь язам әле,
Туры килер сезгә укырга.
Кемнәр анда, әй сез, ашыкмагыз
Исемемне сызып атырга!

Илһам көчем кагып канатларын,
Йөрәк тамырларын киерә,
Рәхәт тә соң ул көрәшеп яшәү
Үз йөрәгең җыры көенә.

Чирәм үскән тар сукмаклы итеп,
Күрмимен мин барыр юлларны,
Җырларымда
Үз йөрәгем белән
Күп йөрәкләр җырын җырлармын!

Яздым менә,
Шушы юлларны да
Туры килде сезгә укырга.
Әйттем бит мин,
Әле иртә, диеп,
Исемемне сызып атырга!

*Май, Олы Бакырчы*

* * *

Үттең-киттең,
Кайнар яшьлегем,
Әй!
Бөтенләйгә...
Кире кайтмамсың?!
Шаулый-шаулый
Инде йөрәгемдә
Язларында чәчәк атмамсың?

Язлар җиткәч
Миңа кыен булыр
Шат яшьлегем китсә күңелдән.
Яшьлегем, дим, тукта,
Тукта, зинһар!
Йөрәгемдә туктал бүгенгә...

Чыгыйм сине
Кайнар байрак итеп
Язгы сулар ташкан урынга.
Биреп калдыр
Нурлы елмаюың
Һич юк шушы моңлы җырыма...

*17 ноябрь, Кошман*

## ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВНЕҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ

Шагыйрь Шәүкәт Галиев (Шәүкәт Галиулла улы Һидиятуллин) 1928 елның 20 ноябрендә Татарстанның хәзерге Апас районы Олы Бакырчы авылында туа. 1943 елда җидееллык мәктәпне тәмамлый, әмма әтисе Бөек Ватан сугышында һәлак булу сәбәпле, укырга мөмкинлеге калмый. Ике ел колхозда эшли: гади колхозчы, бригадир ярдәмчесе, учетчик, урман кисүчеләр бригадиры.

1945 — 1949 елларда СССР хәзерләүләр министрлыгының Кайбыч район бүлегендә статист, аннары учет мөдире хезмәтендә була. 1949 елның язында «Колхоз бригадасы» исемле район гәзитенә җаваплы секретарь итеп алына, соңга таба — җаваплы редактор.

Беренче шигырьләрен 1945 елның гыйнварында яза, республика матбугатында 1948 елда күренә башлый. «Чаян»да юмористик образы Котбетдин катнашкан фельетоннардан күреп, 1953 елның көзендә аны Казанга — редакциягә чакыралар. Әдәби хезмәткәр, аннары әдәби бүлек мөдире булып эшли. Бер үк вакытта 1956 елда эшче яшьләр кичке урта мәктәбен тәмамлый. Шул елларда «Яңа көйләр», «Кичке утлар», «Әткәйгә хат» исемле шигырь җыентыклары чыга, балалар өчен яза башлый. 1958 елда СССР Язучылар союзына әгъза итеп алына. Ә 1959 —1961 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы югары әдәби курсларда укый. Аны тәмамлап кайткач, 1971 елның ахырына кадәр, язучы-профессионал сыйфатында әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә. Казан дәүләт университетының Нил Юзиев җитәкчелегендәге фольклор экспедицияләрендә катнаша, милләттәшләр яшәгән күп кенә өлкәләрдә була, укучылар белән очраша. Шуннан соң унөч ел буе (1971 — 1984) Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясенә җитәкчелек итә.

Ш.Галиев төрле жанрларда — лирика, юмор-сатира һәм балалар өчен язылган илледән артык китап авторы. Халык арасында таралган җырлары бар: «Утыр әле яннарыма», «Раушаниям, бәгърем», «Күпме күзләр күреп онытылган», «Тамчылар тамар чаклар», «Сөенечкә дисәм», «Шомырт чәчәкләре ак кына», «Кыңгыраулы мәктәп еллары», «Шалт Мөхәммәтҗан» һәм башкалар.

Шигырьләре мәктәп дәреслекләренә кертелгән. Шәвәлие

татар баласының яраткан дустына әверелде. Балалар әдәбиятын үстерү өлкәсендәге нәтиҗәле эшчәнлеген күздә тотып, 1972 елда аңа «Шәвәли», «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр», «Кызык», «Тәмле йорт», «Котбетдин мәргән» һәм рус телендә Мәскәүдә чыккан «С папой в кабине» исемле шигырь китаплары өчен, татар балалар язучыларыннан беренче буларак, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелә. 1980 елда Татарстан китап нәшриятында рус теленә тәрҗемәдә чыккан «Заяц на зарядке» китабы өчен 1982 елгы Халыкара бүләккә —Х.-К.Андерсен исемендәге Почетлы дипломга лаек була, авторның исеме бөек әкиятченең Почетлы исемлегенә кертелә. Ул шулай ук 1984 елда ВЛКСМ Үзәк Комитетының А.П.Гайдар Билгесе белән бүләкләнә. 1996 елда аңа «Балалар әдәбиятындагы олы казанышлары өчен» А.Алиш исемендәге бүләк бирелде.

Ш.Галиев төрле елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы, яшь авторлар белән эшләү комиссиясе рәисе, язучылар берлегенә кабул итү коллегиясе рәисе, балалар әдәбияты остаханәсе җитәкчесе һәм РСФСР Язучылар союзының юмор, сатира советы әгъзасы, Х.Туфан әдәби мирас комиссиясе рәисе булды. Ул СССР язучыларының III (1959), V(1971), VII (1981) съездларында, РСФСР Язучыларының IV (1975) съездында делегат булып катнашты. Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге комитеты әгъзасы һәм «Сабантуй» гәзите, «Сабыйга» журналы редколлегияләре әгъзасы. Татар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен «Почет билгесе» ордены, «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. «1941 — 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында фидакарь хезмәт өчен», «1941 — 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә — 50 ел» медальләренә лаек була. (1997 елда нәшриятыбызда дөнья күргән «Минем беренче гомерем» китабындагы автобиографик новеллаларда шул хәвефле еллар сурәтләнә.)

Татарстан Республикасы Президенты Указы белән 1995 елның 2 июнендә Шәүкәт Галиевкә татар әдәбиятын үстерүдәге казанышлары өчен «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирелде.

ЭЧТӘЛЕК

*Р.Миңнуллин.* Кадерен белгәннәргә . . . . . . . . . . 7

**50 нче еллар**

Тимерлектә . . . . . . . . . . 12
Ут кабынгач . . . . . . . . . . 13
Соңгы хәбәр . . . . . . . . . . 13
Минем карлыгачым . . . . . 14
Аерылган чак та була... . . . 15
Яшьлекнең бер минуты . . . 15
Атам исеме, балам исеме белән... . . . . . . . . . . . 16
Аңа . . . . . . . . . . . . . . 18
«Каерылып үскән үләннәрдән...» . . . . . . . . . . . 18
Сабый чагым, дисәм . . . . . 19
Буразнаны буразнага ялгап... 20
Бер карасаң... . . . . . . . . . 20
Кашкаларым . . . . . . . . . 21
Алмалар күзлим мин . . . . 22
Мин эзләдем аны... . . . . . . . 23
Ирнем тибрәтсәм дә... . . . . . 23
Әткәйгә хат *(поэма)* . . . . . 24
Бир, кире бир барсын да . . . 42
Үпкән-кочкан . . . . . . . . 43
«Күзләреңдәй кара карлыганнар...» . . . . . . . . . 43
Кем әйтә ала... . . . . . . . . . 44
Тамчылар тамар чаклар . . . 45
Көянтә алып бирим . . . . . 46
Күгәрченнәр үбешәләр . . . . 47
Күпме күзләр күреп онытылган... . . . . . . . . . . . . 47
Ярый ла сөйгән әле . . . . . . 48
Дулкыннар ярга кага... . . . . 49
Камаларны нигә соң кичтем?.. 50
Чәчәкләр белми хәлемне . . . 51
Утыр әле яннарыма . . . . . . 52
Янып-көясем килә . . . . . . 53
Зәңгәр чәчәк . . . . . . . . . 54
Сиңа әйтер сүзем бар . . . . . 55
«Ак калфаклы кыз китә» дип... 56
Чиккән мендәрләр чанада... 57
Кыр казлары кайта каңгылдашып . . . . . . . . . . 58
Яшен яктысында . . . . . . . 59
Юк синсез яши аласым... . . . 60
Юллар бар бөтен якларга . . 61
Күзләреңә карап бер сөйләшсәм... . . . . . . . . . . . . 62
«Көнчелләрем чәчәк ата...» . . 62
Ник шуларның берсе син түгел? . . . . . . . . . . . . 63
Яшьлек кебек сөендереп... . 64
Моңа хәтле ничек күрмәгәннәр . . . . . . . . . . . . . 65
Сөенечкә дисәм... . . . . . . . . 66
Үкенерсең үкенүен... . . . . . 67
Ник яңара сагышлар . . . . . 68
«Йөрәгемнән хисләр ташый гына...» . . . . . . . . . . . 69
«Ник яраттым икән шул кадәрле». . . . . . . . . . . . . 69
Өлешеңә чыккан көмешең... 70
Әллә бергә үскәнгәме... . . . . 70
Раушаниям, бәгърем . . . . . 71
Саумысез, арышларым! . . . . 72
Килгән идем Агыйделгә . . . 73
Юл җыры . . . . . . . . . . . . 74
Тып-тын урамнардан . . . . . 75
Оныткан дисеңме? . . . . . . 76
Шомырт чәчәкләре ак кына... 76
Тынгы бирми миңа шушы төннәр . . . . . . . . . . . . . 77
Кызлар, кызлар бииләр... . . . 78
«Казаннарга тагын поезд китте...» . . . . . . . . . . . . 79
Уйламый идем... . . . . . . . . 80
«Нигә миңа диңгез зәңгәрлеге...» . . . . . . . . . . . . . 81
«Без беренче тапкыр икәүләшеп...» . . . . . . . . . . . 81
Ай-Петрида ята партизаннар... 82
Тыелган дәрт, тезгенләнгән хисләр . . . . . . . . . . . . 83
«Миндәй сине беркем яраталмас...» . . . . . . . . . . 83
Илһам Шакировка . . . . . . 84
Кушылганнар юллар юлларга . . . . . . . . . . . . . . 84
Көнел тартты тагын шул якларга . . . . . . . . . . . 85

Кипарислар мине аңламаслар 86
Казлар оча шәһәр өстеннән . 87
«...Сабый чагым...» . . . . . . 88
Сузма һаман сагыш көйләреңне . . . . . . . . . . . . . 89
Ап-ак карда йөрим . . . . . . 89
Җирдә ята икмәк сыныгы... 90
Туры Тукай . . . . . . . . . . 91
Чулпы чыңы . . . . . . . . . 92

**60 нчы еллар**

«Икәү генә үткән сукмаклар бар...» . . . . . . . . . . . . . 94
Кырга чыксам . . . . . . . . 94
Бабайлардан калган. . . . . . . 95
Гыйнвар яңгыры . . . . . . . 96
Май аенда яуган кар кебек . 96
«Казан сөйли!» . . . . . . . . 97
Тукай Кырлаенда . . . . . . 98
Таң шатлыгы . . . . . . . . . 100
Чәчәкләрне юлда таратсам да . . . . . . . . . . . . . . . 101
Һавада очканда . . . . . . . 102
Тимерче Гомәр һәм гомер *(баллада)* . . . . . . . . . . 102
Сугышлардан калган мина . 106
Патша-туп бар Кремль уртасында... . . . . . . . . . . . 107
Кулын кыса алмадым . . . . 108
Петропавел крепостенда . . . 109
Юллар заманы . . . . . . . . 112
Көньяк төнендә . . . . . . . . 113
Могҗизалары сөюнең . . . . 114
Төннәрен дә уза яшьлек . . . 115
Бушка янмасыннар . . . . . . 116
Мәхәббәтемә . . . . . . . . . . 117
«Үкенечле булыр көтмәгәндә...» . . . . . . . . . . . . . 117
«Мәхәббәткә сусап йөргән чакта...» . . . . . . . . . . . . 118
«Кыраулар да үткән, кырпак төшкән...» . . . . . . . . . . 118
Очрашкач беренче сүз . . . . 119
Кызыгып кайтам . . . . . . . 120
«Мең аерылу бар йөрәктә...» 120
Кол Галигә . . . . . . . . . . . 121
«Тимә, сырхау, Хәсән абыйга...» . . . . . . . . . . . . . 122
«Шәһәрләрдән, шигырьләрдән арып...» . . . . . . . . . 122
Аталы-уллы солдатлар *(баллада)* . . . . . . . . . . . . . 123
Кыя һәм Кеше *(баллада)* . . 124
Яңгыр ява. . . . . . . . . . . . 126
Имгәнгән күңел . . . . . . . . 127
Тик аны гына сөйлә . . . . . 128
«Әй күп тә соң, диңгез, тозлы суың!..» . . . . . . . . . . 128
«Күрәсеңме зәңгәр һаваларны...» . . . . . . . . . . . . 129
«Су читенә төшеп чишенә кыз...» . . . . . . . . . . . . . 129
«Дулкыннарда сугыш шаулаганга...» . . . . . . . . . . . 130
«Карадагны сүнгән вулкан диләр...» . . . . . . . . . . . 130
«Мамай Курганында мәңгелек ут...» . . . . . . . . . . 131
«Карлы басуларда тургай сайрый...» . . . . . . . . . . . 131
«Илне тукландыру синең өстә...» . . . . . . . . . . . . . 132
«Озак йөреп туган якка кайттым...» . . . . . . . . . . . 132
«Рәхмәт сиңа, безне ашатучы...» . . . . . . . . . . . . . 133
«Гади генә шушы кырларымның...» . . . . . . . . . . . 133
«Кырга чыксам, җаным рәхәтләнә...» . . . . . . . . . 134
«Кайнар комга килеп утырам да...» . . . . . . . . . . 134
«Кояш исе сеңгән чәчләреңнән...» . . . . . . . . . . . . 135
«Салкын һава тынны куырып ала...» . . . . . . . . . . 135
«Сугышка дип чыгып киткән иргә...» . . . . . . . . . . 136
«Исәннәрнең исенә төшереп...» . . . . . . . . . . . . . 136
«Текә кыяларның кәрнизеннән...» . . . . . . . . . . . . 137
«Сапун гора — Сабын тавы икән...» . . . . . . . . . . . . 137
«Яр буенда янган барлык утлар...» . . . . . . . . . . . . 138
«Хушлашкачтын һәрчак үкенәсең...» . . . . . . . . . . 138
«Уллар әйтә: «Яхшы — юлларның...» . . . . . . . . . 139
Нәсихәт . . . . . . . . . . . . . 139
«Халкым!», «Халкым!» дигән сүзләреңне...» . . . . . . . 139
Җир язмышы . . . . . . . . . . 140

«— Ир-егеткәй, нигә йоклamыйсың?..» . . . . . . . . . 140
«Үкенечле мәхәббәтләр көчле була...» . . . . . . . . . . . 141
«Сирәк күрәм сине...» . . . . 141
Хәдичә . . . . . . . . . . . . . 142
«Сыбызгылар ясыйм балаларга...» . . . . . . . . . . . 143
«Бер сулыш тынды...» . . . . 143
Ике дус турында баллада . . . 144
Дога . . . . . . . . . . . . . . 146
«Игенчеләр...» . . . . . . . . 147
Каен турында йөзенче җыр . 148
Бер кызга . . . . . . . . . . . 149
«Сөймәгәннән хат килсә...» . 150
«Сиңа сөйләр күпме-күпме сүзләр...» . . . . . . . . . . 150
«Аерылганга шактый гомер үтте...» . . . . . . . . . . . 150
Тукайга . . . . . . . . . . . . 151
«Әйттеләр...» . . . . . . . . . 152
«Очрашу бар безгә, кавышу юк...» . . . . . . . . . . . . 152
Мин сине эзлим . . . . . . . 153
Хәтерлим . . . . . . . . . . . 154
«Син чаңгыда җилпендең дә уздың...». . . . . . . . . . . 155
«Яшь кыз күкрәгедәй...» . . 155
«Көртләр ерып йөрим урамнарда...». . . . . . . . . . . 155
Муса елмаюы турында баллада . . . . . . . . . . . . . . 156
«Каерып алып, суырып үптем...» . . . . . . . . . . . . 159
«Онытырсың» дидең...» . . . 159
«Теңкәбезгә тиеп торалар...» 159
Ике язмыш.
1.Югалган шагыйрь . . . 160
2.Билгесез кабер . . . . . 161
Минем гомер . . . . . . . . . 163
Тормыш сәхнәсендә . . . . . 164
Сабыйга . . . . . . . . . . . . 165
«Үткәннәрне уйлыйм да мин...» 166
Тормыш-көндәш... . . . . . . 167
«Ачуланган сүзләреңне...» . . 167
Надан аяклар . . . . . . . . 168
Сөйгән ярым минем тылсымчы . . . . . . . . . . . . . . 169
«Күз күнекмәгән...» . . . . . 170
«Мин сине күрергә телим...» 171
«Җир баласы идем, үлән ашап...» . . . . . . . . . . . 172
«Сабыр диеп...» . . . . . . . . 173
«Мин үтәм урамнардан...» . 174
«Борын заман гаҗәп тыныч булган...» . . . . . . . . . . 174
Тукай васыяте . . . . . . . . 175
Тирән тамырлар . . . . . . . 176
«Яшьләр, яшьләр, кая ашыгасыз?...» . . . . . . . . . . 177
«Исемеңне алып җырга куштым...». . . . . . . . . . . . 177
Челләдә . . . . . . . . . . . . 178
«Кайдадыр гармун уйныйлар...» . . . . . . . . . . . . 179
«Бишегеңдә мине тирбәтмә син» . . . . . . . . . . . . . 179
«Минем өчен соңгы мизгел килер...». . . . . . . . . . . 180
Үкенүләр . . . . . . . . . . . 180
«Бәйрәм итә халык рәхәтләнеп...» . . . . . . . . . . . . 181
Хакыйкать . . . . . . . . . . 181
«Сиздермисең, әмма дулкынлану...» . . . . . . . . . . . 182
«Көнкүрештә мәшәкать күп...» 182
«Оныткандыр диеп йөрисеңдер» . . . . . . . . . . . . . 183
Алмагач . . . . . . . . . . . . 184
Чаң турында баллада . . . . 185
Язгы сөенечләр . . . . . . . . 186
«Мәхәббәт мине...» . . . . . . 187
Илһамсыз чак . . . . . . . . . 187
Карашларың шундый ягымлы! . . . . . . . . . . . . . 188
Нюра . . . . . . . . . . . . . . 189
Хәтимә апа . . . . . . . . . . 190
Сувенир чабаталар . . . . . . 191
«Карыйм да мин, сеңелем, гаҗәпләнәм...» . . . . . . . 192
«Караңгы төн...» . . . . . . . 193
«Үзем! — дисең...» . . . . . 193
«Күзләр карарга ояла...» . . 194
«Сез тарихның ар башында...» 194
Сынатма . . . . . . . . . . . . 195
«Айлы төндә йолдызларга баксам» . . . . . . . . . . . 196
«Сугышларда калган егетләрнең...» . . . . . . . . . . 196
«Каберләре бөтен Европада...» 197
«Сәхнәдәге Хәлил, Галиябану...». . . . . . . . . . . . 197
«Ул фронтка бәхилләшеп китте» . . . . . . . . . . . . . 198

«Әткәй рәсмен илтсәм фотографка...» . . . . . . . . . . 198
«Ымсындырып, кызыктырып килә...» . . . . . . . . . . 199
«Ерак планетаның вәкилләре...». . . . . . . . . . . . 199
«Иртән кышның кырыслыгы иде...» . . . . . . . . . . 200
«Кашлаклардан карлар тизрәк китә...» . . . . . . . . . 200
«Җир җылысын тоеп чалкан ятам...» . . . . . . . . . . . 201
«Күлмәк эченә башак куя идем...» . . . . . . . . . . . 201
«Нарат төбенә көмеш акча күмдек...» . . . . . . . . . . 202
«Бер авылда үстек...» . . . . 202
Мәхәббәт һәм биография . . . 203
«Биш ел буе чут төймәсе тарттым...» . . . . . . . . . . . 204
«Кай арада, белмим, күнеккәннәр...» . . . . . . . . . . 204
Кыңгыраулы мәктәп еллары 205
«Ничек икән синең тормышларың!...» . . . . . . . . . . 206
«Ничә көннәр буе үз-үземә...» 206
Баш очымдагы дүрт юл... . . 206
«Илләрдән дә кителә икән лә ул...». . . . . . . . . . . . . 207
«Мәңгелектән...» . . . . . . . 207
Календарь бүләк иткәндә . . 208
Бер мең дүрт йөз унсигез көн 209
«Минем эзләгәнем син түгелдер...» . . . . . . . . . . . 210
«Борчулар йөрәкне таласа...» 210
«Күкнең зәңгәр тамчылары...» 211
«Тезләреңә кызыл бәрхет салдың...». . . . . . . . . . . . 211
«Эскәмиядән карны төшердек тә...». . . . . . . . . . . 212
«Җәйнең соңгы көне...» . . . . 212
«Җәй әле, җәй кебек...» . . . 213
«Тар бүлмәләр, тар күңелләр...» 213
Ут . . . . . . . . . . . . . . 214

**70 нче еллар**

Уй елгасы . . . . . . . . . . 216
Казан арты . . . . . . . . . . 218
«Күз алдымда бөреләнде...». 218
«Сары чәчәк — хыянәт төсе», диләр... . . . . . . . . . . 219
«Җырлы чорлар, нурлы еллар...» . . . . . . . . . . . . 219
«Яшисең ил гамен кайгыртып...» . . . . . . . . . . . . 220
«Күңелемдә күп кешеләр тере...». . . . . . . . . . . . . 220
«Уйлап баксаң, кеше тозлы бит ул...» . . . . . . . . . . 221
«Диңгез офыгында зәңгәр тасма...» . . . . . . . . . . . 221
«Асфальтны тишкән үсенте...» 222
Халык җыры . . . . . . . . . 222
«Бер файдасыз сагыну инде...» 222
«Мин каңгырып йөрим чит вокзалда...» . . . . . . . . . 223
«Килде давыл, айкалды көн...» 223
«Чыгамын да иртән басуларга...» . . . . . . . . . . . . . 223
«Камыр әчегәндәй ята басу...» 224
Киләчәктә . . . . . . . . . . 224
«Җәй кояшы булып йөргән идең...» . . . . . . . . . . . . 224
«Мәңгелектән кайтыр әмәл булса...» . . . . . . . . . . . 225
«Чәчәк аткан болыннарым, кайда сез?..». . . . . . . . . 225

**80 нче еллар**

Хәсән Туфан белән хушлашу сүзе . . . . . . . . . . . . 226
Юл өзелмәс . . . . . . . . . 227
Канатлылар без — бердәм чагында . . . . . . . . . . . . 228
Яшьлек акылы . . . . . . . . 229
«Ромашкалар булып синең...» 230
«Тамчы булып өстәлсәң дә...» 230
«Кояшлы бер көне өчен...» . 230
«Үкенечле мәхәббәтем...» . . 231
«Галәмдәге Киек Каз Юлыдай...» . . . . . . . . . . . . 231
«Гашыйклар йөри, бар илнең...» . . . . . . . . . . . . 231
Моңсылу . . . . . . . . . . . 232
«Кабынмам кебек иде...» . . 232
«Бәхетсезләр моңлы-көйле була...». . . . . . . . . . . . 233
«Гүләү ишетәм дә күккә карыйм...» . . . . . . . . . . . 233
«Мин китәрмен җирдән...» . 233
Авани, тус! . . . . . . . . . . 234
Югалмас сүз . . . . . . . . . 236
Сибгат Хәким белән хушлашканда . . . . . . . . . . . 238
Мәхәббәт хикмәтләре . . . . . 239

Безнең нәсел — безнеңчә! . . 241
«Киек казлар тезелешеп очса...» . . . . . . . . . . . . . 242
Ышаныч . . . . . . . . . . . . 243
«Әткәй китте...» . . . . . . . 244
«Әтиләләр әти кадерен белми...» . . . . . . . . . . . . 244
«Әнкәй тавышына...» . . . . 245
«Буран сарган тәрәзәдән карыйм...» . . . . . . . . . . . 245
«Ул адашкан бәбкә тавышлары...» . . . . . . . . . . . . 246
«Балан җыям көзге бакчада мин...». . . . . . . . . . . . 246
«Кара җиләк җыйдык икәүләшеп...» . . . . . . . . . . 247
Быелгы «Былтыр» . . . . . . 247
«Йолдызларга горур баккан кеше...» . . . . . . . . . . . 248
«Бу дөньяга килгәч...» . . . . 248
«Бүдәнәнең, хәле, ай-һай, мөшкел..» . . . . . . . . . . 249
«Айлы төннәр...» . . . . . . . . 249
Иман . . . . . . . . . . . . . . . 250
Илгә кайта торналар... . . . 252
Ком сәгате . . . . . . . . . . 253
Туган телем . . . . . . . . 254
Балачак балладасы . . . . . . 255
1988 ел кояшына . . . . . . . 256
Җитеп барам... . . . . . . . . . 257
Язмышлар . . . . . . . . . . . 258
Күзле төш . . . . . . . . . . . . 258
«Дәвер арты дәвер алмашына...». . . . . . . . . . . . 258
Хәтерсезлек . . . . . . . . . . 259
Ялгызлык . . . . . . . . . . . . 261
Буыннар, буыннар . . . . . . 262
Бозлык дәвере . . . . . . . . . 263
Соңгылар . . . . . . . . . . . . 264
Күңел түре . . . . . . . . . . . 265
Эчке «штатлар» . . . . . . . . 267
Йөгерергә яраттык без... . . . . 269
Үлчәү . . . . . . . . . . . . . 270
Лоджиядә толып . . . . . . . 271
Хәрәкәттә — һәлакәтме? . . . 272
Яшьлегем чәчәкләре . . . . . 273


**90 нчы еллар**


Сеңелләр китә кияүгә . . . . 276
Кайбычкаем-яшьлегем . . . 277
Г.Камалның оныгы... . . . . 278
«Сөенеп, сыенып» . . . . . . . 279
Якташларга әйтер сүзем . . . 280
Шәвәлиев Барый . . . . . . . 282
«Баксана — яз икән!..» . . . . 282
«Тулышты моң белән...». . . 283
Соңгы мәхәббәтем . . . . . . 283
«Хушлашулар белән көз килде...» . . . . . . . . . . . . 283
Хәтер иясе . . . . . . . . . . . 284
Баттал холкы . . . . . . . . . 285
Иске рәсем . . . . . . . . . . 285
Мәңгелек бабай . . . . . . . . 286
Туганнар табынга җыелдык 287
Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиевкә . . . . . 288
Беренче мәхәббәтем син . . . 289
Нәүрүз . . . . . . . . . . . . . 290
Туган телнең туган көне . . . 291
Объектив хәл . . . . . . . . . 292
Онытылу . . . . . . . . . . . 293
Тукай рәсеме . . . . . . . . . 293
«Азнакайлар, әллә кайлар...» 294
Багышлау . . . . . . . . . . . 295
Олы Бакырчыма . . . . . . . 295
Карамасар . . . . . . . . . . . 296
Кайтыйк әле . . . . . . . . . 297
Көзге белән хушлашу . . . . 298
Якташларга теләк . . . . . . 299
Хәтер аланы . . . . . . . . . . 299
Биштәр . . . . . . . . . . . . 300
Гомер кояшы . . . . . . . . . 301
Якташлар туганлыгы . . . . 302
Халык артисты Айрат Арслановка . . . . . . . . . . . 303
Сара Садыйкова урамы . . . . 303
Тауларым, үзәннәрем . . . . 304
«Яшәдемме мин үз гомеремне...». . . . . . . . . . . . 304
Туганнарны барлыйм Яңа елда . . . . . . . . . . . . . 305
Яшьлегемә кире кайтмас идем 306
Әле дә бар Яңа еллар! . . . . . 307
Тормыш-язмыш . . . . . . . 308
Хәким чишмәсе . . . . . . . 309
Киләчәгең . . . . . . . . . . 310
Яшьлек истәлеге . . . . . . . 311
Әй гомерләр . . . . . . . . . 312
Ни чәчсәң... . . . . . . . . . . 312
Яшәү төсе . . . . . . . . . . . 313
Без — Олы Бакырчылар! . . . 314
Сурәт эзләү . . . . . . . . . . 315
Мин Кайбычка кайттым . . . 316
Озон катламы . . . . . . . . . 317

Язда калган күзләр . . . . . . 318
Хәерле юл! . . . . . . . . . . . . 319
«Кошлар китә, еллар китә...» 319
Кырык яшь уйландыра . . . 320
Минем яшьлегемнең кызлары . . . . . . . . . . . . . 321
Картлык — шатлыкмы . . . . 322
Ындырчының ике чишмәсе 323
Котбетдин котлавы . . . . . . 324
«Патша хатыны...» . . . . . . 325
Элеккечә . . . . . . . . . . . . 327
Сүрелмәс мәхәббәт . . . . . . 328
Яңа Кайбыч, саумы! . . . . . . 329
Кем ул Роберт Миңнуллин? 330
Сабан туена ничә ел? . . . . . 331
Мәдәният сараен ачканда . . 333
Дөнья . . . . . . . . . . . . . 334
Сугыштан кайтмый калган 169 авылдаш истәлеге . . . . 334
Шулай инде . . . . . . . . . . 335
Иж-Бубыйда көз иде . . . . . 336
Яңа Кайбычтан беренче хат . 337
Канатларым . . . . . . . . . 338
Омтылыш . . . . . . . . . . . 339
Егерменче гасыр азагы . . . . 340
Дөньялар бөтен иде . . . . . . 341
Вәгаләйкем әссәлам! . . . . . 342
Июнь ае . . . . . . . . . . . . 343
Гыйльман-Вилдан . . . . . . 344
Үлем элмәге *(Сабан туенда очрашу)* . . . . . . . . . . 346
Шом . . . . . . . . . . . . . . 351
Илһам капусы . . . . . . . . 352
Олы Бакырчыда очраштык . 353
Ник тынгысыз һаман бу җаным . . . . . . . . . . . . 354
Ниләр бар икән күңелдә? . . . 355
Нindидер көч . . . . . . . . 356
Таң . . . . . . . . . . . . . . . 357
Горурлык . . . . . . . . . . . 358
Бер көн . . . . . . . . . . . . 358
Кайттым . . . . . . . . . . . . 359
Бар . . . . . . . . . . . . . . . 359
Талларым-танышларым . . . 360
Чишмәм минем . . . . . . . 361
Аңлашу . . . . . . . . . . . . 362
Мазлүма апа . . . . . . . . . 363
Авыл хатыны . . . . . . . . . 364
Авыл . . . . . . . . . . . . . . 366
Ярап тора . . . . . . . . . . . 367
Ымсыну . . . . . . . . . . . . 368
Онытылган төш . . . . . . . 369
Арча кызы . . . . . . . . . . . 370
Җилләр . . . . . . . . . . . . 371
Сынау — сынатмау . . . . . . 371
Серләрем бар . . . . . . . . . 372
Әгәр дә мәгәр . . . . . . . . . 373
Пароход . . . . . . . . . . . . 374
«Шыбыр-шыбыр яңгыр ява...» 375
Сагыну турында . . . . . . . 376
Тизлек-җитезлек . . . . . . . 377
Ак кәгазем . . . . . . . . . . 378
Егетлек . . . . . . . . . . . . 379
Балкып яшә, Апасым! . . . . 381
Мәчет манарасында . . . . . . 382
Юбилей догалары . . . . . . 383
Гасыр яшьтәше . . . . . . . 384
Сагыну сабаклары . . . . . . 385
Тере суның күзендә . . . . . 386
Сулар ага, уйлар ага . . . . . 387
Балчык хәтере . . . . . . . . 388
Ак болын . . . . . . . . . . . 389
Ул аланнар . . . . . . . . . . 390
Йөрәк эше . . . . . . . . . . . 390
Улыңа куштың минем исемне . . . . . . . . . . . . . . 391
Яңа мәктәп нигезенә . . . . . 392
«Гали» диеп аны йөрттеләр... 393
Бу яз . . . . . . . . . . . . . . 396
Тоташ агым . . . . . . . . . . 394
Фәрманның дәрманы . . . . 395
Татар акылы . . . . . . . . . 397
Ник? . . . . . . . . . . . . . . 398
Яшәү... . . . . . . . . . . . . 399
Күк белән күңел арасы . . . . 400
Кемгә бәйрәм... . . . . . . . . 401
Шөкер . . . . . . . . . . . . . 402
Хатлар яна... . . . . . . . . . 403
Көзге яңгыр . . . . . . . . . . 404
Мәхәббәт һәйкәле . . . . . . 405
Нинди . . . . . . . . . . . . . 406
Сизем . . . . . . . . . . . . . 406
Каратунның ак бәхете . . . . 407
Син калдырган еллар . . . . 408
Күз офыкта... . . . . . . . . . 409

**2001**

Ак юллар . . . . . . . . . . . 410
Каныңда ул, җаныңда . . . . 411
«Сибеләп чәчем...» . . . . . . . 411
Мәктәп белән хушлашканда 412
Ак тәүбә . . . . . . . . . . . 412
Яшьлек дигән урамнар . . . . 413
Тирән таулар . . . . . . . . 413

Албасты . . . . . . . . . . . . 414
Безнең хәлләр, безнең горурлык . . . . . . . . . . . . . 414
Үпкә . . . . . . . . . . . . . . 415
Һәйкәлдәге дуска . . . . . . . 415
Кеше озак яшәмәкче . . . . . 416
Кирәк безгә. . . . . . . . . . . 417
Иман йортыбызга . . . . . . . 418

**2002**

«Безнең якның илчеләре булып...». . . . . . . . . . . . 419
«Башың куйдың иңемә...» . 420
Күлле-Киме . . . . . . . . . . 421
Нинди хикмәт . . . . . . . . . 421
Елама, тал . . . . . . . . . . . 422
Җәбер . . . . . . . . . . . . . 423
Шифалы җир . . . . . . . . . 424
Сусау . . . . . . . . . . . . . . 425
Синең кодрәт . . . . . . . . . 425
Кыйбла . . . . . . . . . . . . 426
Өсте һәм асты . . . . . . . . . 427
Бабай: мәхәббәт турында . . . 429
Тәрәзәдән гөлләр карый . . . 430
Бәхет кайда? . . . . . . . . . . 431
Балачак сукмагы . . . . . . . 432
Киләчәкне төзүчеләр . . . . . 433
Син дә бер, мин дә бер . . . . 434

**Кайбыч дәфтәреннән**
(1945 — 1950)

**1945**

Моң . . . . . . . . . . . . . . 436
Үткән яшьлек . . . . . . . . . 436
Кичке уйлар . . . . . . . . . . 437
«Уйна, дускай...» . . . . . . . 437
«Чара эзләп ярсу йөрәккә...» 437
Туган илне сагыну . . . . . . 438
Тыңла, йөрәк . . . . . . . . . 438
«Сикреп-сикреп ага кар сулары». . . . . . . . . . . . . 438
«Мәхәббәтнең кайбер серләре...». . . . . . . . . . . . . 439

**1946**

«Әллә нинди шатлык булыр сыман». . . . . . . . . . . . 440
«Соңгы чиген белмим...» . . . 440
«Сипче, кояш, шәфкать нурыңны...» . . . . . . . . . 440
Яз кайта . . . . . . . . . . . . 441
«Кемгә сөйлим икән зарларымны...» . . . . . . . . . . 442
«Йөрәгемнең бар тибешен...» 442
«Көн артыннан көннәр ялганалар...». . . . . . . . . . . 442
Яз көнендә . . . . . . . . . . . 443
«Нурга манып иркен табигатьне...» . . . . . . . . . . 443
Кышкы хыяллар . . . . . . . 444
Иртән . . . . . . . . . . . . . 445
Урман тынган . . . . . . . . . 445

**1947**

Сагыну билгесе . . . . . . . . 446
Җырлар дәшә . . . . . . . . . 447
Тукай клубы . . . . . . . . . 447
Унтугыз яшь . . . . . . . . . 447
Кайбыч . . . . . . . . . . . . 448
«Йөрәк нигәдер ашкына...» . 448
«Соңы иде кинәндергән җәйнең...» . . . . . . . . . . . . 449
Буш вагонда . . . . . . . . . . 450

**1948**

Айлы тынлык . . . . . . . . . 451
Саумы, Казан! . . . . . . . . . 451
Якты манзара . . . . . . . . . 452
Кышкы төн . . . . . . . . . . 452
«Гаҗәпләнсә гаҗәпләнер дусишләрем...» . . . . . . . . . 453
Юлда . . . . . . . . . . . . . . 453

**1949**

Тамчы тама иде . . . . . . . . 454
«Менә мин кем, карагыз, дип...» . . . . . . . . . . . . 455
Сагындым мин . . . . . . . . 455
«Яле кайгы, үкчәң күтәр...» 456
Көзге урманда . . . . . . . . . 456
Узармы давыллар . . . . . . . 457
Яшьнәсен язгы яшеннәр . . . 458
Гаҗәпләнмәгез . . . . . . . . 459
Бер кодрәт бар . . . . . . . . 459
«Мин тормышка горур карап үстем...» . . . . . . . . . . . 460
«Күкрәгемне ачам...» . . . . 460
Сөенәм! . . . . . . . . . . . . 461

**1950**

Бәхилләшү . . . . . . . . . . 462
«Илаһи көч сизәм йөрәгемдә...» . . . . . . . . . . . . . 463

«Моңсу булса, сызып җырлап җибәр...» . . . . . . . . . . . 464
«Күбәләктәй карлар оча бүген...» . . . . . . . . . . . . . 464
«Киләсе таң, белмим, ничек туар...» . . . . . . . . . . . . 465
«Газаплы һәм авыр, үкенечле булыр...» . . . . . . . . . 465
«Йолдыз сүнде, диңгез кипте...» . . . . . . . . . . . . . 466
Ялгыз язым . . . . . . . . . 466
«Өмет белән өзелеп карама син...» . . . . . . . . . . . . 467
«Кичке Казан каршыласын безне...» . . . . . . . . . . . 467
Апрель башы . . . . . . . . . 468
«Гаҗәпләнмә, шигырь язам әле...» . . . . . . . . . . . . 469
«Үттең-киттең...» . . . . . . . 470

Шәүкәт Галиевнең тормыш юлы . . . . . . . . . . . . 471

Литературно-художественное издание

Шаукат **Галиев**
(Идиятуллин Шаукат Галиевич)

**ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ**

В пяти томах

Том 1

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *В.Е.Булатов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салуче *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Р.Н.Шакирова, Л.С.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән. Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.11.2002. Форматы 84 108$^{1}/_{32}$. 65 гр. офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 25,2 + рәс. 0,84 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 26,36. Нәшер-хисап табагы 16,55 + рәс. 0,95 + форз. 0,36. Тиражы 3000. Заказ Б-643.

Татарстан китап нәшрияты. 420111, Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111, Казань, ул. Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420266. Казан, Декабристлар ур., 2.